Безнең МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
10
октябрь 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Апас ягына сәфәр: «Шәп! Шәп! Шәп!»
40 бит

Дәвеш-Толымбай моңнары
49 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

10
(346)
октябрь 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.



4

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Шәүкәт Галиев

ТАРИХИ МИРАС

4 Чыңгыз хан сурәте. *Н.Хөсәенов, И.Хөсәенов*
8 «Бакыйга мәхәббәте куәтле иде...» *Л.Мортазина*
10 Әхмәд бай. *Г.Баруди*
18 Болгаер табылдыклары – Финляндиядә. *Х.Бәдретдинов*
22 Апаслылар «Казан каймасы»нда. *Б.Мифтахов*
26 Омар Хакан: «Татарлар – бик укымышлы халык!»
32 Олуг шәхесне искә алу
34 100 ел элек татар дөньясы
37 Галимә абыстай яки Әби-тәтә күлмәге. *А.Сабирова*
40 Апас ягына сәфәр: «Шәп! Шәп! Шәп!» *М.Госманов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразыев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битклә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррирләр
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)
Айзилә Сабирова
(843) 222-09-83 (17-92)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкаләавторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ТАТАР ГАМЕ

46 Айрат Җиһаншин: «Киләчәк буынга бай мирас калдырырбыз дип уйлыйм»
49 Дәвеш-Толымбай моңнары
55 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

56 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
62 Ислам. Дини сүзлек
63 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
64 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

66 Гали Хуҗи шигырьләре
68 Тәүфикъ Әйдигә хатлар. *А.Гыйләҗев*
72 Офык читендәге йолдыз. *Л.Хәмидуллин*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

79 Хаҗ сәфәре. *Л.Лерон*
86 Әсгат Галимҗанов булып карагыз. *Г.Ризванов*
90 «Исемең матур, кемнәр куйган?..» *Ә.Зарипов*
94 Истә, һаман да истә!
96 Хәтер көне. *М.Әгъләм*

СӘНГАТИ МИРАС

98 Аны көткән агач улаклар
104 Апастагы тиңсез хәзинә
106 «Рәйхан» җыры

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

108 Тирәк

СИХӘТЛЕ МИРАС

109 Тупыл дәвалый

ТАТАР РИЗЫГЫ

110 Кабак бәлеше – тәм-том бәйрәме!

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә…

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Октябрь*

Заказ №О-2908. Тираж – 2250 данә. Формат 70x100 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 27.09.2022. Чыгу көне: 04.10.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев

Мин сезгә шундый акыл бирәм:
беркайчан да акыл бирмәгез.
Шәүкәт Галиев

Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев ТР Президенты Минтимер Шәймиев белән. 2008 ел

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ*

(20.11.1928-7.05.2011)

Кеше ишетсен дисәң, пышылдап әйт.

***

Юньсез мактаса, хур итәр.

***

Иң бәхетле чагың – бәхет турында уйламаган чак.

***

Кояшта яфрак матурлыгы күренә, давылда тамыр ныклыгы беленә.

***

Кайсы кешедән, якыннан белгән саен, ерагаясың.

***

Берәүнең йөзендә борын хаким, берәүнең йөзендә – авыз баш.

***

Сәгать әкрен йөри, вакыт тиз уза.

***

Төш күрергә күзлек кирәкми.

***

Эчтән янсаң да, төтенең туры чыксын.

***

Акылга утыру әле ул тик утыру дигән сүз түгел.

***

Үткән көннәрнең төннәре дә якты.

---

*Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Гали улы Һидиятуллин) – Апас районының Олы Бакырчы авылында туган. Татарстанның халык шагыйре (1995), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1972), Г.-Х.Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом иясе (1982), ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби премиясе лауреаты, 1958 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде. ■

ТАТАР ХАННАРЫ

Чыңгыз хан сурәте

Нурмөхәммәт Хөсәенов, Илдар Хөсәенов

Чыңгыз ханның «кануни» рәсеме. Монда ул монголоид итеп сурәтләнгән.

«Бөек хан яисә Тартария императоры...»

Бу темага күп язылган инде. Хәзерге галимнәр Чыңгыз ханның бер дәреслектән икенче дәреслеккә күчеп йөргән «кануни» портретына шикләнеп карыйлар. Әлеге бердәнбер «рәсми», «тарихи» сурәт Хубилай хан чорында, XIV гасырда, Чыңгыз хан үлеп (1227), берничә дистә ел узгач ясалган дип санала; ул Тайбэй (Тайвань) сараеның милли музеенда саклана.

Фарсы тарихчысы Рәшидеддин (1247-1318) «Җәми әт-тәварих» («Гомуми тарих») хезмәтендә: *«Чыңгыз нәселендә балалар соры күзле һәм аксыл чәчле булып туалар,* – дип яза. Тагын: *Хан үзе дә аксыл чәчле, яшькелт-зәңгәр күзле иде»,* – дип искәртә. Дөрес, шул ук китапта җиһангир, ни сәбәпледер, монгол кыяфәтле итеп ясалган. Рәшидеддин, мәгълүм булганча, аны күреп белмәгән, әлеге сурәтнең авторы да билгесез.

Фән докторы Д.Баяр (Монголстан) бу рәсем турында болай ди: *«Чыңгыз хан сурәте Юань хакимнәренең сарайларында сакланып калган. Манҗурлар хакимияте бәреп төшерелгәч, 1912 елда, тарихи һәм мәдәни хәзинәләр Үзәк дәүләт*[1] *карамагына күчә. Алар арасында күренекле илбашларының (шул исәптән, хатыннарының да), акыл һәм фикер ияләренең рәсемнәре бар. Хосусан, сигез монгол ханы һәм җиде ханшаның сурәте мәгълүм. Бу портретлар 1924, 1925, 1926 нчы елларда Пекинда дөнья күрә. Анда Чыңгыз хан ачык төстәге мехлы башлык, кыек изүле ачык*

[1] Үзәк дәүләт – Кытай (Чин) иленең бер атамасы.

төстәге дээл[2] *киеп, киң маңгайлы, яктылык сирпеп торган йөзле, төпле карашлы, сакаллы, үреп, колак артына җибәрелгән чәчле, өлкән яшьтә итеп сурәтләнгән. Өйрәнгәннән соң, озынлыгы – 59 см, киңлеге 47 см булган тукымага әлеге рәсем 1748 елда төшерелгән дип табыла»*[3].

Хәер, андый шикләнүләр безгә генә хас түгел: *«Кульязма борынгы нәсх өслүбендә, аермачык, танырлык итеп язылган, дата куелмаган, язу рәвешенә һәм иске Сәмәрканд кәгазенә игътибар итсәң, әлеге кульязманы гаять борынгы дип табарга мөмкин, ул, мөгаен, XIV гасырда (һичьюгы, икенче яртысында) язылгандыр; гәрчә В.В.Бартольд аны, икеләнеп кенә: «XV гасырдан да соңрак түгел», – дип билгели»*[4].

Тагын бер хәбәргә күз салыйк: *«Без моның ише гарәп язуларының ялган күчермәләрен ясап, киң җәмәгатьчелеккә чыгарган нәсараларның*[5] *да булганлыгын беләбез. Арада иң мәгълүме – Хименес де Рада (1180-1247). Хәтта Кордовада яшәп, бихисап китаплар язган Разис исемле гарәп тарихчысы да «уйлап чыгарыла»*[6].



Чыңгыз ханның тәхеткә менүе.
Марко Поло гравюрасы

Кыскасы, Чыңгыз хан сурәтенең XVIII гасырга «тартуы» безне һич гаҗәпләндерми, чөнки «Бөек монголлар тарихы», Несторның елъязмалары, Монголстанның тәүге картасы һәм тагын бик күп бәхәсле «чыганаклар» нәкъ менә шушы гасыр азагында һәм, бигрәк тә, XIX гасыр башында «табыла».

Чыңгыз ханга бәйле репродукцияләр арасында янә бер билгеле Кытай рәсеме бар. Анысы рәсми портреттан да соңрак ясалган: хан бөтен буйга баскан, монгол башлыгыннан, уң кулында – монгол җәясе, сул кулы кыныга салынган кылыч сабын тотып тора.

Дәрәҗәле, абруйлы галимнәрнең хезмәтләренә дә күз төшерик. Л.Н.Гумилев «Борынгы Русь һәм Бөек дала»[7] китабында Чыңгыз ханны болай сурәтли: *«Ельязмачылар мәгълүматларына һәм Манҗуриядә табылган фреска калдыкларына караганда, борынгы монголлар озын буйлы, сакаллы, зәңгәр күзле һәм аксыл чәчле булган... Тимучин – мәһабәт гәүдәле, киң маңгайлы һәм озын сакаллы, сугышчан һәм көчле шәхес. Ул башкалардан шуның белән аерылып торган».*

Теманы яхшылап өйрәнгән галим А.Г.Оловинцов, бихисап материаллар бар-

---

[2] Дээл –монгол һәм төрки халыкларының милли киеме.
[3] Сергей Волков. Письменные источники о Чингисхане. *https://studopedia.su/13_147790_pismennie-istochniki-o-chingishane.html*
[4] Рашид-ад-дин Фазлуллах. Джами-ат-таварих. «Нагыл Еви»: Баку. – 2011. *https://anl.az/new/upload/File/berpa/berpa-19-file.pdf*
[5] Нәсара – нәсара (христиан) динен тотучы.
[6] У.Топпер. Выдуманная история Европы. – М.: 2006, стр. 212.
[7] Л.Н.Гумилев. Древняя Русь и Великая степь. *https://booksonline.com.ua/view.php?book= 167157*

лаганнан соң, Чыңгыз хан... монгол булмаган (!) дигән фикергә килә[8]. Рәшидеддин «Җәми әт-тәварих»та искәрткәнчә, Чыңгыз хан Бөрҗигин (бу сүз үзе дә «зәңгәр күзле» дип тәрҗемә ителә) нәселенә караган, аксыл чәчле, зәңгәрсу күзле булган. Бу сыйфатлар монголларның антропологик тибына туры килми. «Монголлар һәм татарлар тарихы» китабында Габделгази Баһадурхан да Бөрҗигиннәрнең *«яшькелт-зәңгәр»* яисә *«куе зәңгәр, бәбәге көрән төс белән каймаланган»* күзле булуы турында яза[9].



Чыңгыз хан үлем түшәгендә

Бөек Татариягә килеп, әлеге дәүләтне һәм аның халкын тәфсилләп язып һәм ясап калдырган Көнбатыш шәхесләре арасында Марко Поло да бар. Ни гаҗәп, ул монгол чалымнарына ия бер генә кешене дә сурәтләмәгән... Аның гравюралары арасында атаклы «Чыңгыз ханның тәхеткә менүе» дип аталганы да бар.

[8] А.Г.Оловинцов. Тюрки или монголы? Эпоха Чингисхана. *https://history.wikireading.ru/ 328053*
[9] Histoire des Mogols et des Tatares, par Aboul-Ghasi Behadour Khan publiee, traduite et annotee par le Baron Desmaisons, t. II, St.-Pbg., 1874, p. 72.

Чыңгыз хан һәм аның хатыны. ***Пьер Дюфло гравюрасы***

Чыңгыз ханның оныгы Батуны да монголга охшатып ясамаганнар. Әйтик «Батуның 1238 елда Суздальне алуы» рәсемендә (XVI гасыр) хан – чын европеоид.

Фән ышанычлы адымнар белән алга бара. Ул җәһәттән, Life.ru сайтындагы мәгълүматка игътибар бирик: *«Чыңгыз хан торыннары булырга ихтимал затларның җәсәдләрен тикшергәннән соң шуны әйтергә мөмкин: аларның бабалары – Европа халкына хас гаплогруппа вәкиле».*

«Асия картасы»ның фрагменты

«Чыңгыз хан үлем түшәгендә» дип аталган рәсемдә хан һәм аның дүрт улы ясалган. Аларның берсе дә монголоид түгел. Француз Пьер Дюфло гравюрасында Чыңгыз хан үзе дә, ханша да Көнбатыш Европа монархлары кебек сурәтләнгән.

Бөек җиһангирның торыны да 1590 елгы «Асия картасы»нда (авторы – Даниель Келлер) монгол кыяфәтле итеп бирелмәгән. *«Бөек хан, яисә Тартария императоры биләмәсе Азия Сарматиясен, Скифияне, бүген Катай, Чагатай һәм Төркестан дип атала торган Серика провинциясен үз эченә ала»,* – дип язылган үзгә бер чыңгызый төшерелгән рәсем астына.

Чыңгыз хан ауда

Бөек Татариядә булып киткән ничәмә-ничә сәяхәтчеләрнең гади татарларны да, Чыңгыз ханны һәм аның нәселен дә монголоид итеп түгел, европеоид итеп сурәтләве очраклы хәл була аламы? Юк, әлбәттә. Алар татарлар белән монголларны бутамаганнар. Бүгенге галимнәрнең байтагы «монгол – могол» төшенчәләрендә аерма күрмәскә тырышса да, болар икесе ике сүз, ике халык. Мәктәп укучысы да белә: Бөек моголлар империясе – монголлар иле түгел, татар дәүләте ул! Алайса нигә шундый ялганга барыла, тупаслыклар кылына соң? Җавап гади: чөнки... шулай кирәк, шулай гадәткә кергән!

Дөньяның игътибары бер рәсемгә ябышты да, шуннан һич куба алмый; аны «кануни», «тарихи» дип күтәрә, җитмәсә; югыйсә, ул – аноним автор эше, схематик рәвештә ясалган монгол картының сурәте... Әмма берни эшләтеп булмый: тарихи традиция шундый – монгол-татар чырае кирәк, ихтыяҗ – аңа! Бу мәсьәләдә соңгы елларда гына кечкенә бер уңай үзгәреш күзәтелде: дәреслекләрдән «монгол-татар игосы» төшенчәсе төшеп калды... Аннан гайре барысы да әлегә шул ук хәлдә. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

«Бакыйга мәхәббәте куәтле иде...»

(Иганәче Әхмәд бай Хөсәенов)

Ләлә Мортазина

Әхмәд бай

Тарихка XIX-XX гасырлар чигенең иң бай татар сәүдәгәре буларак кереп калган Әхмәд бай Хөсәеновның милләте өчен кылган игелекләре әйтеп бетергесез дәрәҗәдә күп һәм төрле. Яшүсмер вакытта үз хезмәте, үз кул көче белән эшләп тапкан биш сум акчадан башланып киткән эшчәнлек аны Россиянең иң атаклы эшмәкәре һәм хәйриячесе, заманының иң абруйлы шәхесләренең берсе дәрәҗәсенә күтәргән.

Әхмәд Гали улы Хөсәенов 1837 елда Сәет Каргалысында дөньяга килә. Ата-бабалары бу якларга Казан губернасының Кибәхуҗа авылыннан күченеп килгәннәр, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр. Бөлгенлеккә төшеп вафат булган әтисеннән яшьли ятим калган Әхмәд гаиләнең төп терәгенә әверелгән. Вак-төяк әйберләр сатудан башланган эш, һәрбер тиеннең кадерен белгән яшүсмернең тырышлыгы, сакчыллыгы, гадилеге, көндәлек тормышта аздан да канәгать була, уйлый белүе һәм гаделлеге аркасында, бик нык алга китә, ә ул үзе чын мәгънәсендә татар миллионеры булып җитешә.

Иске тәртипләргә корылган мәдрәсәдә укып, тиешле белем туплый алмаган Әхмәд бай, заманының яңа карашлы мәгърифәтчеләренең милләтне алга җибәрү, үстерү өчен, иң беренче чиратта, аның мәгарифен үзгәртеп корырга кирәк дигән фикерләренең дөреслегенә инанган. Шуңа да яңа ысул, заманча шартларга нигезләнгән җәдид мәктәпләренә матди яктан ярдәм итәргә тырышкан – мәктәп-мәдрәсәләр өчен биналар салган, мөгаллимнәргә хезмәт хакы түләгән, уку әсбапларын бастыруга зур әһәмият биргән, шәкертләргә булышкан. 1889 елда Оренбург шәһәрендә ачылган мәшһүр «Хөсәения» мәдрәсәсе дә бертуган Хөсәеновларның тырышлыгы һәм матди ярдәме белән барлыкка килгән. Моннан тыш, Әхмәд бай Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен дә үз ярдәменнән ташламаган, илнең төрле почмакларында 20дән артык мәчет-мәдрәсә бинасын торгызган. Вафаты алдыннан ул үзенең ярты миллионга якын акчасын милли мәгарифне үстерү өчен васыять итеп калдырган. Бу акчага дистә ел дәвамында никадәр җәдид мәктәп-мәдрәсәләре эшләп килгән, анда күпме татар шәкертләре укыган, сәләтле яшьләр хәтта чит илләргә дә барып белем алган.

Татар тормышына яңалыклар кертергә омтылган Әхмәд бай Хөсәеновның хезмәте замандашлары, фикердәшләре, зыялылар тарафыннан танылган, ул үзе хөрмәткә ия шәхесләрнең берсенә әйләнгән. Ризаэддин Фәхреддин 1910 елда аңа багышлап «Әхмәд бай» дигән китабын, Галимҗан Баруди исә мәкаләләр язып бастырган. 1906-1907 нче елларда, Әхмәд байның вафатыннан соң, татар газета-журналларында күпсанлы кайгынамәләр, истәлекләр, мәкаләләр дөнья күргән. Татар кешеләре, мөселманнар өчен ул изгелек һәм игелек үрнәге булып хезмәт иткән.

Ризаэддин Фәхреддин, Әхмәд байның милләте файдасына кылган игелекләрен искә алып, күрсәткән хезмәтләренә чын мәгънәсендә сокланып, аны «үзенең заманында вә гасырдашлары арасында һимммәте *(тырышлыгы)* иләә мәшһүр, гакыллы, хәмидле *(мактаулы)*, диндар вә милләтпәрвәр» зат дип атый. Әхмәд бай белән дистә ел тирәсе дустанә аралашып, фикерләшеп яшәгән галим, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең җитәкчесе Галимҗан Баруди, татарның иң атаклы баеның шәхесенә һәм кылган эшләренә зур бәя биреп, 1907 елда «Әд-дин вә әл-әдәб» журналының 9 нчы санында бас ылып чыккан «Әхмәд бай» дип исемләнгән мәкаләсендә аны «гакылы куәтле, фәһеме үткен, фикере тугры, милләтенә хәерхаһ (теләктәш), әһле дин өчен гамхор (кайгыручы), хәйратендә (изге эшләр) нияте дөрес, эшләрендә икъдамлы (тырыш) вә җәсүр (гайрәтле), әтрафы өчен хәмитле (мактауга лаек) вә гаюр (булдыклы), заманның бик сирәк туа вә бик сирәк үсә торган әүляденнән (улларыннан) иде», – дип сурәтли.

Әхмәд бай вафатыннан соң, «Әд-дин вә әл-әдәб» журналы битләрендә Г.Барудиның мәшһүр хәйриячегә багышлап язылган тагын берничә мәкаләсе дөнья күрә. Укучылар игътибарына әлеге мәкаләләрнең берничәсен тәкъдим итәбез. Текстлар бүгенге телгә якынайтып бирелде. Гарәп-фарсы чыгышлы сүзләргә аңлатмалар җәяләр эчендә күрсәтелде.

Әхмәд бай

Галимҗан Баруди

Виладәте *(тууы)* – 1837.
Мөддәт хәяте *(яшәгән елы)* – 69.
Вафаты – 1906.

Әхмәд бай Казан вә Болгар мәмләкәтендә вә билҗөмлә *(барлык)* Русия табигълыгында *(кул астындагы халык)* иң мәшһүр адәмнәрдән иде. Бу затның вафаты бөтен мәмләкәт өчен дә зоһур иткән *(мәйданга килгән)* вакыйгаларның олугларыннан вә бөек хадисәләреннән *(вакыйгаларыннан),* бәлки, тугрысы, бөек фаҗигаләреннән саналса дөрестер.

Әхмәд байның тәрҗемәи хәяте җәһәтләренчә – дәүләт хасыйл итүе, гакылының сафлыгы, фикеренең тугрылыгы, һиммәт вә гайрәтенең бәләндлеге *(бөеклеге),* милләт өчен хәерхаһлыгы, хак вә растлык өчен иҗтиһады *(тырышлыгы)* вә тәгассыбы *(үз милләтен чиксез сөюе)*, хак вә дөреслекне һәрнәрсәдән вә һәркемнән олуг күрүе вә алдан тотмагы кеби хәлләре – надир *(сирәк)* күренә торган, бәлки, надир ишетелә торган рәвештә вә һәркем өчен бер дәресе гыйбрәт диярлек дәрәҗәдә иде.

Таныганнар хәлләре вә каләләре *(сүзләре)* берлә, танымаганнар, әлбәттә, фәкать, хәлләре берлә минем ошбу догама кушылачаклардыр: «Йа Аллаһ! Яхшы нияттә вә дөрес игътикадта *(ышану-инануда)* хәлдә гомере түгәнгән вә дин ислам файдасына кылганыбызныңча яхшылыгын азсынган хәлдә, дөньядан кайткан вә егылган зәгыйфь бәндәң – Әхмәд байны ярлыкасаң иде. Фазыйль *(өстенлек)* вә ләтыйфың *(гүзәллегең)* берлә рәхмәтеңә алган булсаң иде. Кылган хәйратен, вә васыятьләрен бәрәкәте, вә үзе өчен кыяմәттә фида *(корбан),* вә багыйс *(сәбәпче)* рәхмәт, башкалар өчен сөннәт хәсәнә, вә изге үрнәк кылсаң иде. Варисларына калдырган малларын да хәерле вә бәрәкәтле, калдыручы вә алучыларның дин вә ахирәтләре өчен файдалы итсәң иде. Амин! Йа Раббелгаләмин вә йа мөҗиб әссаимин!»

Әхмәд байның нәсәбе вә асыл ватаны

Әхмәд бай – Казан вилаяте Кибәк Хуҗа нам карьядән *(авылдан)* күчеп, Оренбург җиварында *(тирәсендә)* булган Каргалы бәлдәсенә *(Сәгыйдь бистәсенә)* урнашкан яки шул шәһәрне Сәгыйдь бабай берлә тәшкил иткән зат нәселеннәндер. Соңгы бабасы Хәсәен бай ибн Гобәйдулла яхшы дәүләтле вә халык ара игътибарлы бай адәм булып, Каргалыда үз мәхәлләсендәге хәзерге 5 нче мәчетне, янганнан соң, 1230 нчы сәнәдә *(һиҗри)* бина иткән. Хәзерге агач мәчет аның бинасыдыр. Вәләкин аның угылы Гали бай печә булып үскән. Бай печәләрнең әксәрендә *(күбесендә)* күрелгән вә ишетелгән рәвешчә, сәфахәт *(кирәкмәскә мал исраф итү)* вә гыйшрәт *(ашау-эчү, кәефләнү)* кеби әхлаксызлыклар бичара Гали аганы да куймаган, малдан вә әхбабтан *(дуслардан)* аерган. Аяныч хәлдә гомерен тәмам итеп, Габделбакый, Әхмәд, Габделгани, Мәхмүд, Габдерахман вә берничә кызларны сабый вә ятим хәлдә калдырып, Илек кальгасында дөньядан кайткан. Аллаһы Тәгалә ярлыкагай!

Соңра Әхмәд бай вә борадәрләре Каргалыда – асыл ватаннарында торып, байтак мая хасыйл иткәннән соң, Оренбургка күчеп, ахыргы 10 елда борадәрләре берлә бүлешкәннән соң, Казанны ватан итеп, Казанда чагында ахирәт йортына күчте.

Әхмәд байның укышы һәм тәрбиясе

Әхмәд байның әүвәлге хәле, мәктәп вә валидәсе *(әнисе)* Хәмидә ханымнан алган тәрбиясе вакыты күп өметле түгел. Вә күп хикмәи тарафларыннан хуш күрелми вә мактаулы булган балаларның шук вә нәшатлы *(шат, энергияле)* хәлдә булулары, Әхмәд байда хәйлә куәтле булган булса да, Каргалы мәктәбенә 4-5 кыш барыш-килеш кыла торып, язу, укырлык-язарлык мәртәбәсенә ирешә алмаган. (Бу шәрәфәт өч борадәрнең һәркаюсында бар иде, берсе дә мәхрүм түгел.)

Баланың шуклыгы вә шаянлыгы өметле вә мактаулы дигән идек. Кыска уй берлә, бу сүзне ятсынучылар, бәлки, булыр, ләкин бу мәсьәлә гыйльме табигыять буенча сәбат *(исбат ителгән)* вә тәҗрибәләр моңа шаһидтыр. Чөнки сабыйда булган шуклык, табигатендә булган уяулык вә калебендә булган үткерлек димагында *(баш миендә)* булган саулыктан гынадыр.

Әгәр бер бала, карчыклар яратканча бик инсафлы, юаш, сүрән булса, ул балада артык өмет булмас, ул табигате берлә бер эштә кәмаль *(камиллек)* таба алмас, артык яхшылыкны да булдыра алмас, ялкаулык вә пәстлектән *(начарлыктан)* башка яманлык та кулыннан килмәс вә һич эштә *(дөнья вә ахирәт эшләрендә)* һиммәт *(яхшы нәтиҗә)* чыгара алмас. Бу тугрыда борынгы болгар картларыбызның: «Балаң булса, шук булсын; шук булмаса, юк булсын!» – дигән сүзләре – бик дөрес, хикмәтле сүздер.

Мәгәр шук бала тәрбиягә вә саклауга, башкадан артыграк тәрбиягә мохтаҗдыр. Зарарлы балалардан сакланса, яхшы тәрбия вә тәгълим ителсә, затында булган истигъдад *(сәләтлелек)* вә үткерлекне ул бала тиешле урында истигъмаль итәр *(кулланыр),* үзенең инсанияте вә исламияте өчен гүзәл корал итәр.

Галимҗан Баруди

Әгәр, билгакес *(киресенчә)*, мондый бала яхшы сакланмаса, тиешле рәвешчә үзгәртелмәсә, бала үзенә очраган кешедән гадәт үгрәнер, яманнарга да күп очрар, сохбәт итәр *(аралашыр)*, үзенә төрле авырлыклар, афәтләр йоктырыр, әхлагы бозылыр, үзенә һәм милләтенә зыянлы булыр. Бу эштә баш гаепле ата вә ана булып, азак гаепле һәлак булган бала үзе булыр.

Әхмәд байның укыган мәктәбе тәртипле, хәлфәсе ысуллы укыту бабында мәгърифәтле кемсәнә булган булса, аның шул холкы укуына зыян итмәс, бәлки, күп файда иткән булыр иде.

Укыткан хәлфәсе Каргалыда мәхәлләсенә мәзин булган иде. Бер Каргалыда мәҗлестә мәктәпләрне ислах итү кирәк, укулар, укытулар тәртипле булу зарур дигән сүзләр ачылса, хәлфәсенә үпкәләп, мәзин абзыйга: «Сабак өчен ничә еллар йөрдем, яхшы сәбат берлә укытмады, юаш булды, мине надан калдырды»,– диеп, уенлы-чынлы гыйтаблы *(шелтәле)* хитаб иткән *(эндәшкән, мөраҗәгать иткән)* иде.

Валидәсе *(әнисе)* байтак тәдбирле *(алдан күрүчән)* вә диянәтле хатын булдыгыннан, ашамак-эчмәк, ятмак-тормак әдәпләрен вә бәгъзе догалар өйрәткәнен үзе сөйләр иде. «Иман шарты» рисаләсе ахырында булган гакыйдәи мәнзумәне *(шигырь белән язылган хикәяне)* вә «Кырык фарыз» рисаләсен яттан белә иде. «Сүрәи Бәкара»ның ахырын *(өч аятьне)*, «Аятел-Көрси» вә саир *(башка)* байтак догалар ятында иде. «Вә мин йаттакъ Аллаһу...» аятен күп укыр иде, күп заманнардан бирле вә бу аятькә мөдавамәт кылганын *(үзгәртмәвен)* сөйли иде. «Сүрәи Ясин» вә «Сүрәи Мөлек» сүрәләрен вә Мосхәф шәриф *(кадергә лаек Коръән)* йөзеннән танып укыр иде.

Язудан шәй: вексель вә чек кәгазьләренә, хатларына вә дәфтәрләренә кул куярлык тамга берлә язу арасындарак чамалап танырлык кына «Әхмәд Хөсәенов» дип татарча вә русча кул куя иде. Русча кул куюны, Мәскәүдә банкка чек кәгазьләренә кул куясы булгач, Сабирҗаннан күчергеч яздырып, бер кичтә өйрәндем, дия иде. «Язу танымый, яза белми үләргә ярамый, бер гайрәт кылып өйрәнсәм иде», – диеп әүвәлрәк сөйләсә дә, соңгы заманнарда ишгале *(шөгыльләре, эшләре)* күбәеп, гайрәте азаеп, үзе картаеп, ул сүзен онытты.

Әхмәд бай. Диянәт вә әхлагы

Дин гыйлемен аз укыган булса да, диндә салабәте *(ныклыгы)* вә мәхәббәте яхшы, намазын һич куймас, казага калдырмас, намаз үтәрдәй булса, кем өендә булса да, тәһарәтсез булса, тәкәллефсез генә, кешене мәшәкатькә төшерми, тышкары өйдә булса да тәһарәтләнеп, намазын үтәр иде.

Бик эшле вә хирысы куәтле вакытларда да һәр намазын сөннәтләре вә камәте берлә үтәр вә галибән *(күп вакытта)* ахырда «Аятел-Көрси» вә тәсбихларны укыр иде. Әһле Гайшә бинте мулла Габделгалләм ибн Әш-шәех Дәүләтшаһ бин Гаделшаһ нәкыленә *(сөйләвенә)* бинаән *(нигезләнеп)*, иртә вә кичке намазлар соңында «Сүрәи Бәкара»не ахырыннан-ахыргача өч аятьне укымый калдырмас вә күп вакытларда иртә «Сүрәи Ясин»не вә кичләрдә «Сүрәи Мөлек»не укыр иде. Намазсыз кемсәнәне аслан сөймәс иде. Һәркемнең сирәтендә *(көнкүрешендә, әхлагында)* булган намазына күз салыр, вә намазында мөсаһәләле *(йомшаклык күрсәткән)* кеше булса, аннан хәер көтмәс иде. Белмәгән нәрсәсен үгрәнүдән тартынмас вә оялмас иде. Укыган нәрсәсен *(дога, зикер вә намаз)* мәхәббәт вә хөлус *(ихласлык)* берлә укыр иде.

Анасыннан өйрәнгән «Йә Хәннан вә йә Мәннан, саббит кальби галиел-иман...» догасын даими укыр. «Гыйбарәм дөресме вә иманны сакларга файда итәрме?» – диеп сорар иде. Сөә хатимәдән *(ахыргы бәхетсезлекләрдән)* вә кыямәт әхваленнән бик куркыр, касавәт *(рәхимсезлек)* калебеннән күп шикаять итәр иде. Аллаһның гыйбадәтенә үзен косурлы *(кимчелекле)* вә гөнаһлы күрер иде. Кылган гыйбадәтен вә хәйратен *(изге эшләрен)* аслан күрмәс – кешене кызыктырыр өчен генә булмаса, аслан белдермәс вә сөйләшмәс иде.

«Акчаның һәр тиене Аллаһтан бәндә кулына амәнәт, кайда куела, кемгә бирелә, Аллаһ каршында хисабын биргәндә оят килмәслек кылырга кирәк. Акчаны Аллаһ разый булырлык урынга сарыф итәргә кирәк».

Диянәтле, һөнәрле, эшлекле, халыкка файдалы кешеләрне сөяр, аларга кирәгенчә ярдәм итәр иде. Ялкау, тамгыкяр *(саран, комагай)*, акча хисабын белмәгән байбичә, үзенең вазыйфасын белмәгән мулла аның каршында кадерле түгел иде. Акча саклый белмәгән, хәрамга тоткан яки хәләлгә кирәгеннән артык тотып исраф итүче кешене яхшы санамаенча, акчасын үз кулына тапшырмак, тәсаррыфларын *(сарыф иткән малын)* үз ихтыярына бирмәк шәриган дөрес түгел, бәлки, мондый кеше малы сабый хөкемендәдер. Кирәгенчә генә биреп торырлык, малын яхшы сакларлык яки арттырырлык ышанычлы мөтәвәлли *(попечитель)* куелып, бар эшен аңа тапшыру тиешледер.

Мөселманнар, яхшы түгел, дигән булып, шәригатьнең бу хөкемен игътибар итмичә, күп мөселман балаларын вә күп кешенең малларын заигъ кылалар. Дин вә шәригать каршында мал – хәерле нәрсә, саклавы лязем *(тиешле)*, һәркем үз малын да, милләт малын да сакларга тырышсын. Тугры вә, кыскасы, үз баласына да, дин кардәше баласына да хәерхаһ булсын. Вәссәлам. [...]

Әхмәд байның хәятендәге хәйраты

Әхмәд бай акча сөяр вә аны бик якын саклар адәм иде. «Акчаның һәр тиене Аллаһтан бәндә кулына амәнәт, кайда куела, кемгә бирелә, Аллаһ каршында хисабын биргәндә оят килмәслек кылырга кирәк. Акчаны Аллаһ разый булырлык урынга сарыф итәргә кирәк», – дияр иде.

Бинаән галәйһи *(шуның өчен)*, ачык, тиешле урын күренгәндә акчаны сарыф итә иде. Миһман дус *(кунакчыл)* иде. Өендә аш вә чәе кунаксыз бик сирәк үткәндер. Аурупада вә аның тәклиденә *(традицияләренә)* ихласлы булган Казанда көннән-көн бетә барган Шәрык гадәте вә ислам сөннәте булган миһман, дуслык гади вә йауме тәгамне *(сый мәҗлесен)* дә галибән миһман *(мәртәбәле кунаклар)* берлә үткәрү Әхмәд байда куәтле иде.

Хәйрат бакыйга *(мәңгелек әйберләргә)* мәхәббәте куәтле иде. Кай җирдә мәчет вә мәдрәсә зарурлыгын аңласа, ярдәм итәр вә яхшы рәвештә аны торгызуга тырышыр иде. Кылган гыймарәтенең *(төзелешнең, корылманың)*, фәкать, кылган сурәте күркәм булуына игътибар итмичә, яшәвенә вә бәкасенә *(мәңгелегенә, ныклыгына)* дикъкать итәр иде.

«Бертуган Хөсәеновлар Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсе җитәкчесе Хәйрулла Госмановка мәгарифне яңарту эшендә матди һәм рухи ярдәм күрсәткәннәр»

Галимҗан Баруди чыгарган «Әд-дин вә әл-әдәб» журналы. 1907 ел

Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсе бинасы

Бинаән галәйһи, агач гыймарәткә *(биналарга)* мәел итмәс *(кызыкмас)*, бәлки, тау ташыннан гыймарәт итәр *(төзетер)* иде. Таштан тәгъмир *(төзү)* тарихын ибтидаи Оренбург шәһәрендә үз мәхәлләләрендәге бөек мәчетне вә башка җирләрдә дә таштан гыймарәтләр итеп, тәҗрибәсе соңында Казанга килгәч һәм шул эшкә игътибар итеп, халыкка аңлатты. Кирпечкә күрә байтак арзан вә чыдамы аз түгел, юнәтүе вә гыймарәте бик җиңел булган таштан мәчет вә мәдрәсә салуны халыкка күрсәтте вә, димәк, мәйданга чыгарды.

Әхмәд бай урынсыз сурәттә мәхыз *(фәкать)* күренеш вә атакъ өчен мал сарыф итүне сөймәгәне сәбәпле, мәчет яки мәдрәсә салачак урынны бик тикшерер иде. Мөҗәррәд *(ялгыз)* бер мулланың вә башка кешенең кирәк димәгенә ышанып кына эшкә керешмәс иде, бәлки, зарурәт вә ихтыяҗны аныклагач кына керешер иде. Әхмәд бай бу эшендә бик хаклы иде, чөнки күп мәчетләр зарурәтсез гыймарәт итәләр. Фәкыйрь карьяләрдә күп булганымнан вә күп мәчет таләбәләренә *(шәкертләре белән)* мөлакатем *(танышлыгым)* булганга, кирәксез салынган мәчетләрнең күп икәнен ачык беләмен. Шәкертләргә урын кирәк булганнан яки бер кызга кияү кирәк булганнан, әүвәлге муллага ачу вә үпкә булганнан мәхәллә аерып, заруратән шәргыясез *(кирәге булмаганга)* мәчет гыймарәт кылу *(салдыру)* аз түгелдер. Мәчет күбәю берлә дин куәтләнә дигән, намаз укый белүче бармы-юкмы – аны тикшерми мәчет салучы надан, фикерсез байлар күп акчаларын урынсыз сарыф иткәннәр. Бер мәчет «Госмания» мәдрәсәсе бинасы икешәр-өчәр мәчет салганнар, мулла күбәйткәннәр. Бер мәчет җитәрлек авылларга икешәр-өчәр мәчет салганнар, мулла күбәйткәннәр. Бу эшләре берлә дини вә әхлакый файда арттырганнармы, юкмы? Халыкны бүлгәннәр, өсләренә йөк арттырганнар. Дин вә намаз өйрәнер өчен мәдрәсәләре бармы? Булса, укытучы бармы-юкмы? Булса, яхшы укытамы, юкса, фәкать, алай-болай юатып кына гомер үткәрәме? Мондый эшләрне вә дин куәтләр өчен иң кирәк нәрсәләрне тикшермиләр. Безнең Әхмәд бай бу ялгыштан котылган, мондый түбән фикердән күтәрелгән иде.

Әхмәд бай хакында «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» тарафыннан мәрсия

Һәртөрле кеше туар җир йөзенә,
Бай булыр, яхуд фәкыйрь язмышында.
Остаз мәгълүм шәкертле булган кебек,
Байларның нәтиҗәсе - хезмәттер.
Файда юк, акча җыю булса максуд,
Андый байдан милләт булмас аслан[1] мәсгуд[2].
Шуның өчен, малың булса, газиз баем,
Тәрәккый вә мәгарифкә акчаңны тот.
Ләкин мондый байлар күп табылмас,
Табылса да, бу дөньяда мәңге тормас.
Бәгъзе вакыт төшеп тә югаладыр,
Бик кадерле булса да кечегә алмас.
Менә бу ел Әхмәд бай Гали угылы
Рәхәт урынын күрмәгә рихләт итте[3].
Вәләкин милләтенә зур тәәссеф[4] –
Бер дә хәләф[5] калдырмый күчеп китте.
Җеназасы сишәмбе көн күтәрелде,
Бу көндә милләтебез әсәф итте[6].
Хосусан «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»
Дәресләр туктату бән матәм итте.
Мәдрәсәнең маддәтән атасы иде,
Җитмәгән күп җирен җитештерде.
Атадан ятим калган бала кеби
Боегып, аһ ормак инде калды.
Һәр шәкертнең авызында Әхмәд ага,
Яхшыларның күчүенә хәйран кала.
«Рәхим Аллаһ рәхмәтән вә әсгане», -
Чын күңелдән җөмлә шәкерт дога кыла.

(«Дин вә әдәб», 1907 ел, 13 нче сан.)

Текстларны басмага ***Ләлә Мортазина*** *әзерләде.* ■

[1] Аслан – һич тә.
[2] Мәсгуд – бәхетле.
[3] Рихләт итү – күчену.
[4] Тәәссеф итү – кайгыга төшү.
[5] Хәләф – алмашчы, дәвамчы.
[6] Әсәф итү – кайгыру, борчылу.

Болгаер табылдыклары – Финляндиядә

Хәмзә Бәдретдинов



Болгаерның 1883 елгы планы

1985 елда Казанда «Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье» исемле фундаменталь китап нәшер ителгән. Монда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре тарафыннан Идел буеның уң ярындагы районнарда һәм Зөя бассейнында сакланган, палеолит чорыннан алып урта гасырның соңгы елларына нисбәтле 800гә якын археология һәйкәле теркәлгән. Галимнәр Альфред Халиков, Рөстәм Габәшев, Светлана Кузьминых тарафыннан басмага әзерләнгән әлеге белешмәдә Олы Болгаер ядкярләре 536

нчы сан белән исәпкә алынган. Аңа мондый аңлатма бирелгән: «В.И.Зусайлов коллекциясе тупланмасындагы кыска саплы сөңгенең (дротикның) дәфнә агачы яфрагына охшаш каләмне хәтерләтүче очлыгы (№3364), сөңгенең уртача тишекле очлыгы (№3354), сөңгенең зур тишекле озынча-түгәрәк каләмле очлыгы (№3355), ике колаклы кельт (№3270), кельт-аркылы ике балта (№3256, 3257) бар. Аларның барысы да ананьино культурасына кадәрге хронологик горизонтта яталар, казан тирәлегендә табыла торган борынгы ядкярләргә нисбәтлеләр».

Әлеге коллекция, шул исәптән Болгаер ядкярләре дә Финляндия милли музеенда саклана. Идел алды археологик картасын төзүдә катнашучы галим Рөстәм Габәшев әйтүенчә, аларны коллекционер В.Зусайлов чит илгә сатарга мәҗбүр булган. 1916 елда А.М.Тальгрен Хельсинки шәһәрендә бу бай мирасның тасвир-



Болгаер табылдыклары. ***А.Халиковның «Приказанская культура» дигән китабыннан алынды.***



Болгаерда табылган сөңгеләрнең бронза очлыгы (1,4 нчесе).
А.Халиковның «Приказанская культура» дигән китабыннан алынды.

ЗУСАЙЛОВ Василий Иванович (1845-1913) – Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. Казан шәһәре музееның беренче директоры. Борынгы әйберләрне һәм археология табылдыкларын бик илһамланып җыючы коллекционер. В.И.Зусайлов хәзерге Апас районы территориясендә табылган дистәләрчә археологик ядкярне үзендә булдырган. Аның 11 мең данә предметтан торган кыйммәтле коллекциясе, язып үтелгәнчә, хәзер Финляндиянең милли музеенда саклана.



Апас төбәгенең нинди бай археологик мирасы бар. «Карта археологических памятников Волжско-Камской Булгарии (X-первая пол. XVвв.)»дан фрагмент

ламасын бастырып чыгаргач, Болгаер табылдыкларын фәнни әйләнешкә кертүгә юл ачылган. Бер китаптан икенчесенә күчеп, әлеге рухи хәзинәгә кагылышлы кайтаваз безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Галим Зөфәр Мөхәммәтшин тәкъдим иткән берничә җыентыкны күздән кичереп, Болгаер табылдыкларына кыскача гына аңлатма бирү белән чикләник.

Менә Б.Тихоновның «Урта Уралда һәм Урал тирәлегендә бронза чорының металлдан ясалган эшләнмәләре» исемле очеркы. Тарихчының бу хезмәте Болгаер табылдыклары белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә. «Сөңгенең уртача тишекле чөй сыман очлыгы 7-13 сантиметрдан озын түгел, – диелә китапта. – Ә беренче төркемгә керүче мондый табылдыкның икесе әнә Апас районының Болгаер авылыннан. Икенче төркемгә керүче сөңгенең зур тишекле очлыгының озынлыгы исә кайчакта 22 сантиметрга җитә. Барлык сөңгеләрдә дә, гомуми озынлыгының өчтән бер өлешен, сапка беркетү өчен, ике тишек ясалган очлык тыккычы алып тора. «Каләм» үзәге күп очракта түгәрәк, әмма кайчакта үзәк буйлап, түгәрәк-ромб формасын биреп, кабырга уза. Кайбер очлыкларның «каләм» үзәге, койганнан соң чүкелгәнгә күрәдер, тыгызлана. Бу үзенчәлек ТАССРның Апас районындагы Болгаер авылы сөңгеләрендә дә күзәтелә».

Дротикларга, ягъни борынгы сугыш коралы булып саналучы кыска саплы сөңгеләргә килсәк, галим болай ди: «Казан тирәлеге, Идел буе сугыш коралларының берничәсен дротиклар төркеменә кертергә мөмкин. Алар ТАССРның Апас районындагы Болгаер авылында табылды. Идел буе дротигы 7 сантиметр озынлыкта, түгәрәкле-ромблы тар үзәкле, яфраксыман «каләм»е тишексез һәм очлыкның ике сантиметр киңлектәге кыска тыккычы бар. Болар барысы да очраклы табылдыклар булып саналганлыктан, датаны билгеләүне кыенлаштыралар. Сөңге белән бергә коелган пычакның безнең эрага кадәрге II гасыр дәвамында кулланылуы билгеле, бу форма Казан тирәлеге культурасы кешеләре яшәгән урыннарга хас. Безнең эрага кадәрге II гасырның беренче яртысында Идел буенда без бер сөңгенең дә коелган очлыгын белмибез. Икенче яктан, кечкенә очлыклар соңрак күренә башлый. Моңа нигезләнеп, дротикны безнең эрага кадәрге II гасыр ахыры-I гасыр башына караган дияргә мөмкин».

Кельт, ягъни аркылы балта – бәлҗә турындагы мәгълүмат та кызыклы. Автор язуынча, «Бронза һәм иртә тимер чорында да СССРның урман, урман-дала төбәгендәге бакыр эшләнмәләр арасында кельтлар – чөйсыман эш кораллары бик киң таралган. Алар аркылы балта яки китмән буларак кулланылган. Әмма мондый эшләнмәләрнең бер өлеше буйга да сапланган һәм балта буларак файдаланылган. Советлар Союзында кельтның иң иртә барлыкка килгәне – сеймин төре. Сеймин кельты Урта Иделдән Алтайга кадәрге урман һәм урман-дала төбәгендә киң кулланылган. Идел буенда мондый ике бәлҗә Апас районының Болгаер авылында табылган. Бу кельтларның алды һәрчак түгәрәкләнә. «Колак»лары начар коела. Кельтларның барысы да кечкенә. Иң зурысының озынлыгы – 7,5; ә иң кечкенәсенеке – 4,2 сантиметр».

Әлеге үзенчәлекләрнең кайберләре Альфред Халиковның Мәскәүдә 1980 елда нәшер ителгән «Казан тирәлеге культурасы» китабында да бәян ителә. Ә шулай да күңелгә сары май булып ягылганы: «Идел-Кама районнары игенчелекне, терлекчелекне, металлургияне җирле кабиләләр арасында беренчеләрдән киң дәрәҗәдә гамәлгә ашыручы булдылар», – дигән сүзләр. Болгаерның борынгы кешеләре менә нинди һөнәрле булган! Уңганлык-булганлык тамырлары, Финляндия музеенда саклаучы дәлилләр раслаганча, менә кая барып тоташа! ■

Апаслылар «Казан каймасы»нда[1]

Барый Мифтахов

Апасның Туган якны өйрәнү музеенда «Казан каймасы»на багышланган күргәзмә: кәтер (мич кырында пешерелгән камыр), мич бәрәңгесе, сохари, киптерелгән кычыткан һ.б.

1941 елның октябре иде. Авылда калган бөтен кешене, шул исәптән уку яшендәге бала-чагаларны туплап мул уңышны җыябыз, фронт өчен ашлык озатабыз. Бүгенгедәй хәтердә, 27 октябрь иде. Мин, партиянең Апас райкомы икенче секретаре, Ворошилов исемендәге колхозда (Зур Әтрәч авылы) урып-җыюны оештырып йөрим. Ашыгыч рәвештә райкомга кайтырга куштылар.

Райкомда бюро әгъзаларын партия өлкә комитеты секретаре А.Г.Барышников, оештыру бүлеге мөдире Е.Р.Федоров һәм республиканың башка җаваплы хезмәткәрләре көтә иде. Район Советы башкарма комитеты әгъзалары, районның бүтән җитәкче хезмәткәрләре дә җыелды. А.Г.Барышников безгә Бөек Ватан сугышы фронтларында килеп туган хәлне һәм Дәүләт Оборона Комитеты карарын аңлатты.

Союзниклар ягыннан хәрби булышлык булмау, Мәскәү янында барлыкка килгән зур кыенлыклар җитди оборона эшләре үткәрүне, сугыш хәрәкәтләре җәелә калса, безнең территориядә зур хәзерлек эшләре таләп итә икән. Дәүләт Оборона Комитеты приказы белән 2 нче хәрби-кыр төзелеше идарәсе оешты-

[1] 1980 елгы әлеге язма Апас районының Туган якны өйрәнү музеенда саклана.

Барый Мифтахов – истәлекнең авторы, Апас райкомының икенче секретаре, Апас районы буенча оборона төзелеше штабы сәяси бүлеге начальнигының урынбасары. Октябрь, 1941 ел

рылган, идарә начальнигы итеп А.Г.Барышников, аның политик эшләр буенча урынбасары итеп Е.Р.Федоров билгеләнгән. Алар безне үзләре белән алып килгән инженерлар, башка белгечләр белән таныштырдылар.

Оборона сызыгы безнең бодай басулары, тау һәм тугайлар, авыллар аша үтәчәк иде. Шуңа күрә районда 1 нче кыр төзү участогы булдыру кирәк дип табылган. Без райкомның беренче секретаре Х.Х.Хәйруллинның участок начальнигы итеп билгеләнүе турында приказ алдык. Начальникның политик эш буенча урынбасары вазыйфасын миңа тапшырдылар. Оборона төзүне оештыру үзәге итеп Биеш авылы сайланды. Райкомның бөтен аппараты белән кичекмәстән шунда киттек.

Мәскәү янында немец-фашист илбасарлары белән көчле бәрелешләр барганда без дәүләтнең гаять җаваплы шундый заданиесен алдык: кыска гына вакыт эчендә шактый зур территориядә танкка каршы траншеялар, ДОТ һәм ДЗОТлар, блиндажлар һәм башка хәрби корылмалар төзергә кирәк инде. Биеш Авыл Советы һәм колхоз идарәсе биналары гөжләп торган штабка әйләнде. Транспорт, тәэминат, финанс һәм кадрлар бүлекләре оештырылды. Аларга җитәкчелек итү партия райкомы һәм район Советы башкарма комитетының бүлек мөдирләренә тапшырылды. Төзелеш өчен агач, таш материаллары, металл әйберләр кирәк иде. Шуны урында булдыру өчен, таш чыгару, урман кисү бригадалары, тимерчеләр группасы төзелде. Аларга җитәкчелек итү дә район звеносының җаваплы хезмәткәрләренә йөкләнде. Төзелеш участогына өч хәрби инженер (Захаров, Тройнин, Дроздовская иптәшләр) бирелгән иде. Шушы белгечләр ярдәмендә, оборона төзелеше мәйданын 8 прораб участогына бүлдек. Районның җидееллык һәм урта мәктәп директорлары Һ.Гомәров, Ш.Исмәгыйлев, И.Галиев, К.Вәлиуллин һәм башка иптәшләргә бу участокларга җитәкчелек итү тапшырылды, алар «прораб» исеме алдылар.

Шушы бөтен оештыру эшләре бер тәүлек эчендә башкарылды. Ә икенче көнне – 28 октябрьдә район хуҗалыкларыннан колхоз председательләренең үзләре җитәкчелегендә һәм массовый төстә оборона төзүгә колхозчылар һәм атлы транспорт килә башлады. Алар арасында хатын-кызлар һәм үсмерләр күбрәк иде. Шулай итеп, колхозларда урып-җыю һәм ашлык сугу эшләрен вакытлыча туктатып торырга туры килде, анда ферма терлекләрен карау өчен генә беркадәр кеше калдырдык. Колхозлардагы атлы транспорт та тулысы белән оборона төзелешенә мобилизацияләнде.

Дүрт ай окоп казыган Равия Таҗиева: «10 кеше бер йортка урнаштык. Ярымач килеш яшәдек һәм эшләдек. Әнием Әгерҗедән 15-16 порция туңдырылган аш җибәрә иде. Анда аз гына токмач, бәрәңге һәм ит булыр иде. Почта аша килгән ашны җылытып, бергәләшеп ашадык. Шул безне ач үлемнән коткарып калды».

Өченче көнне без Саба, Кукмара, Кызыл Юл һәм башка районнардан, Казан һәм Зеленодольск шәһәрләреннән кешеләр һәм җанлы тарту көчләре кабул итә башладык. Оборона төзелешенә эшчеләр – станокларын, колхозчылар басуларын калдырып килделәр. Алар белән бергә интеллигенция вәкилләре, язучылар, журналистлар һәм артистлар да бар иде. Ватан иминлеге өчен халыкның бу патриотик күтәрелеше «Татарстан АССР тарихы»нда гади һәм тыйнак язылган: «Татарстан хезмәт ияләре оборона төзү эшләрендә актив катнаштылар. Бу эшләр бөтен халыкның беренче дәрәҗәдәге мөһим эше дип игълан ителде».

Безнең алда оборона сызыгы төзүгә килгән дистәләрчә мең кешене торак урын, азык-төлек, эш киеме һәм эш кораллары белән тәэмин итү кебек беренче җитди мәсьәлә тора иде. Авылдагы клуб, уку йортлары, башка биналар фатирга әверелде. Колхозчы өйләренә дә дистәләрчә кеше, абзаркиртәләренә атлар урнаштырдык. Бүтән районнардан һәм шәһәрләрдән килгән хезмәт ияләренә торак урынны ашханәдә тукланырга мөмкин булырлык авыллардан сайладык. Булган ашханәләр киңәйтелде, Биеш, Болын Балыкчы, Чүрибураш һәм Ябалак авылларында яңалары ачылды. Моның өчен клуб биналарын файдаландык. Яңа пекарнялар ачарга да туры килде. Ә азык-төлек белән күбрәк колхозлар тәэмин итте, башка эчке резервлар да таптык.

Дошманга нәфрәт кешеләрне бердәм итте, алар теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп, илнең чын патриотлары кебек эшләделәр. Прораблык участоклары, бригадалар, группалар арасындагы ярыш «Явыз дошманны тар-мар итик!» дигән лозунг астында барды. 5 көнгә бер ярышка йомгак ясала, җиңүчеләр билгеләп үтелә иде. Агитаторлар траншеяларда, ДЗОТ, блиндаж, землянка төзелешләренә йөриләр, бөтен яңалыкларны вакытында җиткерәләр иде. 10 көн саен кыр төзү участогының стена газетасын чыгара идек. Монда коммунист М.Гыйсмәтуллин инициативалы эшләде. Безнең күршедә 2 нче кыр төзү участогы киң эш алып бара, анда оборона төзүгә партиянең Буа райкомы беренче секретаре Ш.Ә.Әхтәмов җитәкчелек итә иде. Ике участок арасында заданиене срогында үтәү өчен киң ярыш оештырылды. Ярышка 10 көн саен йомгак ясалды. Идарәнең күчмә Кызыл Байрагы күбрәк безнең участокта була иде. Безнең участок көндәлек планны – 110-120, кайбер бригадалар 150-200 процентка кадәр үтәп килделәр. Бу халыкның искиткеч патриотизм үрнәге, Ватан язмышы өчен зур җаваплылык тоюларын һәм үз өсләренә төшкән бурычны тирәнтен аңлауларын күрсәтү иде.

Окоп казу күренешләре. 1941 ел

Ноябрьнең икенчеункөнлегендә һава кинәт салкыная башлады. Эшчеләргә, бигрәк тә шәһәрдән килгән хезмәт ияләренә җылы киемнәр кирәк булды. Өскә фуфайкалар, сырган чалбарлар табыштырдык. Ләкин аяк киеме белән тәэмин итү кыенрак иде. Монда чабата белән тулага да «мөрәҗәгать итәргә» туры килде.

Жир эшләрен үткәрү кыенлашты. Гади көрәкләр генә җитмәде, лом, тимер чөй, кувалдалар кирәк булды. Районлагы 3 МТС һәм 64 колхозның мөмкинлекләрен барладык, тимерчеләрен мобилизацияләдек. Кешеләр эш коралы белән тәэмин ителде.

Декабрьдә салкыннар 45 градуска, җирдә туң 30-40 сантиметрга җитте. Җир эшләренә махсус сапер взводы чакырырга мәҗбүр булдык. Взвод төнлә туң җирне шартлата, кешеләр аны көндез чистарталар.

Авыр иде. Шундый суыкларга да, сугыш вакыты белән бәйле кыенлыкларга да карамастан, планлаштырылган эшләрнең күләмен билгеләнгән вакыттан алда үтәдек. Немец-фашист гаскәрләрен Мәскәү янында тар-мар иткәч, оборона чиге төзүне туктатырга боерык алдык. Халыкны зурат[2] һәм кибәндәге ашлыкны сугу һәм фронт өчен озатуга тупладык. 1942 елның язгы чәчүенә хәзерлек эшләре дә башланды.

Шинельсез солдатлар дәүләтнең Идел ярындагы ашыгыч заданиесен шулай үтәделәр. Монда күрсәтелгән ныклык һәм хезмәт батырлыгы өчен зур группа иптәшләр бүләк алды. Участок начальнигы Х.Х.Хәйруллин «Почет билгесе» орденына лаек булды. Минем хезмәтем ТАССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән билгеләп үтелде. Мин аны иң авыр елларның кадерле истәлеге итеп саклыйм.

Еллар үтте. Без төзегән оборона сызыгының эзе дә калмады. Ул басуларда хәзер оныкларыбыз – тыныч тормышның кадерле кешеләре җиң сызганып иген үстерәләр, батыр хезмәтләре белән илебезнең оборона куәтен ныгыталар. ■

[2] Зурат — басуда ашлык көлтәләреннән ясалган озынча зур өем.

Омар Хакан*: «Татарлар – бик укымышлы халык!»

(Төркия галиме, тарихчы Омар Хакан Озалп белән Ленар Гобәйдуллин әңгәмәсе)

Тарихчы Омар Хакан Озалп дин галиме Нургали Хәсәновның кабере янында. Буа шәһәре, 10 сентябрь, 2022 ел

– Омар бәй, тәүге мәртәбә татар язма мирасы белән кайчан таныштыгыз?

– 1990 нчы елларда Муса Ярулла Бигиевнең «Рәхмәте илаһия борһаннары» исемле хезмәтенә рәддия язган Мостафа Сабри әфәнденең китабын әзерләгән вакытта танышырга насыйп булды. Муса Ярулла Бигиевнең ике китабын – «Рәхмәте илаһия борһаннары» һәм «Инсаннарның гакыйда илаһияләренә бер назар» рисаләләрен басмага әзерләгәндә татар тарихы, әдәби мирасы белән кызыксынуым көчәйде. Төрле шәхесләрнең иҗатларын өйрәнгәндә бу өлкә мине үзенә алып кереп китте дә башка аерыла алмадым һәм шуңа бик канәгатьмен. Хәзер дә әлеге юнәлештә эшемне дәвам иттерәм. Фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнеп, берничә татар галименең әсәрен Төркиядә таныта алдым. Ризаэддин Фәхреддиннең биографиясен өйрәндем һәм 2000 нче еллар

* Омар Хакан Озалп белән дин белгече Нургали Хәсәновның тууына 170 ел уңаеннан уздырылган халыкара фәнни-практик конференция вакытында Буада таныштык. – *Л.Г.*

башында Истанбулдагы «Дәргаһ яйынлары» нәшриятында аның ике китабын әзерләп бастырдым. Күңелгә аеруча якыны – «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» хезмәте. Бераз соңрак Габдулла Бубыйның «Хакыйкать яһуд тугрылык» исемле әсәрен әзерләдем. Әле тагын Йосыф Акчураның сәяхәтнамәсен дә өйрәндем. Хәзерге көндә биш татар галименең – Габдерәшит Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Галимҗан Баруди, Мөхәммәд Морад Рәмзи һәм Сөнгатулла Бикбулат әсәрләрен төрекчәләштерү белән шөгыльләнәм. Насыйп булса, якын арада аларны да эшләп бетереп, китап итеп бастырырга планлаштырам. Габдерәшит Ибраһимов белән Гаяз Исхакый – хәзерге вакытта Төркиядә киң танылу алган исемнәр. Башка татар галимнәренең исемнәрен дә төрекләргә якын арада танытырбыз дип өмет итәм.

«Татарның һәр гыйлемле инсаны, мәдәниятле кешесе турында укыйм да таң калам»

– Татар язма мирасы Сезнең игътибарны кайсы ягы белән җәлеп итте?

– Сәбәп шунда: татар халкы – безнең кардәш милләт, без татарларны үзебездән һич аерып карамыйбыз. Һәр төрек йөрәгендә, нәкъ башка төрки халыкларга булган җылы мөнәсәбәт кебек үк, татарларга да һәрвакыт хөрмәт-мәхәббәт бар. Татарлар горурланырлык, сокланып сөйләрлек бай тарихка ия. Төрле тарафның көчле басымына каршы тора алган, үз тарихына хуҗа була алган, юлы һәм максатыннан ваз кичмәгән, тамырларыннан аерылмаган көчле халык сез. Иң авыр чорларда да егылмаган, киләчәккә ышанычын саклаган, үз миллиятчелеген булдыра алган халык. Хәйран калырлык бай мираслы халык! XVIII гасыр ахыры - XX гасыр башында, шәхси фикеремчә, кешелек дөньясында иң гүзәл гыйльми һәм мәдәни мәркәзләрнең берсен булдыра алган милләт ул татар. Бу чор миндә гаҗәеп хисләр уятты. Алай гына да түгел, үз мәркәзеннән, ислам мәмләкәтеннән еракта – Япониядә рухи-мәдәни үзәк оештырып, «Япон мөхбире» исемле басма чыгарган, мәчет-мәдрәсәләр салган милләт ул. Татарның һәр гыйлемле инсаны, мәдәниятле кешесе турында укыйм да таң калам.

Татар үз тамырын корытмаган, үткәнен җуймаган, каршылыкларга чыдам, әзләнүчән, дингә тугры милләт булып калган. ИншәАллаһ, киләчәктә дә шундый булып калырлар дип өметләнәм. Дөньяда һәртөрле тарафтан аерым бер милләтләргә көчле басымнар бара. Төркиядә дә нәкъ шундый ук кыенлыкларда яшибез. Аларны узганда татарларга җиңеллек килүен, юлларыннан, максатларыннан аерылмауларын телим. Тамырыбыздан аерып алсалар, исән калмабыз, берләшә дә алмабыз. Үзебезнең тарихи ватаныбызда берләшсәк, яшәптернәкләнеп китү мөмкинлеге, бернинди янау-куркынычларга карамастан, аз булса да, барыбер бар. Ә менә тамырыннан кубарып, башка бер җиргә утырткан агач йә корыр, йә чын-чынлап тамыр җибәреп үсеп китә алмас. Милләтләр белән дә шулай: аннан сүнгән, чәчелгән бер көл генә калыр. Ләкин татарларның күптөрле әдәби-мәдәни чаралар уздыруы, үткәне белән кызыксынуы, борынгы әдәби әсәрләрен кадерләп саклаулары күренә. Мирасны сакларга омтылулары, аларны яңартып бастырулары, галимнәргә кагылышлы биографик, монографик әсәрләр язулары, әсәрләрен кирилл алфавитында яисә факсимилесен дөньяга чыгарулары соңгы елларда ешаеп китте. Шулай дәвам итә күрсен. Бу мирас –

үзе зур байлык бит. Ассимиляциягә бирелдеңме, ул байлык та, төсләр дә, матурлык та юкка чыгар. Киләчәк буыннарда, бәлки, башка мәдәниятккә авышучы бер катлам булып та алыр. Ләкин ул якка таба авышканда да алар үзләренең башкалар астында калуын, алардан ким булуын барыбер күрерләр. Кабат өскә калкып чыгар, үз асылына кайтыр өчен, бәлки, йөзләрчә ел көрәшергә кирәк булыр. Шуңа күрә татарларның читкә авышмаулары, үз тамырларын корытмыйча яшәүләре, үз йөзләрен саклап калулары бик мөһимдер. Бу – минем шәхси күзаллавым.

«Әлеге тема белән кызыксынып кына эшли башлаган идем, аннан туктый алмадым»

– Нургали Хәсәновның китабына кайчан юлыктыгыз?

– Чынлыкта, аның исемен ишеткәнем дә юк иде. Минем монда бер дустым-кардәшем бар. Үзе дә берничә тапкыр Истанбулга килгәч, аны кунак иткән идек. Мәдәни үзәкләрдә, нәшрият йортларында, китапханәләрдә булдык, аңа мөмкин булганча ярдәм итәргә тырыштык. Шул вакытта Нургали ибне шәех Хәсән әл-Казаниның 1907 елда басылган «Әл-гауатыф әл-хәмидия фиссаяхәти нурия» исемле сәяхәтнамәсенә юлыктым. Ул аны Рәшит Амишов исемле кардәшебездән алган булган. Мин кызыксынып укыдым да бу чыганакны гарәп теленнән төрекчәгә тәрҗемә итәргә булдым. Моннан тыш галимнең Оренбургта «Ахун вә мөдәррис Нургали ибне шәех Хәсән әл-Казани әл-Мирзави» исеме белән «58 ел гасырда җәүәлән (Бер йөзьеллыкта 58 ел сәяхәт)» дигән әсәре дә дөнья күргән икән. Аны да төрекчәләштерергә теләдем һәм басмага әзерләдем. Бу хезмәтләргә мәгълүмат рәвешендә бер мәкалә языйм дидем һәм кем ул Нургали Хәсән дип эзләнә башладым. Әлеге тема белән кызыксынып кына эшли башлаган идем, аннан туктый алмадым, өйрәнгән саен, һаман тирәнгәрәк чумдым. Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин, М.Ярулла, Г.Исхакый, Габдерәшит Ибраһимов кебек шәхесләр турында аерым бер хезмәт бастырырга мөмкинлек табарга була. Ә менә Нургали Хәсәнов хакында махсус биографик басма чыгару җае юк иде. Шулай итеп, аның хакында җыйган мәгълүматны тәрҗемә әсәр азагына өстәп куярмын дип уйладым. Саллы гына хезмәт барлыкка килде. 1900-1920 нче елларда дөнья күргән татар матбугатының табылган саннарын, «Вакыт», «Йолдыз», «Казан мөхбире» газета-мәҗмугаларын тикшердем, Нургали хәзрәткә бәйле мәкаләләрне күчереп алдым. Кирилл алфавитындагы материалларны эзләгәндә, Рәшит Амишов кардәшебезнең мәкаләләренә юлыктым. Таба алмаган әсәрләрне миңа Казаннан Данияр Гайнетдинов белән Рәшит Амишов җибәрде. Шулай итеп, алар ярдәме белән китап тулыланды, камилләште.

– Сез белгән Нургали Хәсәнов кем ул?

– Нургали Хәсәнов хәзерге Апас районындагы Морзалар авылында туган. Казанның 4 нче җамигъ мәчете (бүгенге «Зәңгәр мәчет». – *Л.Г.*) каршындагы мәдрәсәдә («Халидия» мәдрәсәсендә. – *Л.Г.*), 1875 елга кадәр Казанның 2 нче мәчет мәхәлләсе каршындагы «Апанай» («Касыймия») мәдрәсәсендә, 1875-1883 нче елларда Бохараның «Мир-Араб» мәдрәсәсендә укый. Аннары

Бохараның бер мәдрәсәсендә укыта. Бохаралы бер ханым белән гаилә кора. Аларның Гыясетдин исемле уллары туа. Улы туганчы ук, хатыны бала көткәндә, ул имамлык итү максаты белән туган җиренә – Буага кайта, имтихан биреп, атасының мәдрәсәсен җанландырып җибәрә. Тиз арада мәдрәсәнең даны тирә-якка «Нургали мәдрәсәсе» яки «Мәдрәсәи Нурия» буларак тарала. Нургали Хәсәнов 30 ел буе төрле матди, мәгънәви кыенлыклар кичереп, үз тырышлыгы белән мәдрәсә эшен тартып бара. Ул бик үзенчәлекле шәхес, кадимчеләргә дә, җәдитчеләргә дә кушылмыйча, кемнәргәдер ияреп түгел, ә үз фикерен булдырып, үз принципларына тугры калып, үзенчә эшли. Шуңа күрә дә ул һәр ике тарафтан да каршылыклар, тәнкыйтьләргә юлыга. Аның фикерләрен кабул итүчеләр дә, каршы чыгучылар да була, билгеле. Газета битләрендә хәзрәткә тискәре бәя бирелгән мәкаләләр шактый күп очрый.

Аның Истанбул белән бәйләнеше минем игътибарны аеруча җәлеп итте. Галим үз гомерендә күп сәяхәт итсә дә, аның башка сәяхәтнамәләре юк. Нургали Хәсәнов күбрәк Россияне гизә, шундагы мөселманнарның проблемаларын хәл итү белән шөгыльләнә. Бохарага да, башка җирләргә дә сәяхәткә чыга, тик сәяхәтнамәнең үзәген Истанбул-Мәккә-Мәдинә, ягъни хаҗ сәфәре алып тора. Истанбулга ул 1906 елның августында килә.

«Истанбулны зиннәтле фаэтон арбасында гизә»

– Нургали хәзрәтнең Госманлы империясе җитәкчесе, мөселманнарның танылган хәлифе, солтан Габделхәмид II белән очрашу вакыйгасы шактый маҗаралы булган дип беләм...

– Нургали Хәсәновның падишаһны күрү һәм улын мөгаллимнәр мәктәбенә укырга кертү теләге була. Солтан җомга намазына мәчеткә килгәндә тантаналы, атаклы «Җомга сәламләве» чарасы – рәсми парад үткәрелә. Бу – дәрәҗәле һәм зыялы шәхесләр катнашындагы демонстрацияле тамаша. Анда чит илдән килгән дәүләт эшлеклеләре, зур илчеләр, консуллыкта эшләүчеләр, хәрбиләр катнаша. Хәтта мөмкинлекләре булганнар, падишаһка гаризалар язып, бу чарада үз теләкләрен дә җиткерә алган. Нургали Хәсән, бөек вәзир (садыйр әгъзам)

Нургали Хәсәновның тууына 170 ел тулу уңаеннан оештырылган конференция кунаклары Буаның борынгы мәдрәсә бинасы янында. 10 сентябрь, 2022 ел

янына барып, үзенең сәламләү мәрасимендә катнашырга теләвен белдерә. Бөек вәзир татар галимен падишаһ белән күрешү мөмкинлеге булган урынга – Истанбулның иң гүзәл, иң зиннәтле сарае – Йолдыз сарае мәчетенә җибәрә. Ләкин 1901-1906 нчы елларда падишаһка янаулар, аның идарә системасына каршы төшүчеләр күбәю, үзенә төрле куркынычлар тудыручылар булу сәбәпле, бу елларда сарайда рәсми булмаган чит кешеләрне кабул итү сирәгәйгән. Шуңа да карамастан, Нургали хәзрәтнең көчле тавыш белән дога укуын күреп, солтан Габделхәмид аңа игътибар итә һәм үзенең ярдәмчеләреннән: «Бу кем?» – дип сорый. Аңа: «Русиядән килгән татар галиме», – дип җавап кайтаргач, патша Нургали хәзрәт белән кызыксына һәм үз янына алдыра. Алар бергә намаз укыйлар, аннары солтан татар галимен сарайга урнаштырырга боера. Нургали хәзрәт сарайда да солтан белән берничә мәртәбә күрешү бәхетенә ирешә. Ул аның янына гариза язып керми, ә турыдан-туры аралаша. Укыган догасын падишаһның ишетүе аркасында, татар галиме һәм аның улы 1,5 ай сарайда кадерле кунак булып яши. Аларның төрле матди-рухи ихтыяҗларын үтәргә тырышалар, өс-башларын карыйлар. Нургали хәзрәт Истанбулны зиннәтле фаэтон арбасында гизә, аларга шәхси сакчы-ярдәмчеләр бирелә. Нургали хәзрәт мәчет-мәдрәсә, төрбә, тәккәләрдә була, төрле зыялы шәхесләр белән очраша, сарай ифтарларында катнаша, патша белән берлектә тәравих намазларын укый. Рамазан аеның билгеле бер көннәрендә укымышлы кешеләр, падишаһ янына җыелып, гыйльми фикер алышуларда катнаша торган була. Бер-ике урында Нургали хәзрәт тә үз фикерләрен әйтергә тели, ләкин, эчке кагыйдәләр буенча, чит илдән килгән кунакларга сүз әйтергә рөхсәт ителми. Солтан Габделхәмид II аны үз хисабына хаҗга җибәрә, Төркиянең иң мәртәбәле бүләге – «Османия» ордены белән бүләкли. Нургали хәзрәтнең улы Гыясетдин дә мәшһүр шәхес булып таныла.



Омар Хакан Озалпның «Габделхәмид солтан сараенда: бер татар мөдәррисенең хатирәләре...» дигән китабы

– Солтан ни өчен нәкъ менә Нургали хәзрәтне кабул иткән соң? Аның белән күрешергә теләүчеләрнең саны хисапсыз булгандыр бит?..

– Россиядән килгән татар-мөселман галиме булуы төп сәбәптер дип уйлыйм. Солтан үз хәлифәтеннән читтә яшәүче мөселманнарның авыр һәм фаҗигале хәлен белеп, ничек булса да аларга ярдәм итәргә омтылган. Дөрестән дә, Нур-

гали хәзрәт Истанбулга сәфәр кылган чорларда Россиядән килгән йөзләгән мосафир солтан акчасына хаҗ кылу бәхетенә ирешә.

Моннан тыш, Нургали хәзрәтнең бөек вәзир белән китаби телдә – камил итеп гарәпчә-фарсыча сөйләшүе Төркиянең дәүләт җитәкчеләрендә кызыксыну уята алган.

– Ни өчен солтан Нургали хәзрәткә Госманлы империясенең иң мәртәбәле бүләген бирә? Россиядән мондый орденлы дин әһеле тагын булганмы?

– Госманлы дәверендә сарайга килгән мосафирларга, кадерле кунакларга падишаһ тарафыннан төрле кыйммәтле бүләкләр бирү бер матур гадәт булган. Алар, – нигездә, галимнәр, журналист, язучы, шагыйрь, сәнгать эшлеклесе яисә дәүләт чиновниклары кебек зур шәхесләр. Нургали хәзрәткә дә, аның белән бергә килгән улына да сыйфатлы-зиннәтле күлмәкләр, кием-салым бүләк итәләр, юллык акча да бирәләр. Әйткәнемчә, казна хисабына хаҗга да җибәрәләр. Кытай мөфтие дә Нургали Хәсәнов белән бер үк вакытта сарайда кунак ителә. Ул да нәкъ шундый ук орден белән бүләкләнә. Аннан алда – 3-4 ел элек Диния нәзарәте мөфтие Мөхәммәдьяр Солтановның да Истанбул сараенда булуы, аны да зурлап каршы алулары, падишаһ белән күрешүе, шундый ук дәрәҗәле орден белән бүләкләнүе билгеле.

«Гарәпчә басмаларыгыз гаять күп. Мин моңа шаккаттым!»

– Татар мирасы баймы?

– Бик бай! Чагыштыру өчен шулай дим: зур-зур ташлардан биек-биек таулар өелергә мөмкин. Тик шуның арасында бик кечкенә бер асылташ булса, бу тау бик кадерле булыр. Бу асылташ, бер кечкенә алмаз кисәге биек тауларның иң кыйммәтле хәзинәсе саналыр. Эш санда түгел! Ә чынлыкта татар мирасы сан ягыннан да бик бай. Гомумән, сан да, сыйфат та гаҗәпләнерлек! Гарәпчә басмаларыгыз гаять күп. Мин моңа шаккаттым! Боларның барысы да Казанда чыккан бит. Татар зыялылары күп эшләгән, күп укыган. Алар бик укымышлылар! Хезмәтләрнең күбесе, нигездә, мәдрәсә эшчәнлеге, дин-ислам хакында булыр. Ул чорларның китаплары турында сөйләсәк, Төркиядә дә нәкъ шул ук темаларның яктыртылуын күрәбез. Ләкин һәр мәдрәсә турында язганда, шул мәдрәсәдә укыткан һәм укып чыккан мәшһүрләр турында да сөйләнелә. Аларның һәркайсы – аерым язмыш һәм бу шәхесләр – тарихта бай мирас калдырган әдипләр. Әлеге чор хезмәтләре шуның белән аеруча кадерле.

– Ихлас әңгәмәгез өчен рәхмәт!

Төрекчәдән ***Алия Мөбарәкшина*** *тәрҗемәсе* ■

Олуг шәхесне искә алу

10 сентябрь көнне Буа районында дин галиме Нургали Хәсәновның тууына 170 ел тулу уңаеннан халыкара фәнни-гамәли конференция узды

Фәрит Садриев: «Толымбайның борынгы зиратында этник-мемориаль комплекс булачак»

Журналист Рәмис Сафин һәм галим Данияр Гайнетдинов: «Буа зиратындагы һәр таш кисәге – олы тарих»

Камил хәзрәт Сәмигуллин: «Остаз ул хәзерге профессор дәрәҗәсенә тиң»

Дин әһелләре Нургали хәзрәт Хәсәнов рухына дога кыла

Раил Садриев: «Буадагы иң борынгы бина – иске мәдрәсәне торгызырга кирәк. Элек бирелә Татар урамы булган. Киләчәктә тарихи-милли комплекс һәм Нургали Хәсәновка багышланган һәйкәл булыр дип хыялланам»

Искәндәр Гыйләҗев: «Нургали Хәсәнов кебек шәхесләребезнең роле бәяләп бетергесез зур»

Галим Рәшит Амишов үзенең «Татарский богослов Нургали Хасанов» исемле китабын тәкъдим итә

Фоторепортаж белән тулысынча beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.

100 ел элек татар дөньясы

Татар укытучылар мәктәбе – 1920 нче елларда Татар педтехникумы бинасы

Керәшен мәгариф хезмәткәрләре өчен татар теле курслары

Керәшеннәр арасында татар язуы кертү эшләрен башкару өчен керәшен мәгариф хезмәткәрләре өчен курслар ачыла. Шулай ук керәшен мәсьүл *(җаваплы)* хезмәткәрләре өчен татар телен өйрәнү курслары да ачылачак. Бу курсларның сметалары тасдыйк ителгән *(расланган)* инде.

«Татарстан». – 1922. – 4 октябрь.

Ачларга ярдәм комиссияләренең съезды

Шушы көннәрдә Мәскәүдә бөтен Русиядәге Ачларга ярдәм комиссияләренең съезды ясала. Бу съездга Татарстан Җөмһүриятеннән Татарстан Мәркәз Башкармасы

рәисе урынбасары иптәш Исхак Казаков китте. Ул анда Татарстан Җөмһүриятенең авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать эшләрен яңарту вә алга җибәрү мәсьәләләре хакында доклад ясаячак.

«Татарстан». – 1922. – 5 октябрь.

Тукай исемендә балалар йорты

8 нче татар балалар йортының («Волга» номерлары) тәгълим *(укыту)* вә тәрбия бүлеге тарафыннан мәзкүр йортка «Тукай йорты» дип исем бирелү турындагы үтенеч Татарстан Халык Мәгариф Комиссариатының яшь балаларга иҗтимагый тәрбия бирү бүлеге тарафыннан тасдыйк ителде *(расланды)*. Мәзкүр татар балалар йорты «Тукай йорты» дип йөртелә башлады.

Йорт хозурында балалар әдәбияты белән тулы көтепханә бар. Шулай ук балаларга тәрбия бирүдә тәҗрибәле кешеләр тарафыннан идарә ителә торган драма, музыка, пластика, гимнастика түгәрәкләре дә бар. Шулай ук, Казанда ябык балалар йортларының һичберсендә клуб булмаган хәлдә, бу йортта 3 айдан бирле клуб та дәвам итеп килә. Гомумән, бу балалар йортын балаларга иҗтимагый тәрбия бирүдә Казанда беренче йортлардан хисапларга ярый.

«Татарстан». – 1922. – 8 октябрь.

Карт революционер исеменә ачылсын!

Казанның иң зур уку йортларыннан саналган әүвәлге беренче реальный училищеның бинасына хәзерге көндә гаять тә зур ремонт ясалып ята. Биш-алты ел буена солдат казармасы булып шактый җимерелгән, хәзерге көндә матур бер дворец төсенә кергән мондый ташландык зур хәрабәләрнең кыска вакыт эчендә төзәтелүләрен күргәч, төзәтү чорының могъҗизаларына ис китми һич мөмкин түгел.

Ишетелүләренә күрә, бу ремонт тагын бер-ике атнадан тәмам булып, Казанда Татар педтехникумы (әүвәлге Татарская учительская школа) ачылачак икән.

Татарская учительская школаның әүвәле дә, хәзер дә бик күп революционерлар чыгарганын, аның татарлар арасындагы революция һәм ысулы җәдид хәрәкәтләрендә уйнаган ролен монда язып торырга хаҗәте дә юк.

Менә шул тарихи бер мәгариф йортының зураюын, аның үсүен бер тәбрик итми китә алмыйбыз. Минемчә, мондый зур бер тарихи йортны ачканда, тантаналы рәвештәрәк ясап, үзенең хезмәтләре белән танылган бер революционер исеменә ачу муафыйк булыр иде.

Мондый революционерлардан, һичшиксез, беренче урында торганы Исхак абзый Казаков булырга тиеш. Исхак абзый Казаков – шул Татарская учительская школаның чыгарган бер җимеше, 1905 нче еллардан бирле революция юлында хезмәт итеп килгән иң карт революционерларыбыздан. Әлбәттә, бу карт революционерның хезмәте тәкъдир ителер, мәгариф органнары бу хакта бер тәшәббескә керешерләр дип өмид итәбез.

С.Бакый.
«Татарстан». – 1922. – 9 октябрь.

Казанда Байтарлык институты

Тиздән Татарстан Мәгариф Комиссариаты тарафыннан Казанда Байтарлык *(ветеринария)* институты ачылачак. Факультетның беренче сыйныфына керә алырлык мәгълүматлы татар егетләре бу институтка кабул ителәчәкләр.

«Безнең байрак». – 1922. – 18 октябрь.

Ник татарлар юк икән?

Татар Җөмһүриятенең милиция баш идарәсе тарафыннан милициягә кызыл командирлар җитештерү өчен ачылган курс икенче тапкыр җыелды.

Хәзерге көндә авылларда ришвәтчелек, хыянәтчелек шактый гына зур урын тота. Игенчеләр үзләренең хакларын белмәгәнлекләреннән, бик еш-еш кына урынсыз рәнҗетүләр булып тора. Бу җитешсезлекләр белән көрәшергә мәркәздә бик күптәннән бирле инде хәзерлекләр корылса да, бу көнгәчә һаман да нәтиҗәсез.

Бу курс инде үзенең беренче выпускасында 30лап кызыл начальникларны игенчеләр арасында хезмәт итәр өчен төбәкләргә таратты. Күпчелеген тәшкил иткән татарлар арасында хезмәт итәргә тиеш булсалар да, никтер, бу курска татар яшьләре бик аз әһәмият бирәләр. Чөнки курсантлар арасында татарлар тик өчәү генә.

Курсант Җ.Гыйматдинов.
«Татарстан». – 1922. – 8 октябрь.

Эшчеләр тормышы

Томь вилаяте, Кузнецк күмер хавирәсендәге *(бассейнындагы)* Прокопьевск һәм Кисловодск шахталарында искедән эшләп килүче татар шахтерларының икътисади тормышлары зарарсыз булса да, ләкин, ачлык сәбәпле, Эчке Русиядән күчеп килгәннәренең хәлләре бик уңайсыз. Күбесенең, гаиләләре зур булу өстенә, ачлык сәбәпле җончыганлыкларыннан эшчеләрнең көчләре калмаган. Шунлыктан болар ашау-эчү һәм өст-баш мәсьәләләрендә бик читен хәлдә яшиләр.

Гомумән, эшчеләр арасында аң-белем тарату эшләре дә начар бер хәлдә бара. Араларында башлап йөрерлек сәяси юлбашчылары юк. Һичбер җирдән татар матбугаты бармый. Болай да матди җәһәттән уңайсыз хәлдә яши торган татар эшчеләре өчен акчага газета-журнал һәм башка матбугат сатып алу читен. Балаларга мәктәп юк. Шунлыктан бу шахталардагы татар эшчеләренең карты-яше, хатыны, кызы, шахтадагы көнлек эшләрен бетергәннән соң, калган вакытларын корыга – ләчтит сатып утыралар.

Ерак Себернең очсыз-кырыйсыз тайгаларында яшәүче бу иптәшләрнең хәлләренә дикъкать ителсә икән.

«Таучы» коммунист.
«Безнең байрак». – 1922. – 23 октябрь.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Галимә абыстай яки Әби-тәтә күлмәге

Айзилә Сабирова

Галимә абыстай күлмәгенең күкрәкчәсе

Әби-тәтә күлмәгенең орнаменты

Тарихи ядкяр – Галимә абыстайның күлмәге

Хатын-кызлар элек-электән үзләренең тышкы кыяфәтен кайгырткан, үзенчәлекле итеп бизәнергә, үзләренә һәм тирә-юньдәгеләргә дә ошарга омтылган. Бу омтылышта аларга төрле милли киемнәр, бизәнгечләр, аеруча хатын-кыз күлмәге ярдәмгә килгән.

Үзен ихтирам иткән һәр татар кызы гомеренә бер тапкыр булса да затлы, аның шәхесен тулаем чагылдырган күлмәк тектерергә яки үзе үк тегәргә теләгән. Андый кадерле күлмәкләр бары бәйрәм көннәрендә генә сандыктан алынган, гомер буе зур игътибар белән киелгән һәм буыннан-буынга тапшырылган. Нәтиҗәдә, шактый күп татар хатын-кызының күлмәкләре бүгенге көнгә кадәр яхшы халәттә сакланган. Апас районының Туган якны өйрәнү музеенда урын алган үзенчәлекле бер татар күлмәге дә нәкъ шундыйлардан.

Гомумән, Апас районының Туган якны өйрәнү музее ядкярләргә гаять бай булып чыкты. Әмма әлеге күлмәк тарихы, халәте һәм гүзәллеге белән барлык экспонатлардан аерылып тора, аеруча сәнгать сөючеләрнең игътибарын җәлеп итә. Куе яшел төстәге затлы тукымадан зәвык белән тегелгән татар хатын-кыз милли күлмәге тышкы кыяфәте белән генә түгел, ә үзенең иясе-хуҗасына карата да кызыксыну уята.

Районның Борнаш авылында гомер кичергән, 108 яшенә җитеп инде бакыйлыкка күчкән Галимә абыстай Булатованың исемен, нинди кеше булганын бу төбәктә белмәгән кеше юктыр ул. Авыл халкы да аңа яратып Әби-тәтә дип эндәшкән. Ул абыстай зиһене, зирәклеге белән авылдашларын таң калдыра торган карчык булган.

«Галимә абыстай авылда кендек кисүче әби иде. Безнең күршедә генә тору сәбәпле, минем кендекне дә нәкъ Әби-тәтә кискән дә инде. Ул шулай ук 103 яшендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ны яттан көйләп, галим Нурмөхәммәт Хисамовны шаккаттырган кеше дә. Кульязманың Әби-тәтә варианты «Бөек язмышлы әсәр» китабында чагылыш тапкан. Шунысы да кызык: Галимә абыстай гомере буе Владимир Ильич Ленинны үз күзләре белән күрүе турында сөйли иде. Бу очракның тарихи дәлилләре, кызганыч, әлегә юк», – дип безнең белән хатирәләрен бүлеште «Апас туган якны өйрәнү музее» директоры Рамис Госман улы Ногманов.

Галимә абыстай шәхесе никадәр үзенчәлекле, кызыклы булса, аның музейда бүгенге көнгә кадәр сакланган күлмәге дә безнең игътибарга лаек. Ул 1904-1905 нче елларда махсус тектерелгән һәм Әби-тәтә тарафыннан бәйрәмнәрдә, кунак-төшемнәрдә генә киелә торган булган. Галимә абыстай күлмәгенең иң үзенчәлекле өлеше – аның итәк очлары, ягъни бала итәкләре, чөнки алар кытай күпертмәле чигеш өлгесе белән эшләнгән. Мондый төр күлмәкләрне хәлле, бай татар хатыннары гына киеп йөри торган булган.

Галимә абыстайның әлеге күлмәген җентекләп карап китик. Яшел төс татар милләтендә изге булып саналган, чөнки ул мөселманнар арасында зур ихтирамга ия булган. Яшел төс гармония, тынычлык, табигать белән бергәлекне аңлаткан һәм яшь татар кызлары, олы хатыннар арасында да зур кулланылышта йөргән. Тегүчеләр, гадәттә, яшел төс белән сары төсне килештерергә яраткан. Сары төс татар халкында эволюция кичерә: башта кайгы символы булып саналган сары, вакытлар үтү белән, ут, яктылык, байлыкны аңлата башлый. Әби-тәтәнең күлмәге куе яшел булганлыктан, аның бизәкләре, орнаментлары да ачык төсле җепләр белән чигелгән. Бу, күлмәккә контраст өстәп, төсләр гармониясен саклап калу нигезендә эшләнелгән дигән фараз бар.

Күлмәкнең бер элементына да игътибар итик: ул – күзләрне шунда ук үзенә җәлеп иткән күкрәкчә яки төшелдерек. Күкрәкчә татар хатын-кыз күлмәгенең аерылгысыз бер өлеше итеп саналган. Аны күлмәкнең күкрәк өлешендәге кисемне каплар өчен кулланганнар. Галимә абыстайның күкрәкчәсе аппликация ысулы белән тегелгән. Сары, күбрәк алтынга охшаш җепләр, күптөрле катламнар җыелмасын тәшкил итә ул.

Татар милли киемнәрендә еш кына чигү белән ясалган орнаментлар очрый. Бу, беренче чиратта, татар осталарының киемнәрне чигү белән бизәвенә бәйле, чөнки аның өчен катлаулы манипуляцияләр таләп ителми. Техник планда нибары энә-җеп, чигү кармагы һәм башка гади җиһазлар гына кирәк булган. Икенчедән, татар хатын-кызлары бу гади җайланмалар ярдәмендә үзләренең осталыгын

да күрсәткән, киемнәрен, йорт җиһазларын да бизәгән. Галимә абыстайның күлмәгенә дә чигү ысулы белән ямь өстәлгән. Аның үзенчәлеге – келәмле чигү белән чигелгән бизәкләр дип атарга кирәк. Татарның милли киемнәрендә әлеге техника сирәк очрый торган булган. Келәмле чигү ярдәмендә бизәк күпереп, йомшак булып торган һәм үзенә җәлеп иткән.

Мәгълүмат өчен язып үтик: келәмле чигү фарсыларда III гасырда килеп чыккан. Бик озак вакыт дәверендә келәмле чигү белән ясалган келәмнәрне көнчыгыш халыкларының бай катлам вәкилләрендә генә күрергә мөмкин булган. Әмма соңыннан бу техника гади халык арасында тарала һәм келәмле чигүне милли киемнәрдә, йорт җиһазларын бизәр өчен куллана башлыйлар. Акрынлап келәмле чигү техникасы татар осталарының арсеналына кереп китә.

Чигү бизәкләренең ничек күренүенә килсәк, шуны билгеләп үтәргә кирәк: татар халкының киемнәрендә аеруча киң таралган бизәк үсемлекләр белән бәйле була. Әмма, моңа да карамастан, башка вариантлар да гамәлдә йөргән. Мәсәлән, кошлар сурәте, геометрик фигуралар һәм ислам кануннарына туры килгән сурәтләр. Әби-тәтә күлмәгенә үсемлек мотивлары, төгәлрәк әйтсәк, чәчәкләр һәм яфраклар төшерелгән.

Композиция ягын игътибарга алсак, татар киемнәрендә бизәкләрнең куелышы бертөрле, ягъни гади генә булмаган. Дулкынлы бизәк, уртадан нурлар чыккан төсле, түгәрәкле яки шахмат тәртибендә, бәйлән шикелле. Әби-тәтә күлмәгендә исә без шахмат тәртибендә урнаштырылган сурәтләрне күрәбез. Татар чигүендә иң еш очрый торган сурәтләрне төп өч төркемгә бүләргә мөмкин: дала, болын һәм, һичшиксез, бакча чәчәкләре һәм үсемлекләре. Осталарның үз күзләре белән күреп, әлеге гүзәллекне буыннан-буынга тапшыру теләге нәкъ шушы бизәкләрдә чагыла да инде. Галимә абыстай күлмәгендә дә бу тенденция күзәтелә.

Күлмәкнең тарихы Галимә абыстай сандыгы белән генә тәмамланмый. Аны музейга 1997 елда әбинең килене Җиһан апа тапшырган. Өстәвенә, тегү остасының машинасын да оныгы Фәнис Галәветдинов шушы мирасханәгә бүләк иткән. Әби-тәтә күлмәгенең күренекле урыны музей бинасы белән генә чикләнмәве билгеле. Ул 2013 елда Казанда Универсиада бәйгеләре барган көннәрдә «Татар милли киеме: тарих һәм заман» дигән күргәзмәдә дә катнашкан. Соңыннан әлеге ядкяр Татарстан Милли музее әзерләп чыгарган «Йөрәк серенең ефәк бизәге» дигән каталогка да кертелгән.

Галимә абыстайның улы Лотфулла Булатов Илдәшләр һәм Бөек Ватан сугышлары ветераны, җитәкче була. Оныклары да дәрәҗәле урыннарда хезмәт куя. Әйтик, олы кызы Сараның улы Әнвәр Баһаветдинов – КПСС ның Азнакай район комитеты беренче секретаре, ТАССР Югары Советының беренче рәисе; Фәрит Баһаветдинов ТАССРның сәүдә министры булып эшләгән. Галимә абыстайның нәсел җепләре, оныкларының хезмәте, авылдашларының аның хакында сөйләгән тарихлары онытылмыйча, бүгенге көнгәчә буыннан-буынга тапшырылып килә. Әби-тәтә турындагы хатирәләр шулай ук аның әлеге үзенчәлекле, зәвыклы күлмәгенең җепләрендә, чигешендә сакланып калган. ■

Апас ягына сәфәр: «Шәп! Шәп! Шәп!»[1]

Миркасыйм Госманов

Шәкерт дәфтәре

Кереш

Бу сәфәргә чыгып китүе бик авыр булды: машина булмыйча 15 көн газапландым; көн саен гараж бусагасын таптап җәфа чиктем. Көтеп зарыкмасыннар, дип, егетләрнең күпчелеген 7 июльдә үк җибәрдем. Үзем исә, бары 17 июльдә генә машина алып, юлга чыктым.

17.07.1969.

Көн болытлы, бик салкын иде. Паромда хәрби колонна иде. Озын чират.

Экспедиция сотрудниклары: Марсель Хәйретдинов, Роберт Закиров, Рөстәм Кәримуллин, Әнвәр Шәрипов, Мирза Мансуров, шофер Петр Кузьмин һ.б. Икеөч сезон эшчеләре дә бар. Шулай да 12-13 көн югалды. Әлбәттә, алдан киткән егетләрнең кайбер нәрсәләр табуы ихтимал. Хәер, баргач, күрербез.

Районга килеп, эшләрне рәтләгәч, Уразлино авылына килдек. Авыл Советында Әнвәр Шәрипов утыра икән. Кулында 3-4 кулъязмасы да бар. Бәетләр, шигырьләр, әллә ни түгел.

Уразлино (Каратан) авылында Резеда Ганиева һәм аның ире Зөфәр Рәмиев[2] кунакта яталар икән (Зөфәрнең туган авылы). Шуларга килеп кунак булып, кунып яттык. Печәнлектә йокладык. Бик шәп ял ителде.

---

[1] Язма Миркасыйм Госмановның археографик көндәлекләре нигезендә әзерләнде.

[2] Резеда Ганиева (1932-2020) һәм Зөфәр Рәмиев (1938) – филология фәннәре докторлары, профессорлар, атаклы әдәбият галимнәре.

18.07.1969.

Юлга иртә генә чыгып булмады: машина рәтсезләнеп, башны катырды... Юлга сәгать 11дә генә чыктык. Көн буе юлда булдык. Бары кичке 7дә генә Яңа Тинчәлегә җиттек. Егетләрне таптык. Күтеп яталар икән. Берничә кульязма да җыеп куйган булганнар. Бик иске дуслар кебек Тәүфикъ бабай Вахитов белән очраштык. Өенә кереп, яхшылап чәй эчеп, исне җыеп алдык.

19.07.1969.

Иртән якта колхозга, Авыл Советына кереп, сөйләшеп чыктык. Тәүфикъ абзый Вахитовны эшкә алып, документларны рәтләдем. Аннары машинада Кече Чынлыга киттек. Фатыйх Сөләйманов дигән кешегә кереп, аның атасы Шәкүр Сөләймановтан (1955 елда үлгән) калган бер әрҗә кульязмаларны актарып, аннан мәрхүм бабайның төрле документлар нигезендә үзе төзегән шәҗәрәләрен, авыл тарихына караган мәгълүматларын сайлап алдык. Бик бай, региональ тарих өчен бик кыйммәтле материал!

«Кыйссаи Йосыф»

Түгәрәк йөзле, түгәрәк сакаллы, чибәр генә кеше булган бу Шәкүр Сөләйманов дигән кеше (рәсемен күрдем, әбисе белән бергә төшкән). Бу бабайны шәҗәрәләр язганы өчен мактап телгә алырга.

Коръән тәфсире. 18 нче йөз

Болардан чыккач, Сабир Мәхмүдов дигән авыл картына кереп, 8-9 иске китап һәм бер авыл шәҗәрәсе (өлешчә) алдык. Бер «Йосыф китабы» да бар. Зур рәхмәт язарга. Авылда мулла була. [...] Кичке якта Тинчәлегә кайттык. Иске таныш Вәлиәхмәт абзый Бакировка барып, кәрәзле бал белән чәй эчеп озак кына утырдык.

20.07.1969.

Төнлә бераз яңгыр яуган. Көн салкынча һәм болытлы. Шулай да Иске Тинчәле ягына киттек. Тәүфикъ абзый белән бергә. Шактый йортларга кердек. Берничә кульязма һәм басма китаплар бар. Бәдәрбану Хәлимуллина дигән бер матур гына әбидән шигырьләр җыентыгы алдык. Басма китапларыннан Һ[ади] Атласовның

«Казан ханлыгы», Ш.Мәрҗанинең «Мостафадел...» һ.б. Тәүфикъ абзый үзен гел батырларча тота: кыю, телгә оста, җор.

Иске Тинчәледән соң Яңа Шәйморзага килдек. Кечерәк кенә авыл. Кунак булып йөрүләрне искә алмаганда, монда бернәрсә дә чыкмады. Яңа Тинчәлегә кайтып киттек. Кичен кичә Чынлыдан алып кайткан кайбер кулъязмаларны карап утырдым: Пугачев манифестының күчермәсе һәм аның турында Гомәр мулла Колмыкай улы язган истәлекнең төп нөсхәсе бар! (Соңгысы бераз инчәлгән хәлдә «Борынгы татар әдәбиятында» басылган – 431 б., шул ук нөсхәдән алынган күчермә.) Шәп! Шәп! Шәп!

Тик манифестның гына төп нөсхәсе сакланмаган. Аның караву, күчермәләрнең берсеннән күчерелгәнчә, ул шул ук Гомәр мулла тарафыннан күчерелеп калган. Теле гаҗәп саф! Эшкәртмәде микән?.. Алай дисәң, Пугачев турындагы башка әйберләр дә халык теленә бик якын бит!..

21.07.1969.

Көн бүген ачык иде. Мунчадан соң бик яхшы йокланган. Иске Шәйморзага киттек. Иң элек Авыл Советына кердек. Барлыгы 750 йорт (Авыл Советында). Иске Шәйморзаның үзендә 542 йорт. Берничә йортка кердек. Артык әйберләр юк. Картлар үлгәч, кабергә илтеп күмү бик күп булган икән... Хәтта олавы белән. Кемнәр күмүе турында да әйттеләр...

Җиһанша дигән бер картка кердек. Хәлле, әйбәт кенә торалар. Китапларын карадык, тик язмалар юк. Әйтүләренә караганда, бу мөселман булган чуашлар нәселеннән икән.

Тагын шактый йортларга кердек, төрле өзек-өзек нәрсәләр бар. Аннары ашханәгә кереп ашап алгач, җилдертеп Олы Чынлыга (Ярәмәйгә) киттек. Гәрәй абзый Алимовка кереп, якын туганнар кебек исәнләшеп, бик озак сөйләшеп утырдык. Чәйләп, закускалап алгач, Яңа Тинчәлегә кайттык. Кичке салкын белән...

Кайтышлый Вәлимөхәммәт абзыйга кереп, хушлашып чыктык. Кичен иртәнге юлга әзерләнеп, җыелган китапларны барладык. 50-60 берәмлек бар икән. Тик күпчелеге өзек-өзек әйберләр.

22.07.1969.

Көн тагы болытлы, сибәләгән яңгырлы иде. Буа ягына юлга чыктык. Авыл белән, танышлар белән саубуллашып. Хәерле сәфәрләр...

Юлдан Югары Наратбаш авылына кереп, Низамов Борһан абзыйга очрап, аның җыеп куйган кулъязмаларын алдык.

Аннары Апаска килдек. Райисполкомга кереп, рәисе белән сөйләшеп чыктык. Заляев Амет Галяутдинович. Авылларга киттек. Ике егетне Keче Болгаер авылына илтеп куеп, Әнвәр белән Мансурны эзләп, Уразлинога чыгуга, көчле яңгыр башланды, юл камыр кебек изрәде, барып булмый. Сатлыганга көчкә генә җиттек. Тик егетләр Зур Карилегә китеп барганнар икән. Алар артыннан китәргә генә торганда, машинабыз ватылды. Ул арада көчле яңгыр ява башлады. Шулай итеп, без, мосафирлар, ярты юлда калдык... Элек малайлар торган Нуретдиннәрдә кундык.

23.07.1969.

Иртүк машинаның алдагы көпчәген ремонтларга тотындык. Шарлар ычкынган булган. Димәк, эш бик чамалы. Ремонт көндезге 12дә генә бетте. Ә көн һаман ала болыт, яңгырга тартым иде...

Киттек Затонга. Юл әле начар. Ләкин Затонга җитүгә, машинабыз тагы ватылды: шул ук шарлар ычкынды. Их!.. Шофер тагы машинаны сүтеп җыйды, 3-4 сәгать вакыт узды. Нәкъ җыеп бетерүгә, былтыр танышып киткән Рәшит Ваһапов (райбашкарма рәисенең урынбасары) үз максаты белән килеп чыкты (ул эш белән китеп бара икән), райбашкарма янында очрашырга булдык. Кичен аның шоферы тиешле частьларны табып бирде. Мин шул Рәшитләргә кунарга туктадым. Яхшылап кичкене ашап, ак, йомшак түшәк урында рәхәтләнеп йокладым.

24.07.1969.

Көн бүген матур булырга вәгъдә итә сыман: аяз, якты… Районга килдек. Барырга кирәк авыллар: Каратал (Старая Хазеевка), моның янында 3 авыл бар – Стар. Барышево (Барыш), каршында 2 авыл; Ямасылы (Яңасала) – 2 авыл; Б.Буртасы – 5 авыл; Клянчевский с/с. - 2 авыл; Б.Кляринский – 3 авыл; М.Сатлыковский – 3 [авыл]; Балтачский с/с.

Авылларга чыгып киттек. Уразлинога (Караталга) киттек. Резеда белән Зөфәргә кереп, бер чәй эчеп алдык. Аннары ике егетне (Әнвәр һәм Мирзаны) эзләп, Олы Карамалыга килдек. Тик егетләр аннан Бәрлегуҗа авылына киткән, егетләрне таптык. Әйтүләренә караганда, егетләр ул хәтле әйберләр тапмаган кебек. Ярар. Киттек авыл буйлап «сәяхәт итәргә». Бу авылда бернәрсә дә чыкмады. Киттек О[лы] Кариле (Б[ольшие] Кляри) авылына. 4 авыл (Олы Кариле – 164 йорт, Кече Кариле – 84, Чаллы – 110, Бәби – 30). Бу авыл, кешеләрнең мөгамәләсенә караганда, бик җүнсез күренә. Хәерле булсын.

Киттек Болгаер ягына, юлдан Келәнче авылына кереп, Авыл Советы рәисенең урынбасары Гыйльметдинов Ирек (тарих укытучысы) белән очрашып сөйләштек. К[ече] Болгаерга килдек. Егетләр шактый кульязмалар җыеп куйган икән. Ләкин күпчелеге яраксыз. Бер әтәчне кимереп, йокларга яттык.

25.07.1969.

Иртәнге яктан колхоз һәм Авыл Советы башлыклары белән киңәшеп, авылдан киттек. Колхоз рәисе дә бу якның бик кара һәм белемсез булуы хакында сөйли («Тау Ягы кара, Апас ягына киткәч, бераз агара төшә…»). «Ак як» дип Апас районының Дәвеш, Чури-Бураш, Апас, Турай, Әлмәндәр авылларын әйтә (Ленин колхозы). Колхозда 3 авыл (283 йорт).

Зиратка барып, печән киптереп йөргән бер көтү картлар белән озак кына сөйләшеп, аларга «лекция» укып алдым. Кичен егетләр килеп, шуларның берсенә ияреп, авыл буйлап йөриячәкмен. Кайбер картлар үзләренә килергә кушып киттеләр. Аннан соң Әҗем дигән авылга кереп чыктык. Бернәрсә дә юк.

Борнаш авылына килдек. Бер карт белән очраштык. Аннары Кәфил Минһаҗев дигән авылдагы тарих укытучысы белән очраштык. Аның әйтүенә караганда, бу авылда да кайбер шәҗәрәләр язучылар булган, имеш. Әйтүләренә караганда, бу якларда элек керәшеннәр күп булган, тик революциядән элек яңадан исламга кайтканнар. Менә ни өчен бу якларда белемлелек түбән булган.

Калган егетләр ягына киттек. Егетләр бер кадәре әйберләр табып куйганнар икән. Шәп! – «Бачман хикәясе» бар! Бу безнең өчен бик яңа әйбер!

Малайларны Кариле авылына китереп урнаштыргач, Олы Бортас авылына киттем: егетләргә урын әзерләп куяр өчен. Авыл Советында Исламов Рәшит – рәис – бар икән. […]

26.07.1969.

Иртәнге якта Әлмәндәрдә калган егетләр ягына киттем. Болар да шактый әйберләр тапкан. Тик күпчелеге яраксыз.

Авыл Советына барып, Гыйбадуллин Гатаулла, Хәйруллин Гарифулла дигән ике бабайны, эзләнеп торыр өчен эшкә алып, беркадәре аванс биреп киттем.

Кичке якта Күккүз авылына килеп төштек. «Гигант» колхозында бик яхшы каршы алдылар. Колхоз рәисе Камалов Фәрих дигән кеше икән. Кичен су буена барып юынып кайттык. Бер әтәчне ялмадык.

27.07.1969.

Көн бик ачык иде. Малайларны авылда калдырып, Апас һәм Буа якларына киттек. Каратун станциясенә килеп, аннан Балтай, Бакырчы һәм Багыш якларына киттек. Максат шул яклардагы авыллар белән танышып-белешеп, киләсе ел өчен җирлек әзерләү иде. Көн бик эссе, бик бөркү иде.

Килдек Чиремшән авылына. Колхоз «Вахитов» (рәисе – Мөхетдинов Габбас Мөх.). Авыл Советы – Насыйбуллин Ислам Насыйбулла улы. Колхозда 5 авыл (Чиремшән – 280, Багыш – 220, Аю Көйдергән – 100, Тәүгилде – 115, Бакырчы – 270). Чиремшәндә Җиһанов Галим дигән кешедә авыл тарихы бар, имеш.

Багыш авылына килеп, Тәүхид Фәлләховларга туктадык. Атасын күрдем, Гани абзый дигән акыллы гына карт икән. Ашап-эчеп алгач, су буена төшеп, кизләү суын эчеп кайттык. Бераз ял итәргә исәп… Көн болытлы, бозыла башлады, җил чыкты. Нәрсә булыр икән… Ләкин яумыйча узды, Аллаһка шөкер. Тәүхидләрдә яхшылап ял иттек.

28.07.1969.

Бүген көн бик ачык иде. Яхшылап чәйләп алдык.

Хикаять (табышмак): Бер килен уракка бара. Өйгә кайткач, каенанасы сорый: «Ничә көлтә урдың, кызым?» Тегесе җавап бирә: «Өчәр-өчәр өч төштә, ике көлтә бер төштә, ике сигез, бер тугыз, бер алты да бер утыз». Ахыры онытылган, 72, ахыры.

Киттек авыл аша Апас ягына. Морза Бәрлебашын узып, Рус Ябалагы дигән авылга килдек. Урта Биябаш авылында күпчелеге татарлар. Рус Ябалагында якынча 30-40 татар йорты, Урта Биябашта барлыгы 109 (70-80 татар) хуҗалык.

Апаста райбашкармага килдек. Карта буенча мәгълүматлар җыйдык.

Түбән Балтайда шәҗәрә бар – Гатауллин Әкрам, почта башлыгы.

Урта Балтайда Рәхмәтуллин Мөбинда әтисе язган авыл тарихы булырга тиеш!

Моннан соң, шалтыратып, Буага киттек. Анда кайбер эшләрне бетергәч, Югары Наратбаш, Әхмәт авылларына кереп, Аксу авылы аша Багышка кайттык. Бик арылган иде…

29.07.1969.

Апастан узып (Тәүхид, аның әтисе Гани абзыйны Каратунга китереп ташлап), Күккүз авылына килдек. Егетләр бер-ике бәет дәфтәреннән үзгә бернәрсә дә тапмаган икән. Төшлеккә бер әтәчне ялмагач, ял итәргә булдык. Көн ачык булса да, җилле генә иде. Иртәгә Кама Тамагы ягына күчәрбез…

30.07.1969.

Көн бик матур булырга вәгъдә итә бугай. Авыл Советына барып, рәхмәтләрне белдергәч, Кама Тамагы районына чыгып киттек. Иске Барыш Авыл Советына кил-

дек. 2 авылдан гыйбарәт: Иске Барыш (110 йорт), Кыртапа (100). Кечкенә генә иске авыллар. Марсель белән Рөстәмне Иске Барыш һәм Кыртапа авылларында калдырып, Каратал ягына калган икесен эзләп киттем.

Габделҗаббар Кандалый шигырьләре

Юлдан бер ташландык чиркәүне карадык. Әйләнә-тирәдә татар авыллары һәм бер ташландык чиркәү. Миссионерлар истәлеге. Әнвәр белән Мирза шактый әйбер тапкан булган. Ләкин мин аларның шактыен брак ясадым. Шулай да берничә бәет дәфтәрләре бар. Кичке якта Иске Барыштагы ике егетне алып, ягъни бөтен бригаданы җыеп, Яңасала ягына юл тоттык.

Иске Барыш авылында Салихов Харис дигән бер абзыйны корреспондент итеп килештек. Ләкин көн соңаргканлыктан, Яңасалага бармыйча (аны киләсе ел өчен калдырып), Олы Барыш авылында туктадык. Элек егетләр кунып киткән Кәрим абзый дигән картларда туктадык.

31.07.1969.

Төшкә хәтле машинаның ватык-потыгын карадылар. Аннары Казан ягына киттек. Кичен өйдә идек.

Нәтиҗәләр:

1. Экспедициянең ярты срогы «җилгә киткәнлектән», быел тикшереп бетерергә тиеш булган Апас районы тәмамланмыйча калды. Дөресрәге, аның көнчыгыштагы бер чиген генә капшап чыктык. Ә Кама Тамагы районын исә шактый төгәл эзләдек (бары бер-ике зур авыл гына калды). Димәк, киләсе елны Апас районының үзәген һәм көньяк, көнбатыш, төньяк өлкәләрен бик ныклап тикшерергә кирәк.

2. Кулъязмаларның күпчелеген Буа районы һәм Чүпрәледәге К[ече] Чынлы авылы бирде. Кама Тамагы, Апасның көнчыгышы, халыкның үз әйтмешли, шактый «кара як» икән. Шуңа күрә табылган кулъязмаларның сакланышлары да бик әшәке…

3. Егетләрдән Мирза Мансуровтан башкалары археография планында өметле түгел…[3] Ул егетне киләсе елны да чакырырга кирәк.

4. Табылган әйберләрнең иң әһәмиятлеләре: «Түләк һәм Сусылу хикәяте», Пугачев явы турындагы истәлекнең язмалары, Чынлы авылы тарихына караган материаллар (шәҗәрәләр) һ.б. Кыскасы, 150дән артык кулъязманың калганнары бигүк әллә ни түгел.

5. Киләсе ел ни күрсәтер.

Текстны басмага ***Диләрә Госманова*** *әзерләде.* ■

[3] Әмма экспедициядә катнашучылар арасыннан Әнвәр Шәрипов кына галим-археограф, филология фәннәре докторы, профессор булып җитлегә, Кол Шәриф, Утыз Имәни һәм башка шәхесләр турында затлы китаплар иҗат итә. – *Ред.*

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Айрат Җиһаншин: «Киләчәк буынга бай мирас калдырырбыз дип уйлыйм»

Апас муниципаль районы башлыгы Айрат Габделхак улы Җиһаншин

ТАРИХ

Апас районы истәлекләргә, тарихи вакыйгаларга бик бай. Аңа XVII гасырда Зөя елгасына якын күл буендагы, талаучылар һөҗүм итеп яндырылган авылдан күченүчеләр нигез сала. Шулар арасыннан Габбас исемле кеше ямьле Табар елгасы буена, урман-тауларга, чишмә-үзәннәргә, кыр-тугайларга бай урынга, кыскасы, уңдырышлы һәм мул җирләргә гаиләсе белән килеп төпләнергә уйлый. Габбас агай үзе игенчелек белән шөгыльләнә, ә хатыны өй эшләре һәм балалар тәрбияләү белән мәшгуль була. Габбас исеменнән чыгып, телдән-телгә күчеп, Аббас, Аппас, ә соңрак Апас топонимы барлыкка килгән.

Башка фикер буенча, Апас Иске Әнәле авылыннан күченүчеләр тарафыннан нигезләнгән һәм 1647 елдан Кече Әнәле исемендә мәгълүм. «Олы» Апас дүрт торак пунктны берләштерү нәтиҗәсендә оешкан дип тә әйтәләр. Шуларның берсе, Колсәет авылы, XIX гасыр ахырына кадәр үзенең исемен һәм мөстәкыйльлеген саклый. XX гасыр башында Апас барлык рәсми документларда «Аерылып чыккан Колсәет авыллы Апас» буларак искә алына. Зур авыллардан халык бирегә даими күчеп килгән һәм Апаста яшәүчеләрнең саны арткан.

Апас ягы – борынгы болгар бабаларыбызның да торган җире. Алар күп гасырлар элек биредә иген иккән, ауга йөргән, үзләреннән соң матур гореф-гадәтләр кал-

дырган. Бу тарих Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында да дәвам иткән.

Хәзерге Апас районы җирләрендә кешеләрнең 12-14 мең еллар элек үк утрак тормышта яшәүләре турында мәгълүмат бар. Мәсәлән, Зөя буендагы Кабык Күпер авылы янында археологлар төрле ау һәм балык тоту кораллары табалар. Сөяктән ясалган ыргаклы сөңгеләр, ук очлыклары да Зөя буенда урнашкан Дәвеш авылындагы торфлыкта килеп чыга. Саный китсәк, мондый ядкярләр бихисап. Алар белән Туган якны өйрәнү музеена барып иркенләп танышырга мөмкин.

> **«Зөя буендагы Кабык Күпер авылы янында археологлар төрле ау һәм балык тоту кораллары табалар. Сөяктән ясалган ыргаклы сөңгеләр, ук очлыклары да Зөя буенда урнашкан Дәвеш авылындагы торфлыкта килеп чыга.**

ХӘЗЕР

Хәзерге вакытта Апас районында 18 меңнән артык (18 247) кеше 1048 кв. километр җирдә гөрләтеп яши. Биредә 73 торак пункт бар.

Районыбызда 18 мәктәптә, 25 балалар бакчасында, 2 башлангыч мәктәп-балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирелә. Мәктәпне тәмамлаган балалар укуны Апас аграр көллиятендә дәвам итә алалар. Яшьләр өчен 100 спорт корылмасы эшләп килә. 2 стадион, 19 спорт залы, «Алтын алка» боз сарае, «Апас» универсаль спорт залы, «Дельфин» йөзү бассейны, чаңгы трассасы бар. Егет һәм кызларыбыз спорт мәктәпләрендә чыныгу ала.

Мәдәният йорты, 59 клуб, 27 китапханә милли мәдәниятебез сагында тора. «Сәләт» балалар иҗат йорты һәм Сәнгать мәктәбе дә эшләп килә. Үзәк музейдан кала, Тутайда – композитор Сара Садыйкова, Шәмбалыкчыда – җырчылар Фәхри Насретдинов һәм Бану Вәлиева, Бакырчыда балалар шагыйре Шәүкәт Галиев музейлары, Түбән Барышта атаклы татар артисткасы, профессор Асия Хәйруллинаның музей бүлмәсе бар.

Апас – авыл хуҗалыгы районы. Хәзерге вакытта 6 авыл хуҗалыгы оешмасы, 19 крестьян хуҗалыгы эшләп килә.

КИЛӘЧӘК

Узган ел гына «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия конкурсында катнаштык. Нәтиҗә дә сөенечле: «2021 нче елда шәһәр төзелеше сәясәте, халыкның уңай яшәү тирәлеген тәэмин итү һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү» номинациясендә икенче урынга лаек булдык. Шуның нигезендә Апас урамнарына яктырткычлар куярга уйлыйбыз. Гомумән, хәзерге көндә дәүләт программалары ярдәмендә Апасның үзәген заманча итеп үзгәртергә хыялланабыз. Юллар, ял итү урыннары булдырып, туган җиребезне тагын да ямьләргә иде. Шул ук вакытта төп урамнарның барысын да карап, яңартып чыгарга ниятлибез.

Район буенча тарихи маршрут төзү эше дә бара. Ике маршрут күз уңында тотыла. Беренчесе – мәктәп балаларына, икенчесе өлкәннәргә юнәлтелгән. Шушы

Безнең мирас №10 октябрь 2022

маршрутта Апасның иң борынгы тарихы, үзенчәлекләре, шәхесләре, геройлары һәм мөһим вакыйгалары турында сөйләячәкбез. Күрсәтерлек архитектура һәм табигать һәйкәлләребез дә җитәрлек. Сәүдәгәр Кадыйр Латыйповның ике катлы йорты, Үләмә, Табар һәм Зөя елгаларының гүзәл үзәнлекләре генә дә ни тора! Болар хакында районга килгән һәр кеше белергә тиеш дип уйлыйм. Апасның үзендә аерым, ә район буенча киңрәк маршрут эшләячәк. Апас буенча мәктәп балалары белән җәяүле экскурсияләр циклын инде башлап җибәрдек. Бу эш, һичшиксез, дәвам итәчәк.

Археологик казу эшләре вакытында

Икътисади үсешкә килгәндә, яңа сәнәгать оешмалары ачу турында хыялланабыз. Әле шушы арада гына авыл хуҗалыгы ашламалары җитештерә торган «ФосАгро» оешмасы һәм «Волгодорстрой» асфальтобетон заводы эшләп китте. Сөт комбинатына инвестиция керде, 8 исемдәге сыр җитештерергә уйлап торабыз. Сөткә ихтыяҗ терлекчелек үсешенә дә уңай йогынты ясаячак. Битум заводы, кошчылык фермасы төзү буенча эшләр башланды. Апас районы логистик яктан уңайлы урынга – Идел аръягының үзәгенә урнашкан. М12 трассасы да безнең яннан узачак.

Әлбәттә, икътисади үсеш кадрлар мәсьәләсен дә алга куя. Әйтеп үткәнемчә, Апаста электән үк эшләп килүче Аграр көллият бар. Шуның нигезендә политехник ресурс үзәге булдырырга да ниятлибез. Уку бинасына ремонт ясалды, яңа тулай торак төзеләчәк. Кадрларны шунда әзерләп, эш бирә торган оешмаларны да мәгариф системасына җәлеп итсәк, проблема хәл ителер дип уйлыйм. Студентлар сәнәгать оешмасында практика үтәләр һәм, укуны тәмамлагач, шунда ук эшләргә тиеш булалар. Бу – һәр укып чыккан белгеч киләчәктә эш белән тәэмин ителәчәк дигән сүз.

Хәзерге вакытта, республика программасын гамәлгә ашыру нигезендә, «ТРда гигиена һәм эпидемиология үзәге» Апас филиалы бинасы балалар поликлиникасы һәм стационары өчен үзгәртеп корыла, район үзәк хастаханәсенең патологоанатомия бинасын төзү эшләре бара.

Барлык төр социаль программаларда да катнашабыз. Хәзерге көндә авыл җирендә су һәм юл проблемасы үзәктә тора. Су буенча ел саен эш дәвам итә, скважиналар, сууткәргечләр яңартыла. Фәкать, алты авылга гына асфальт юл килмәгән. Бу юнәлештә проект эшләрен алып барабыз. Ә калган авылларның урам эчләрендәге юллары турында уйлыйбыз.

Быел, федераль һәм республика программалары нигезендә, биш мәктәпкә ремонт ясалды. Хәзер алар шәһәр мәктәпләреннән ким түгел. «Зөя» ял итү лагерендә заманча төзекләндерү эшләре бара. Урман эченә, матур һәм тарихи урынга урнашкан лагерьда инде шактый бала ял итәргә, сәламәтлеген ныгытырга өлгерде.

Гомумән, район яшәрсен, яшьләр авылда калсын өчен, хәлкадәри барын да эшләргә тырышабыз. Яхшы юллар, уңайлы мохит, эш урыннары булдырыла, спорт һәм мәдәният – үсештә. Районыбызның киләчәген матур һәм якты итеп күрәм.

Тарихыбыз затлы һәм сокланырлык, бездән соңгы буыннарга да бай мирас калдырырбыз дип уйлыйм. ■

Дәвеш-Толымбай моңнары

Толымбай яшьләренең Дәвештән килгән кунакларны озату мизгеле

Апас районының Дәвеш, Буа районының Толымбай авылларына барсаң, ярты гасыр элек үк үткәрелә башлаган сәнгать һәм спорт бәйрәмен – «Дәвеш-Толымбай дуслык күпере» фестивален сагынып сөйләргә яраталар. Әлеге бәйрәм ничек оешып киткән? Аның геройлары кемнәр? Эчтәлеге нидән гыйбарәт булган? Биредә сүзне сәхнә ветераннарының үзләренә – әлеге вакыйгаларның шаһитларына бирәбез.

Фәрит Садриев: «Дәвеш халкы бик кунакчыл булды»

«Илдар Исмәгыйль улы Садриев 1960 нчы еллар азагында, армиядән кайтып, Казанда укый башлый. Бер үк вакытта Буа районындагы «Коментерн» колхозының Толымбай авылыннан партком секретаре булып та эшли. Буа-Казан поездында Апас районының Дәвеш авылы мәдәният йорты директоры Фирдүс Галимов белән таныша. Күңел күтәренке, икесе дә Җиңү яулаган аталарның балалары. Болар сөйләшеп китәләр, энергияләре ташып тора. Шунда: «Әйдә, ике район яшьләрен берләштереп фестиваль оештырыйк. Ике авыл арасында дуслык күпере салыйк», –



Фәрит Садриев

диләр. Бу турыда колхоз җитәкчеләре белән киңәшеп, елга ике мәртәбә очрашырга карар бирәләр. 15-20 кешедән торган делегация туплана...

Кышын чаңгы ярышлары, җәен футбол, шашка-шахмат уеннары, лозунглар, кызыл әләмнәр, авыл халкында бәйрәм рухы... Кичен исә КВН, концертлар гөрли. Концерт тәмамлангач, яшьләр бер-берсенә кунакка бара иде. Таң атканчы кич утырып, җырлап-көлешеп бәйрәм итә идек. Дәвеш халкы бик кунакчыл булды. Бу көнне читкә киткәннәр дә кайта иде. Миңа әле ул вакытта 15 яшь кенә, үзешчән сәхнәне яулап кына киләм. Ә авылда ике кешенең берсе йә җырчы, йә биюче иде. Битарафларны, гомумән, хәтерләмим. Яшьләрне авылда калдыру, аларга үзләрен күрсәтү, туган җирләрендә кирәклеген тоемлар өчен дә бик мөһим чара иде бу».

Фәридә Мөлекова-Салихова: «Күпер»нең беренче субайларын без салган идек»

«Бер-берең белән танышулар үзе бер дулкынландыргыч мизгел иде. Көндез Дәвешнең нарат урманында чаңгы ярышлары, клубта шашка-шахмат уеннары оештырылды. Ә кичен ике авыл яшьләре катнашында зур концертта көч сынаштык, төрле уеннар дәвам итте. Һәр ике як та зур дулкынлану белән үзләренең чыгышларын күрсәттеләр. Чаңгы ярышларында Толымбай яшьләре үзләренең көчле булулары белән аерылып торды. Анда Рафаэль Юнысов, Соня Николаева, Фирдания Латыйпова кебекләргә тиңнәр булмады. Бу ярышта бик күп яшьләр катнашты.

Апас-Буа төбәге талантлары – Гөлсинә Юнысова, Харис Нургалиев һәм Гөлфия Рәхимова. 1969 ел

Толымбайда узган фестивальдә рус халык биюен башкарган мәл. Рәсемдә авылның булдыклы кызлары – Рузалия, Әминә, Нурия, Руфия, Асия һәм Фәридә. 9 март, 1969 ел

Фәридә Мөлекова башкорт биюен башкара. 9 март, 1969 ел

Яшьнәп үткән «Яшьлек». Уңнан икенче – Фәрит Садриев

Аннан без март аенда Толымбайга бардык. Толымбайның яше-карты безне бик җылы каршы алды. Алдан клубта очрашу-танышу үтте. Яңа дуслар таптык. Мин дә яңа дус кызым – Рәйсә Михайлова белән таныштым. Ул чуаш милләтеннән иде. Хәтта шул милләтнең бер бәйрәм кичәсендә дә булырга туры килде. Танышуларны төгәлләгәч, ярышлар башланды. Бу юлы инде чаңгы ярышлары Толымбай урманында узды. Кичен клубта энә төртергә дә урын юк иде. Ике авыл яшьләренең чыгышларын зур алкышларга күмеп карадылар. Азактан ике якның да сәләтле үзешчәннәренә бүләкләр тапшырдылар. Безне клубтан гостиницага алып кайттылар. Анда бәйрәмнең өченче өлеше дәвам итте. Ә инде тагын да күркәмрәге – Гөлгенә пешереп алып килгән кайнар коймаклар булды.

Җәй көне без тагын очраштык. Анда инде җәйге атлетика уеннары: йөгерү, сикерү, футбол, волейбол ярышлары. Һәр авыл командасы үзенчә көч сынашты. Мәйдан гөр килеп, авыл халкы көч биреп торды. Җиңел атлетика буенча без инде беренчелекне үзебездә саклап кала идек. Соңыннан җиңүчеләргә бүләкләрне безнең авыл яшьләренә Толымбайдан парторг Илдар абый Садриев – оештыручы, башлап йөрүче тапшырды. Ә Толымбай яшьләрен исә безнең Дәвеш авылыннан парторг Фәхри абый Гыймадиев белән шушы фестивальне оештыруга бөтен көчен куйган Фирдүс абый Галимов бүләкләде. Миңа шул вакытта Илдар абый кулыннан «Красная Москва» дигән ислемай алырга туры килде. Ул вакыт өчен моннан да зуррак бүләк юк иде инде. Фестиваль кичен янәдән клубта концерт, төрле чыгышлар белән дәвам итте. Җәйнең икенче өлешен Толымбайга барып, шундый ук концерт һәм ярышларны уздыра идек. Толымбайның матур түгәрәк аланы, төнбоеклы күле әле дә күз алдымда тора.

Мондый шатлыклы мизгелләргә 50 ел вакыт үткәч, 2020 елда Дәвеш авылында янәдән Толымбай яшьләре белән очрашу уздырдылар. Бу очрашуны Толымбайдан Илдар абыйның улы Раил Садриев белән Дәвеш кызы Фирая Гыймадиева оештырды. Дәвеш авылына җан керде, яше-карты клубка агылды. Клуб шыгрым тулы, мин дә зур дулкынлану белән ике авыл яшьләренең концертын көтеп утырдым. Аларны караганда үземнең яшьлегемә кайткандай булдым. Соңыннан ике якның

оештыручылары – Раил Садриев белән Фирая Гыймадиеваның сәхнәгә чыгып: «Без электән килгән «дуслык күпере»н ныгытырга уйладык», – дигән сүзләренә кушылып, мин күңелемнән: «Ә бит ул «күпер»нең беренче субайларын без салган идек. Сез аны тагын да ныгытыгыз, дәвам итегез!» – дип өстәп куйдым».

Илгизәр Хөсәенов: «Җыр бәйрәме спорт белән үрелеп барды»

«1971 елның декабрендә концертта беренче мәртәбә баянчы буларак катнаштым. Камил Хөсәенов, Фирдүс Галимов, җырчылар Роза Мөхәммәтшина, Әнәс Халитов, Галиябану Сәлимовалар белән беренче мәртәбә концерт куйганым аеруча хәтердә калды. 1972 елдан соң, Фирдүс абый Галимов киткәч, фестивальләр туктап торды. 1976 нчы елларда яңадан елына ике мәртәбә оештыра башладык: февральдә алар безгә килсә, мартта без бара идек. Җыр бәйрәме спорт бәйгеләре белән үрелеп барды».

Илсур Хәсәнов: «Сәхнәдән һәм җирдән аерылганым юк»

«Бабам Кадыйр Мөхәммәдҗанов колхозның беренче рәисе булган. Заманында ул Габдулла Тукай белән бергә укыган. Тукайның шаянлыгы-шуклыгы турында бик еш искә алырга ярата иде бабаем. Соңрак ул Германиядә әсирлектә булган. Бабам янында үстем: җор телле, җырга-моңга бай кеше иде мәрхүм. Үземнең дә, 50 елдан артык авыл хуҗалыгы тармагында эшләсәм дә, сәхнәдән аерылганым юк.

Агач клубка 21 думбыра кайтканын яхшы хәтерлим. Без мәктәптә укыганда ук толымбайлылар белән фестивальләр оештыра башладык. Буаларга да барып чыгышлар ясый идек. Сәнгать һәм спорт уеннары белән үрелеп барды. Халык клубка сыймый иде. Шушы ансамбльләр күп яшьләрне кавыштырды, гаиләле итте. «Әти кайтты» спектаклендә баш рольне уйнаганым әле дә истә. Әлеге ансамбль 2000 нче елларгача гөрләп эшләде. Сәнгать җитәкчесе Илгизәр абыйны халык күтәреп кенә йөртми иде. Искиткеч моңлы якташыбыз ул. Шушы ансамбль республикабызга күп талантларны бирде. Мәсәлән, Татарстанның атказанган артисты Илсөя Гайнуллина (Төхвәтуллина), профессорлар Хәлил Сәлимов белән Шәрифҗан Сәлитов, аның кызы – музыка белгече Фәридә ханым».

Гөлназ Камалова: «Бөтен авылны гөж китерде»

«1969 елның июнь аенда безнең авыл яшьләре белән Буа районының Толымбай авылы яшьләре катнашында фестиваль була дигән хәбәр бөтен авылны гөж китерде. Без, бала-чага, фестивальнең нәрсә икәнен дә белмичә, кызыксынып көттек бу вакыйганы. Авылыбызга Толымбайдан бер төркем егетләр-кызлар килеп төште. Зөя елгасы буендагы стадионда ике авыл яшьләренең очрашуы футбол уйнау белән башланып китте. Ә стадион яны халык белән тулы иде. Бәйрәм кич белән клубта дәвам итте. Бу мавыктыргыч, күңелле очрашулар кыш көне дә узды. Авылның яше-карты нарат урманына ашыкты. Ә анда ике авыл яшьләре арасында чаңгы ярышлары оештырылды».

Дәвешнең булдыклы егетләре Илшат Кәримов, Илсур Хәсәнов һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон

Галия Гәрәева: «Мәхәббәт хатлары да алыша идек»

«Толымбайга «Сулган чәчәкләр» дигән спектакль куярга барганыбызны яхшы хәтерлим. Мин баш рольне – Сараны уйнадым. Толымбайлылар белән бик аралаштык, хәтта мәхәббәт хатлары да алыша идек».

Гөлгенә Исмәгыйлева: «Мәүҗүдә әптиләргә кич кунарга озаттылар»

«Әти-әниләр карт булу сәбәпле, читкә китмәдем. 4 нче класста укыганда Бугага, 4 литрлы бидон күтәреп, сөт сатарга бара идек. 5 нче класста укыганда 50 сутый чөгендер җире бирәләр иде. Көзен ындыр табагында икмәкнең көшелен чала идем. Үсә төшкәч, кукуруз, бодай басуында чүп утый идек. 8 нче класста 1 гектар чөгендер җире бирәләр иде. Яныбызда күл бар. Кичләрен шунда су коенгач, бөтен ару-талулар онытылып китә иде. Үзешчән сәнагать түгәрәгенә бик күптәннән катнашып килдем. 8 яшемдә үк Йосыф абый Рыбаков мине зур класслар янына концертта катнашырга кертеп җибәрә иде. Иң беренче «Мәк чәчәге», «Уракчы кыз»ны җырладым.

1968 елның 7 июнендә Илдар абый, бер төркем егет-кызларны оештырып, Апас районының Дәвеш авылына алып килде. Егетләр көне буе футбол уйнады. Кичке якта КВН булды. Аннан соң зур концерт оештырдык. Безне, берничә кызны, Мәүҗүдә әптиләргә кич кунарга озаттылар. 1972 елда Дәвешкә килен булып төштем».

P.S.: Истәлекләрне озак дәвам итәргә булыр иде. Әлеге фестиваль бик күп кешенең яшьлеген ямьләгән, аңа үзен күрсәтергә, сөйгән ярын табарга ярдәм иткән, соңыннан илгә тугры, намуслы һәм булдыклы ул-кызлар үстерергә рухи көч биргән. ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар, журналистлар һәм сәнгать әһелләре октябрь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә.
Менә алар:

1 октябрь – язучы, юмор-сатира остасы, публицист, 1985 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Тукай районының Иштирәк авылы тумасы **Рафис Хәсән улы Сәлимҗанов**ка 70 яшь (1952);

6 октябрь – театр тәнкыйтьчесе, сәнгать фәннәре докторы (1993), профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТРның атказанган фән эшлеклесе (1997), 2007 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, Актаныш районының Түмерҗә авылы тумасы **Гали (Мөхәммәтгали) Гыйльмегали улы Арслановка** 75 яшь (1947);

11 октябрь – җырчы, нашир, эшмәкәр, ТРның халык артисты (2009), Арча районының Симетбаш авылы тумасы **Габделфәт Габдерахман улы Сафин**га 60 яшь (1962);

15 октябрь – журналист, дәүләт эшлеклесе, философия фәннәре кандидаты, РФ Хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендәге премиясе лауреаты (2009), Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, Башкортстанның Уфа шәһәре тумасы **Зилә Рәхимьян кызы Вәлиева**га 70 яшь (1952);

18 октябрь – драматург, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1996), 1982 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Яшел Үзән районының Бакырчы авылы тумасы **Юныс Габдулла улы Сафиуллин**га 75 яшь (1947);

21 октябрь – шагыйрә, 2013 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, Түбән Кама районының Тоба авылы тумасы **Илзирә Сәмигулла кызы Вәлиуллина-Шаһиева**га 50 яшь (1972);

22 октябрь – шагыйрә, прозаик, мәсәлче, мөгаллимә, С.Сөләйманова исемендәге премия лауреаты (2021), 2019 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире, Яңа Чишмә районының Чаллы Башы авылы тумасы **Лилия Рәфхәт кызы Фәттахова**га 50 яшь (1972);

27 октябрь – прозаик, шагыйрь, публицист, композитор, журналист, 2005 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, Саба районының Түлешкә авылы тумасы **Рөстәм Зәет улы Зарипов**ка 70 яшь (1952).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов



Ханкан (Гонконг) порты. XIX гасыр ахыры

Ханканнан китү

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Инде бередән туры Сингапурга китәргә җыенам. «Ориентал» ширкәтенең «Азия» пароходына, 75 доллар 5 цент түләп, икенче дәрәҗәдәге каютага билет алдым.

Һиҗри 1327 ел[1], мөбарәк Рамазан аеның 3 нче көнендә, юл йөгемне төянеп, Ханканнан китәр өчен пристаньга килдем. Мине озатырга дип, таныш-белеш имамнардан шактый кеше җыелган иде. Һәрберсе юлга дип җиләк-җимеш кебек нәрсәләр китергән.

Мөхеддин әфәнде җәнапларының корабы яр буенда әзер тора иде, минем йөкне шуңа төядек. Кораб белән барып, пароходка күчеп утырачакмын. Озатырга килгән кешеләрнең кайберләре белән ярда ук саубуллаштым, калганнары безнең белән бергә пароходка кадәр барачак.

Нәкъ сәгать уникедә пароходка кадәр килеп җиттек. Кереп урнашуга, пароход кузгалып та китте. Озатырга килгән дуслар утырган кораб 1 сәгать 20 минутка

[1] Яңача ел исәбе буенча 1909 ел *(тәрҗ.иск.)*.

якын пароход артыннан ияреп барды. Мин уйланам: Аһ, исламият! Ни дәрәҗәдә бөек тәгълимат һәм никадәр камил тәрбия! Бу кешеләр белән минем арамда исламияттән башка бернинди дә бәйләнеш юк. Бу дуслыклар, бу ихтирамнар бары тик минем мөселман булуым өчен генә. Югыйсә мин сәүдәгәр түгел, бу кешеләр белән матди мөнәсәбәткә бернинди хакым да, сәләтем дә юк. Таныш булуыбыз да шул берничә көндә хасил булган дини мөнәсәбәт һәм шуннан барлыкка килгән дуслык, дөресрәге, Аллаһы Тәгалә хакына дуслык.

Без утырып киткән пароход – дөньядагы иң зур пароходларның берсе. Тизлеге 16 мил[2]. Эче шәһәрне хәтерләтә. Юлчылар арасында төрле милләт кешеләре – инглизләр, американнар, французлар, японнар, кытайлар бар. Мөселман кешеләре буларак беренче дәрәҗәдәге каютада баручы Мөхәммәд Хәсән Нәмази Сахиб белән икенче дәрәҗәдәге каютада баручы мин бар.

Пароходның матрослары барысы да диярлек мөселман һиндләр, бары тик капитаннары, төрле дәрәҗәдәге баш кешеләре генә инглизләр иде.

Нәмази Сахиб әйберләрен урнаштыру белән мәшгуль иде, ахры. Мин палубада ялгызым гына йөренәм. Букадәр зур пароходка күрә, юлчылар бик аз иде. Бер сәгать тирәсе вакыт үткәч, ашка чакырып барабан кактылар. Безнең Рамазанда кагыла торган барабан кебек үк булмаса да, бераз шуңа охшап тора иде.

Инде мөшкеллекнең зуры башланды: ашарга барачакмын, ләкин тел белмим. Төрле ризыклар булачак. Ул тозакка капмас өчен, нишләргә икән инде?.. Ач калып та булмый. Әлбәттә, теләмәсәм дә, «Әһли Китапның бугазлаганнары» диярга мәҗбүр булачакмын, ләкин бугазлау белән дә хәләл булмаячак – теге бәдбәхет хайван бар ла, аны нишләтергә, каян беләчәкмен?!

Ничарадан бичара, дигәндәй, бу юлы саклык өчен сыр, май, балык уылдыгы һәм балыктан кала һичбер нәрсәне авызга алмадым, юлаучы булуыма да үкендем. Һич булмаса, уразага кирәсем калган икән, бер ашауны ашамас идем.

Мөхәммәд Хәсән Нәмази

Нәмази әфәнде – чын мөселман, хөрмәтле шәхес, гаять яхшы, бик галиҗәнап кеше. Үзе беренче дәрәҗәле каютада барса да, анда бары тик ашарга һәм йокларга гына керә, башка вакытларда гел минем каютамда була иде.

Нәмази Сахиб белән арабызда гаять самими сөйләшүләр, фикер алышулар булды: сәясәттән алып, Госманлы һәм Иран дәүләтләренең хәлләренә кадәр барысы хакында да сөйләштек.

Нәмази җәнаплары – шактый киң мәгълүматлы, илләр күргән кеше. Күбесенчә исламиятнең киләчәге турында фикер йөртә иде. Бу хакта мин аның белән берничә тапкыр фикер алыштым. Беркөн шулай сөйләшеп утырганда, аңа болай дидем:

– Мөселманнарның киләчәге турында нәрсә уйлыйсыз, ничек итсәк, дошманнарыбызга каршы үз урыныбызны саклап кала алырбыз икән? Бу хакта фикерегез нинди?

– Мин, – диде ул, – бу мәсьәлә турында бик күп уйланам, ләкин әлегә кадәр бернинди чара да уйлап таба алганым юк. Бу хакта бигрәк тә Сезнең фикерегезне беләсем килә. Әлбәттә, үз фикеремне дә әйтермен. Сезнең фикерегездән һәм тәҗрибәгездән файдаланырга телим. Бөтен мөселманнар арасында җитди

[2] Диңгез миле якынча 1 километр 852,2 метр тәшкил итә *(тәрж.иск.)*.

бәйләнеш һәм самими бергәлекне мин ислам дөньясының хәлен яхшырту өчен бердәнбер чара дип саныйм. Болар булмаса, бөтен мөселманнар сүнүгә һәм үлемгә хөкем ителәчәк. Ирандамы, Госманлы дәүләтендәме – кайда гына булса да, дәүләт идарәсе кем кулында булса да – бердәмлек булмаса, дәрәҗәләре дә булмаячак. Берләшә алсалар, кайда гына, кайчан гына булса да, нинди мәмләкәттә булсалар да, милли һәм дини хокукларын саклый алачаклар. (Гаять нык, карарлы, саф мөселман кешесе!)

– Бердәмлеккә килү юллары, берләшү чараларыниләр?

– Бердәмлеккә илтә торган юлны, берләшү чараларын эзләп торырга да кирәкми. Аллаһының «Үз бавыңа нык итеп тотын» фәрманы безгә фарыз икән, көнгә биш тапкыр мәчет-шәрифләрдә җыелышабыз икән – моннан да зуррак чара ни була алсын?! Мин үзем шулардан башка чара турында уйлауны кирәксез дип саныйм. Безгә бары тик боларның кыйммәтен аңларлык калеб кенә кирәк. Шулай да, тагын да ачыграк итеп шуны әйтергә телим: Җәнабе Хакның «Сәлам – һидаяткә буйсынганнарга» (Та-Ха: 47), – дип гомумиләштергән сәламен әгәр Сез Али өчен күпсенсәгез, без дә шуңа җавап итеп, Әбүбәкер белән Гомәргә бәддога укысак, әлбәттә инде, сез дә, без дә берләшүгә якын да килмәячәкбез. Безнең шигыйләр барысы да диярлек бу өммәтнең чиктән ашканнары исәбендә. Сезнең сөнниләр дә җиңел акыллы хокук белгечләрегезнең кулында, «мәет юучы кулындагы мәет» хәленә калганнар. Әлеге ике хәл бу өммәтне кабергә сөйри, ә безнең моннан хәбәребез юк. Әлегә кадәр, сез – голамәнең әсирлегеннән, без – мөҗтәһидләр[3] әсирлегеннән котыла алмыйбыз. Менә моның чарасын табу бераз кыенрак.

– Сөнниләр үз тарафларыннан хуш күрү, үткәреп җибәрү мөгамәләсен күрсәтергә риза булырлар дип уйлыйм. Али галәйһиссәлам вә галәйһиррахмә вә-р-рыдван да дия алабыз. Ал’и Мөхәммәдкә булган ярату хисендә аерылмыйбыз. Без үз ягыбыздан һәртөрле килешүгә бара алырбыз.

– Сүзләремне сөйләгәндә, Сезнең йөзегезгә карап тордым. Мин: «Җиңел акыллы хокук белгечләрегез», – диюгә, йөзегез үзгәреп китте. Менә Сез дә шулай, иң хөр кеше буласы урында, иярү Сезнең дә холык-табигатегезгә әйләнгән. Бу авыр сүзләрне күтәрә алмадыгыз. Авыр сүзләр дисәм дә, алар сезнең-безнең колакка гына авыр ишетелә, чөнки без андый сүзләр ишетмәгән. Чынбарлыкта һич кенә дә авыр-фәлән түгел, голамәбез арасында җиңел акыллылар бик күп булган һәм әле дә бик күп. Әлегә без дә, сез дә чын кеше кытлыгы гасырында яшибез.

Шул рәвешле Нәмази әфәнде белән бик күп фикер алыштык. Сүз арасында бик ачыклары да әйтелде.

Чынлыкта, мин үземне беркадәр хөр һәм азат дип уйлый идем, тик җәнабе Нәмази миннән һәрьяклап өстен чыкты. Шул ук вакытта Нәмази кардәшемнең гаять диндар һәм дини ныклыкка ия мөселман булуы да аңлашылып тора иде.

Ханканнан кузгалып киткән көнне Нәмази җәнаплары уразада иде. Болай дип сорадым:

– Сәфәрдә булган көннәрнең уразасын аннан соңгы көннәргә казага калдырырга рөхсәт ителгән, ник ураза тотасыз?

– Бүген, теләсәм дә-теләмәсәм дә, ураза тотачакмын, миннән тормый. Мин юлга чыкканчы уразалы идем, китүебез төштән соң булды. Сайлау мөмкинлегем калмады, иртәгә, Аллаһының ярдәме белән, сәфәрдән файдаланырбыз.

[3] Мөҗтәһид – ихтыяҗ булганда аятьләрдән һәм хәдисләрдән хөкем чыгаручы дин галимнәре *(тәрҗ.иск.)*.

Менә бер сәүдәгәрнең дини мәгълүматы. Безнең сәүдәгәрләребез арасында дин хокукларын белүче, булса да, бик сирәктер.

Мондый кешеләр белән танышкач, кызыкмый булдыра алмыйсың: гарәп теле – мөкәммәл, фарсыча – үз теле, урду теле – мөкәммәл, инглизчәсе дә мөкәммәл, дини ныклыгы да мөкәммәл. Шулай булгач, мондый кешегә күпме генә кызыксаң да, аз булыр.

Без пароходта Нәмази җәнаплары белән гел бергә, бер-беребездән күбрәк мәгълүмат алып калырга тырыша идек.

Беркөнне кытайларның холык-фигыле, әхлагы турында сорау бирдем. Ул үз фикерләрен болай аңлатты: «Кытайларның бүгенге хәлләре бик үк яхшы түгел, үзегез дә күргәнсездер. Җаһиллек изгән боларны. Ул хакта әллә ни күп сөйләп тормыйм. Әхлакларына килсәк, кытайларның холык-фигыле әлегә бозылмаган. Без аларны күбесенчә сәүдә мөгамәләсендә күрәбез. Сүзләренә тугры, нык кешеләр алар. Сүзләреннән һичбер вакыт кире кайтмаслар, сүзләре кыйммәтле кәгазь кебек. Бервакытта да башкарылган сату-алудан кире чигенмәсләр. Бер тауарны алырга карар кылганнан соң: «Бу тауар минеке» – ди, бернинди ышаныч кәгазенең дә кирәге юк. Хәтта ике сәгатьтән тауарның бәясе төшсә дә, берни үзгәрми. (Сату-алуда килешкәннән соң төзелгән) килешү кәгазем, кыйммәтле кәгазьләрем-фәләнем юк, дигән сүзләрне түбәнлек дип бәялиләр. «Минем сүзем – килешү кәгазе», – ди дә китә. Ничек килешенгән булса, шулай кала. Бу яктан караганда, кытайларның мәдәнилеге бөтен милләтләрнекеннән дә өстенрәк, дип әйтергә мөмкин.

Кытайларның сәүдә эшендә иң беренче кагыйдәләре – икътисад кануннарына буйсыну. Икенчесе – тугрылык, дөреслек. Язганымча, килешү кәгазе бармы-юкмы – әһәмияте юк. Сату-алуда: «Фәлән көн, фәлән сәгатьтә», – дип, вакытны сәгатенә кадәр билгели. Әгәр берәр каза килеп чыкмаса, шул вакытка соңга калмыйча килә.

Тик чит ил кешеләре, аеруча инглизләр, кытайларга бик начар мөгамәлә күрсәтәләр. Мыскыллау-кимсетү сүзләре әйтәләр. Инглиз милләте мин-минлекле, киберле милләт, үзләреннән башкаларны кеше урынына да куймыйлар. Бик начар холыклы милләт.

Кытайлар әлегә инглизләргә карата сабырлык күрсәтәләр, алар белән яхшы яшәргә тырышалар. Бу үтәчәк дип уйлыйм. Бер көн килеп, боларның һәммәсен себереп түгәчәкләр.

Һиндләр – элек-электән әсирлеккә күнеккән милләт. Англия хөкүмәте күпме генә золым итсә дә, һинд кешесе тавышын чыгармый. Тик кытайлар андый түгел. Вакытлыча түзсәләр дә, ниһаять, бер көн килеп, мәйданда үз көчләрен күрсәтәчәкләр, чөнки болар гел хаким милләт булып яшәргә күнеккәннәр. Боларны һиндләр белән чагыштырырга ярамый, болар, билгеләп үткәнемчә – хаким милләт.

Һиндләр, Мисыр халкы, берәрсе килеп: «Мин сезгә патша булдым», – дисә, шунда ук буйсынганнар, чөнки болар – буйсынырга күнеккән милләтләр.

Кытайлар меңнәрчә ел хаким милләт булып яшәгәннәр, буйсынуны алай бик тиз генә кабул итә алмаслар. Шуның өстенә, болар – яратылышлары белән куәтле, сугышчан милләт. Тик әлегә дәүләтләренең мәнфәгате өчен сабыр итәләр. Бу милләт киләчәктә: «Үч!» – дип әйтер. Мондый өмет бар.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: бу милләттә иҗат көче юк, гел җисми көч, сәләтләре табигатьләрендәге сәләт түгел. Белемнәре – инглиз белеме, һич

үзгәртелмичә кабул ителә. Тик инглизләр һичбер вакыт боерыклары астындагы халыкларга фикри белем-тәрбия бирмәсләр. Алар бөтен бу халыкларны сукырлар хәлендә тоталар. Һиндстанны басып алганнарына 100 елга якын вакыт үтте, ләкин һиндләр арасында ник бер белем иясе, ник бер фикер иясе булсын?!

Мисыр халкына карасак та, шул ук хәл: 30 ел буйсыну астында яшиләр, Мисыр өчен 30 кеше дә тәрбияли алмадылар, алмаслар да. Мисыр халкы инглизләрдән ала алачак мәдәният бик чикләнгән.

Гольч паша – барон, генерал-фельдмаршал Вильгельм Леопольд Ко́льмар фон дер Гольц (1843-1916), 1883 елдан Госманлы солтанаты хезмәтендә, 1909-1912 нче елларда – Төркиянең Югары хәрби шура вице-президенты, 1914 елның ноябреннән 1915 елның апреленә кадәр – солтан Мәхмүд Vнең адъютанты

Мин биредә бернәрсәне башыма сыйдыра алмыйм, шуны аңлатып бирүегезне аеруча үтенәм. Сәбәбе нәрсәдәдер – белмим, безнең көнчыгыш милләтләренең барысы да диярлек көнбатыш милләтләренә кирәгеннән артык ышаналар, бигрәк тә эш башында торучыларыбыз бөтен нәрсәне аурупалылар белән киңәшләшеп эшлиләр. Барысын да белмим, тик безнең иранлылар һәр эштә бер аурупалы фикеренә әсир төшкәннәр. Госманлыларны да шулай күрәм. Мин үзем алар белән мөнәсәбәттә һичбер вакыт улкадәр үк беркатлы була алмыйм, чөнки үзем белән чагыштырам. Мин – сәүдәгәр, башка бер сәүдәгәр, – минем дустым яки туганым булса да хәтта, миңа көндәш булачак сәүдә кешесе. Сәүдә эшендә әгәр минем белән киңәшсә – мин никадәр генә галиҗәнап булсам да – үз сәүдәмә күпмедер көндәш булачагын хис итү белән үк, улкадәр галиҗәнаплык күрсәтә алмам.

Әле газеталарда күрдем: яңа Госманлы хөкүмәте, гаскәри үзгәртеп корулар өчен, Гольч пашаны китертте. Бу кеше Хамид заманында да анда иде, үзгәртеп корган булса, корган булыр иде инде. Менә шул: мин Гольч пашага карата мөнәсәбәтемдә бик беркатлы була алмыйм.

Гольч пашаның яхшы һәм галиҗәнап кеше булуы бик мөмкин, тик ул Госманлы гаскәренең Герман гаскәреннән өстен булуын теләмәс. Паша кадәр паша кешенең исә, милли хисләрдән мәхрүм калган булуы мөмкин түгел.

Менә шундый фикергә таянганга, мин бу безнең көнчыгыш милләтләренең улкадәр беркатлы булуларының сәбәбен аңлый алмыйм. Иран шаһы бер рус офицерының кулында, ул ничек әйтсә, мәмләкәтне шулай идарә итә. Кытайлар

да мәмләкәтләрен инглиз офицерлар фикеренә ияреп идарә итәләр. Безнең көнчыгыш милләтләрендә, никтер, мөстәкыйль фикер йөртү юк.

Бу яктан, Көнчыгыш милләтләре арасыннан японнарны аерып куярга тиешбез. Алар бөтен нәрсәне башта Аурупадан алалар, биш-ун ел үтүгә тәмам үзләштерәләр. Бүген кечкенә генә Япониянең икътисади кереме миллиардларга җитте. Мин Япония фабрика-заводларының күпчелеген барып күрдем. Җитәкчеләрне, эш башында торучыларны әйтәсе дә юк, хәтта осталар, эшчеләр арасында да бер генә чит ил кешесе дә күрмәдем. «Япония – японнар өчен!» – диләр, шуңа инанганнар.

Бөтен Кытай иленә, Госманлы һәм Иран мәмләкәтләренә карасак, илнең иң мөһим һәм дәрәҗәле урыннарында чит ил кешеләренең торуын күрәбез. Мондый мәмләкәт нык була алмый. Мин үзем Иран кешесе. Иранда өмет калмады. Иң куркыныч чиребез – дәүләт кешеләренә кытлык».

Шул рәвешле Нәмази җәнаплары миңа бик яхшы юлдаш булды. Төнге йокы вакытында гына аерылып тора идек. Кайчакларда мин, язуларымны язарга дип, бер-ике сәгатькә үзем генә кала идем.

Пароходның авырлыгы – 7376 тонна, 6500 айгыр куәтендә, моңа һич шикшөбһә юк.

Икенче дәрәҗәдәге каюталарда баручы юлчы бик аз. Болар арасында ике кытай кешесе бар. Ашау вакытында бөтен юлчылар бер табынга җыела, ә теге ике кытай өчен аерым табын коралар иде. Ризык шул ук, вакыты да шул ук, тик өстәлләре генә аерым. Мин моның хикмәтен аңлый алмыйм. Һәр ашауда шулай. Милли киемнәре дә бик пөхтә. Ни сәбәпле безнең белән бер табынга утырмыйлар? Мин берничә көн шуны уйлап бетерендем, ниһаять, беркөнне Нәмази әфәндедән: «Бу ник шулай икән?» – дип сорадым. Ул да белми икән, официантны чакырып сорады. Официант исә: «Кытайлар», – дип җавап бирде. Гаепләре – кытай булуларында икән лә. Югыйсә алар да безнең кебек үк акча түләгәннәр, безнең кебек үк Адәм угыллары. Бары тик чәчләре белән милли киемнәре генә Аурупа мәдәнияте тарафыннан түбән һәм җирәнгеч санала.

Пароход хезмәткәрләре

Алда да әйтеп үткәнемчә, пароходның матрослары барысы да диярлек һинд мөселманнары. Биредә болар турында аерым мәгълүмат бирүнең кирәге дә юк иде, тик «Галәме Ислам»ның 79 нчы битендә[4] японнарның матрослары турында язган идем. Биредә исә, болар – дөньяның иң мәдәни милләтләренеке булган иң зур фирманың иң зур пароходының матрослары. Мондый пароходларның юлчыларының да күбесе югары фикер ияләре булырга тиеш. Әлбәттә инде, матрослар да шул нисбәттә булырга тиеш. Тик кызганыч, мең кат кызганыч: ни инглизләр, ни һинд матрослары арасында кулына китап тоткан бер генә кешене дә күрмәдем. Берничә һинд матросыннан: «Укый-яза беләсеңме?» – дип сорадым. Бик кызганыч, барысы да: «Юк», – дип җавап бирделәр. Бер инглиз матросыннан да сорадык. Нәмази әфәнде сорады. Ул да: «Белмим», – дип җавап бирде. Үзе кып-кызыл булып кызарды. Очраклылык та булуы мөмкин, әлбәттә.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[4] Бу – әсәрнең госманлы-төрек телендәге басмасындагы бит саны *(тәрҗ.иск.)*.

Ислам. Дини сүзлек

Амин (яһүдичә – дөрес, хак булсын) – кабул булуны сорауны, дога яки гыйбадәтнең тәмамлануын аңлата торган сүз.

Ахирәт (гарәпчә – мәңгелек дөнья) – ислам дине өйрәтүенчә, кеше, Кыямәт көнендә кабат терелеп, мәңге яшәячәк. Бәндәләрнең әнә шул мәңгелек галәме «ахирәт» дип әйтелә.

Ахун (фарсыча – остаз) – муллалардан, мөхтәсибләрдән югарырак рухани дәрәҗә, аерым төбәкләрдә руханилар башлыгы.

Ахырзаман (заман ахыры) – Коръән буенча, кешеләрнең җир йөзендәге табигый тормышы вакытлы гына күренеш: «Белегез, дөньядагы тормыш – уен һәм шаяру, бизәнү һәм үзара мактанышу» (Коръән: 57 нче сүрә, 19 нчы аять), «Дөнья тормышы – ялган рәхәт кенә» (Коръән: 57 нче сүрә, 20 нче аять).

Ислам дине өйрәтүенчә, күпмедер вакыттан соң җир йөзендәге табигый тормыш тәмам булачак, барлык кешеләр дөнья тормышында кылган эшләре өчен Аллаһ каршында хисап бирәчәк. Шулай итеп, мәңгелек тормыш – ахирәт башланачак. Дини әдәбиятта җир йөзендәге табигый тормышның Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән бетерелүе ахырзаман яки заман ахыры дип атала.

«Ахырзаман китабы» – XIX гасырда һәм XX гасыр башларында татарлар арасында киң таралган «көйле китап»ларның берсе (мөәллифе – Сөләйман Бакыргани дип фараз ителә). Һәр дүртьюллыкның соңгы юлы: «Андыйн артык тәкый гаҗәп дыңлары вар», – дигән җөмлә белән бетә. Шуңа күрә аны «Тәкый гаҗәп китабы» дип тә атаганнар. Бу китапның эчтәлеге ахырзаманны һәм Кыямәт көнен сурәтләүдән гыйбарәт.

Язма «Ислам. Белешмә сүзлек» (төзүчесе – Заһид Шәфигый, фәнни редакторы – Равил Үтәбәй-Кәрими) китабын (1993) файдаланып әзерләнде. ■

безнен мирас №10 октябрь 2022

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре[1]

Әхмәдвәли Рәхими

61

Әбү Муса разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Ике салкын вакыт намазын укыган адәм җәннәткә керер: иртәнге һәм икенде».

Укы һәм исеңдә калдыр!

62

Буридә разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Шатлыклы хәбәр: караңгы төннәрдә мәчеткә йөручеләргә Кыямәт көнендә камил нур биреләчәк».

Укы һәм исеңдә калдыр!

63

Җәбир разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Намазның фазыйләтлесе кыям[2], кыйраәт[3] озын булганы».

Укы һәм исеңдә калдыр!

64

Әбү һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Әгәр өммәтемә мәшәкать салуым булмаса, өммәтемә ястү намазын тәэхир белән *(соңрак)* укырга[4] һәм һәр намазда мисвәк кулланырга боерыр идем».

Укы һәм исеңдә калдыр!

65

Әнәс разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Кояшның саргаеп шайтан мөгезләре арасына кергәнен (ягъни мәкруһ вакытка кадәр) көтеп, Аллаһы Тәгаләне аз гына куңелдә тотып укылган намаз – монафыйк намазыдыр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

66

Буридә разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Икенде намазын куйган *(калдырган)* адәмнең гамәле юкка чыкты».

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

[1] Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

[2] Кыям – намазда аягүрә тору.

[3] Кыйраәт – Коръән сүрәләрен яттан уку.

[4] Ястү намазын төн уртасына чаклы кичектерергә рөхсәт ителә.

Текстны басмага ***Айсылу Вәлиева*** *әзерләде.*

Безнең мирас №10 октябрь 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Уналтынчы дәрес

Мәдинә халкының Пәйгамбәрне (с.г.в.) каршы алуы. Мәчет салдыру. Исламиятнең таралуы. Падишаһларга илчеләр җибәрү. Мәкканең алынуы. Пәйгамбәрнең (с.г.в.) вафаты.

Мөгаллим: Пәйгамбәрнең (с.г.в.) Мәккәдән чыгуын ишетү белән, сәхабәләр көн саен, Мәккә юлына чыгып, аны көтеп торалар икән. Көннәрдән беркөнне каршы чыгучыларга көтелгән кунаклар күренгән. Болар куанычларыннан нишләргә белмәгәннәр. Аны чолгап алып, хәл-әхвәл сорашканнар. Кайсы дөянең тезгененнән, кайсы ияреннән, кайсы аннан, кайсы моннан тотканнар. Шулай итеп, пәйгамбәр (с.г.в.), сәхабәләр белән чолганган хәлдә, Мәдинәгә барган. Мәдинә халкы аны гаять шатлык белән каршы алган. Бала-чага, ул Мәдинәгә керү белән, шатлык мөнәҗәтләре әйткән. Мәдинәдә шатлыкның иге-чиге булмаган. Ул көн Мәдинә бер бәйрәм төсен алган. Мәдинә урамына керү белән, сәхабәләрнең һәркайсының пәйгамбәрне (с.г.в.) үзләренә төшерәселәре килгән. Кайсы дөянең тезгененә, кайсы ияр агачына тотынган. Шулай итеп, аларның һәркайсының пәйгамбәрне (с.г.в.) кунак итеп, савап аласылары килгән. Пәйгамбәр (с.г.в.) боларга дөяне үз ихтыярына куярга кушкан. Дөя кая барып чүксә, шунда йорт салачагын әйткән. Бервакыт дөя, бер ындырлыкка барып туктап, шунда чүккән. Шуннан соң пәйгамбәр (с.г.в.) дөядән төшкән. Дөянең бу җиргә килеп чүгүе Аллаһы Тәгаләнең әмере берлән булган икән. Шунлыктан пәйгамбәр (с.г.в.), шул урынны сатып алып, бер зур мәчет салдырган һәм, шуңа кушып, үзенә өй торгызган.

Пәйгамбәрнең (с.г.в.) дөясе чүгү белән, Әбү Әюб әл-Әнсари дигән бер сәхабә, тиз генә килеп, дөя өстеннән пәйгамбәрнең (с.г.в.) әйберләрен (кирәк-яракларын) алган. Шунлыктан пәйгамбәр (с.г.в.), үзенә өй салганчы, аның өендә кунак булган. Әбү Әюбнең тиз генә килеп дөя өстеннән әйберләрен алуы да пәйгамбәрне (с.г.в.) кунак итү өчен булган икән. Шулай итеп, сәхабә пәйгамбәрне (с.г.в.) кунак итү мәртәбәсенә ирешкән. Бу – бик зур мәртәбә, шулаймы?

Шәкерт: Әлбәттә, зур мәртәбә.

Мөгаллим: Зур мәртәбә булмыймы соң! Пәйгамбәр (с.г.в.) хәтле пәйгамбәр (с.г.в.) үзеңә кунак булып төшсен дә, ул зур мәртәбә булмасын! Бу – бигрәк тә зур мәртәбә, бигрәк тә зур бәрәкәт инде. Сәхабәләр һәркайсы аны үзләрендә кунак итәргә тырышканнар, ләкин Аллаһы Тәгалә бу бәрәкәтне Әбү Әюбкә

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

насыйп иткән икән. Менә шул вакыттан бирле пәйгамбәребез (с.г.в.) үлгәнче Мәдинәдә торган. Пәйгамбәрнең (с.г.в.) Мәккәдән Мәдинәгә күчүенә «һиҗрәт» диләр. Гарәпчәдән безнеңчәгә күчерсәң, ул «күчү» дигән сүз. Бу вакыт пәйгамбәр итеп җибәрелүенә унөч ел булып, яше илле өчтә булган. Мәдинә шәһәре хәзерге көндә дә шул урында. Әлеге пәйгамбәр (с.г.в.) салдырган мәчет тә бүгенге көндә бар, тик ул әллә ничә кат төзәтелгән, зурайтылган инде. Пәйгамбәрнең (с.г.в.) Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килүенә инде 1335 ел*. Мөселманнар ел хисабын пәйгамбәр (с.г.в.) Мәдинәгә күчкән көннән алып хисаплыйлар.

Мәдинәгә күчү белән, пәйгамбәр (с.г.в.) вә сәхабәләр иркен сулыш алганнар. Алар гыйбадәтләрен инде яшермәгәннәр, Аллаһы Тәгаләгә теләгәнчә гыйбадәт кылганнар. Мәдинә һәм аның тирәсендә дин яхшы ук таралган. Пәйгамбәр (с.г.в.) һәм сәхабәләрнең Мәдинәгә күчеп анда дин таратуларына Мәккә мөшрикләренең эчләре бик пошкан. Аларны ничек тә булса бетерергә, кырырга теләгәннәр. Шулай итеп, пәйгамбәр (с.г.в.) вә сәхабәләр белән алар арасында байтак кына сугышлар да булып алган. Бу сугышларның пәйгамбәр (с.г.в.) вә сәхабәләр өчен бик авырлары, бик кайгылылары да булган. Аларның берсендә пәйгамбәрнең (с.г.в.) бите бик нык җәрәхәтләнгән, мөбарәк теше дә сынган. Ләкин шулай була торып та, ул мөшрикләргә бәддога укымаган, киресенчә, хәер-дога кылган. Аллаһы Тәгаләдән аларны ярлыкавын сораган. Ахырда, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, пәйгамбәр (с.г.в.) вә сәхабәләр мөшрикләрдән өстен чыкканнар. Дин Гарәбстанның һәр тарафына таралган. Мәккә мөшрикләре үзләре дә иманга килгәннәр. Мәдинәгә килүгә сигез ел дигәндә, пәйгамбәр (с.г.в.), сәхабәләр белән барып, Мәккәне дә алган. Моннан соң инде Мөхәммәднең (с.г.в.) чын пәйгамбәр икәнлеге бөтен Гарәбстан халкына мәгълүм булган һәм барысы да аңа иман китергән, ул китергән дин вә шәригатьне кабул иткән.

Пәйгамбәр (с.г.в.), дингә бер гарәп халкын гына өндәп калмыйча, тирә-яктагы башка халыкларны да исламга өндәгән, чөнки Аллаһы Тәгалә аны җир йөзендәге бөтен халыкка пәйгамбәр (с.г.в.) итеп җибәргән. Шунлыктан, ул тирә-яктагы падишаһларның барысына да илчеләр күндергән, хатлар язган. Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килүгә ун ел тулып унберенчегә китү белән, пәйгамбәребез (с.г.в.) дөньядан киткән. Бу вакытта аның яше 63тә булган. Ул Мәдинәдә хатыны хәзрәти Гайшәнең өенә күмелгән. Пәйгамбәрнең (с.г.в.) үлүе Мәдинә халкына, бөтен әһле исламга әйтеп бетермәслек бер кайгы-хәсрәт булган. Һәр җирдә «аһ!» вә «ваһ!» тавышлары, елау вә сыкранулар ишетелеп торган. Ләкин ни чара, үлемнән һичкем котыла алмый шул. Менә шушы пәйгамбәр (с.г.в.) Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәлам дога кылып сораган, Муса вә Гайсә галәйһиссәламнәргә бирелгән китапларда аның хакында сөенеч булган пәйгамбәр (с.г.в.) инде. Ул – бөтен дөнья халыкларына җибәрелгән пәйгамбәр (с.г.в.). Мөхәммәд (с.г.в.) – пәйгамбәрләрнең иң соңгысы. Аңардан соң пәйгамбәр килмәгән вә килмәячәк. Шунлыктан ул Ахырзаман пәйгамбәре (с.г.в.) дип санала. Менә без дә – шул Ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәдкә (с.г.в.) ияргән вә аның шәригате белән гамәл кыла торган кешеләрбез.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

---

* Хәзер 1444 ел булды. – *Ред.иск.*

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Гали Хуҗи шигырьләре

Шагыйрь, 1936 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Гали Хуҗи (1912-1966) татар совет поэзиясендә поэмалар авторы буларак та билгеле. Ул утызынчы еллар азагында ук «Комсомолка» һәм «Хәсән күле» поэмаларын иҗат иткән. Шагыйрьнең шушы чордан соңгы иҗаты тулысы белән диярлек Бөек Ватан сугышы каһарманлыгын чагылдыруга багышланган. Сугыш елларында ул бу темага «Зоя Космодемьянская», «Россия», шагыйрь Фатих Кәримгә багышланган «Гражданин, солдат, шагыйрь» һәм башка поэмаларын язган, ә сугыштан соң, М.Җәлилгә атап, «Кырык хикәят» дигән поэмалар циклы һәм башка күп кенә әсәрләр иҗат иткән.

Кайчандыр:

«Мин солдатың әле – һаман сафта,
Бу – намуслы хезмәт итүем.
Үкендермәс, күзем йомган чакта,
Яшь гомернең болай үтүе», –

дип язган фронтовик шагыйрь 1966 елның 13 октябрендә Казанда вафат булды.

Таныш миңа завод егетләре

Яшьлек, диләр, үзе гүзәллек ул!
Ә кем аны шулай димәсен?
Бары сөя, сөелә белүдәме –
Гүзәллеге аның нидә соң?

Таныш миңа завод егетләре,
Бишектән үк иртә төшкәннәр;
Бик күпләре сугыш михнәтләрен
Бураздада татып үскәннәр.

Буразнадан – завод цехларына;
Яхшы түгел юлда соңлавы.
Колакларда йөргән башак шавын
Алыштырган металл чыңнары.

Кичке мәктәп, соңра кичке вузлар
Үзләренә дәшкән күпләрне;
Кайсылары инде – инженерлар,
Үтәгәннәр заман көткәнне.

Шулай атлый алар иртәгәгә,
Таптану юк бер үк урында;
Бергә килсәк, кызык бәхәс китә
Замана һәм шигырь турында.

Дөреслек күп алар карашында –
Чын җыр белән гаҗәп дус алар.
Чыгар, бәлки, алар арасыннан
Яңа Такташ, яңа Мусалар.

Яшьләр күңеле шундый хис-тойгыдан
Беркайчан да тормый бушанып.
Киләчәкне мондый алмашларга
Тапшырырга була ышанып.

Яшьлек, диләр, үзе гүзәллек ул!
Беләм аның шулай икәнен.
Гүзәллек ул, әгәр үз иңендә
Алып барса заман җилкәнен!

Күңел җилкәне

Кеше күңеле – үзе бер дәрья ул,
Кеше күңеле белми чикләрне;
Һәм яктырта өмет-хыяллары
Гомер күген – язгы йокләрне.

Хәтәр җилләр, беләм, сез тормышта
Күп дәрьялар аша искәнсез.
Чын мәхәббәт белән җырдан башка,
Кеше күңеле, гуя, җилкәнсез. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Тәүфикъ Әйди*гә хатлар

Аяз Гыйләҗев



Тәүфикъ Әйди. 1998 ел

* Тәүфикъ Әйди - прозаик һәм публицист, 1941 елның 1 маенда Мәскәү өлкәсенең Кривандино районындагы Туголеевский Бор бистәсендә туган. Бала һәм үсмер чагы Апас районының Түбән Балтай һәм Олы Бакырчы авылларында үткән.

18 октябрь, 1988 ел, Пицунда

Тәүфикъ, хәерле көн!

Миннән хат килеп төшәр дип исеңдә дә юктыр, үз эшең, мең мәшәкатең белән йөреп ятасыңдыр. Юк, сиңа мәшәкать өстәргә дә, эш кушып үтенергә дә җыенмыйм, мәгәр, хатны байтактан язасым килеп йөрим, гадәттәгечә, вакытны гына җиткерә алмыйм…

Еллар үтү белән акыл арта дип уйламыйм, алай да тәҗрибә беркадәр ишәя, тыгызлана дип беләм. Кайчагында бар булган акыл да, тәҗрибә дә ярдәм итми икән, хаталар китә, ялгышлар ычкына, «алай» дип фараз кылып буталасың, ә ул «болай» булып чыга. Синең алда түбәнчелек белән гафу үтенергә кирәк иде, белмим, Туфан кереп шуны сиңа әйтеп чыккандырмы, мин менә, соңарып кына булса да, гафу сорыйм. Син безгә караганда зирәгрәк, акыллырак, төплерәк булып чыктың. Әйе, без заманны үз калыбыбызга яраштырып, үзебез заманга яраклашып, бик шәп кыяфәтләр белән йөри бирдек, ә кемнәрдер без гомуми сүзләр белән зарланып, уфтанып йөргәнне саннар, кыю фактлар белән нигезләгән, өйрәнгән, сүздән олы эшкә күчә алган, без йомшак йодрыкларыбыз белән һава сөзгәндә, кулларына кылыч эләктереп алган икән! Мин үзебезнең куркаклыкны да, буш куык икәнлекне дә беләм, без барыбыз да наданлыгыбызны яшерергә өйрәндек тә бүтәннәр берни күрми, без бик шәпләр дип юанып йөрдек… Ә кемнәрдер эш эшләгән икән, ике дә уйлап тормаган, фикерләрен хөкем дәрәҗәсенә күтәреп дөньяга чыгарган. Без, буш куык, фанфарон, төпсез көймә дип йөргән Айдар Хәлим милләтебезнең чын улы булып дөнья алдына чыгып басты. Хәзер аны тотып ашарга йөрүчеләр шактыйдыр, әмма башкорт булып кыланып, маймылланып йөрүче уфалылар да, сәнәктән көрәк булырга да өлгермәгән кара эчле экстремистлар да бу мәкалә чыккач уйлангандыр. Ә без, Туфан чордашым белән икәү, эшем иясе булып, акыл сатып, редколлегия утырышында кызып-кызып речьләр сөйләгән булдык. Янәсе, Айдар Хәлим ике милләт арасында буталып йөрүче бушбугаз ул, моңарчы эш күрсәткәне юк. Хәер, моңарчы кылган кайбер гамәлләре миңа икеләнергә урын да калдыргандыр. Берчак Уфада чакта гостиницага Рифкат Исрафилов килеп керде, тагын берничә кеше, башкортның борынгы көйләрен җырлаучы кызыкайны да иярткәннәр. Шунда Айдар Хәлим дә килеп керде. Исрафиловка барыбыз да тәлинкә тотабыз инде, баш режиссёр, ул – хуҗа, капризлы һәм назлы хуҗа. Шунда, Айдарның Исрафиловка тез чүгүе артыкка китте, дип, ачуым ташып утырган идем. Дөрестер, хактыр! Кешене бер ягыннан гына карарга һич тә ярамый, бөтенләй өметсез дип саналган дәвердә дә аның әллә нинди батырлыклар эшләп ташлавы бар! Мәкаләсе белән Айдар Хәлим үзенең чын йөзен күрсәтте, без, бушбугазларга, акыл бирде, гаҗәпләндерде. Җөмләдән, аның ул мәкаләсе «Казан утлары»нда басыламы? Әллә без, салам торханнар, каршы төште, дип, аны исемлектән сызып ташладыгызмы? Минем өйдән киткәнгә шактый вакыт, журналның соңгы саннарын күргән юк, әгәр шулай икән, безнең хатаны да, журналның ялгышын да тиз үк төзәтергә кирәк: ул мәкалә басылган журнал тиражын арттырырга мөмкин булмасмы? Аны журнал активистларына, бүтән шәһәрләргә, Башкортстан авылларына юлларга кирәк, башкорт диктаторларының аяк астына кереп миңгерәүләнә язган кардәшләребезгә сабак, хәлләрен җиңеләйтергә көч, кулларына корал булыр иде. Югыйсә алар әле һаман да элеккечә яшәп ята икән, татар мәктәпләренең маңгаенда «башкортныкы» дигән язулар жандарм картузларындагы кокардалар булып ялтырый… Әле дә булса «Казан утлары»на язылуны кысалар икән. Ишетүемчә, Айдар Хәлимгә дә төрле

яктан янаулар, куркытулар ява икән!.. Куркып, берүк, Уфаны ташлап китә күрмәсен, бу качу йомшаклык булыр иде, әгәр син аның белән аралашасың икән, минем фикерләремне аңа җиткер. Без көчсезләнә бара торган вакыт түгел, без көчәя барган чор, көчәергә йөз тоткан дәвер. Әгәр соңга калмаган булсак, беләкләрдә көч саклансa, татар халкы ил алдында ялтырап күренеп китәчәк әле. «Кара көчләр изеп торганга гына» ул шул мескен хәленә төште. Үзебездә дә гаеп: озак йокладык, озак! Чамадан тыш озак... Моның сәбәпләренә кереп тормыйм, аның сәбәпләрен барыбыз да беләбез, мәгәр безне акларга ярамый! Әкиятләрдәге «буе бер карыш, сакалы биш карыш кәрлә», муенга бер менеп атланса, төшәр димә! Мин элегрәк: «Нигә аның сакалы биш карыш икән?» – дип уйлана идем...

Тормыш безне якынайтмады, уртак сукмакларга төшкән көнебез булмады, монысы да хата булган. Ничектер, сиңа шик-шөбһә беләнрәк, ышанмыйчарак каралган. Монысы өчен дә үпкәләмә, ярыймы?! Мин һаман шул инде, иске калып, «Балта кем кулында?» дигән повесть язып утырам. Байтак еллар элек уйланылган нәмәрсә иде, язылыр көне килеп җитмичә, туа алмыйча торды-торды да, хәзер әнә иртәнге алтыдан кичкә кадәр мине «тулгак тота», бүлмәм, йөргән таш сукмакларым, диңгез ягасы мине өерелеп алып кереп киткән гап-гади вакыйгалар белән тыгызланып тулган. Мин, әнә шул гади вакыйгалардагы бөек мәгънәне ачыкларга тырышып, үткәннәремне ияртеп йөрим. Кайсы көнне машинкамның хәрефләренә ял юк, алар сикерә, бәрелешә-чәкешә, зарлана, кычкырып көлә. Ул – бу көннәрдә минем бердәнбер сердәшем, мин, күзләремнең нурын клавиатурага түгә-түгә, газапланып, дөньяны аңларга телим. Ни барып чыгар...

> «
> **Тормыш безне якынайтмады, уртак сукмакларга төшкән көнебез булмады, монысы да хата булган. Ничектер, сиңа шик-шөбһә беләнрәк, ышанмыйчарак каралган.**

Журналдагы иптәшләргә – Кояшка, Рашатка, бөекләрнең бөеге Кашфулычка һәм начальникларга да миннән сәлам җиткер. Теләмәсәң, бер сүз дә дәшмә. Хуш булып тор, Тәүфикъ, исәнлектә күрешергә язсын. Ихтирам белән, Аяз.

26 март, 1989 ел, Переделкино

Тәүфикъ дус, сәлам сиңа!

Шылтыраткансың – рәхмәт, онытмагансың – мең рәхмәт. Мин өченче көн Минск-Ислочьтан кайтып төшеп, көнне Мәскәүдә үткәрдем дә кичә иртән җаныма якын Переделкинога килеп урнаштым. Былтыр көз, 28 сентябрьдә, шушы бүлмәдә «Балта кем кулында?» дигән повесть язарга тотынган идем, кичә шуны дәвам итә дә башладым. Бара, языла! Аллаһы боерган булса, кайтыр шәпкә, апрель азагына повестьны тәмамлыйм дип ышанып яшим. Ышанычым шуңа – повестьны мин моннан 10-12 еллар элек уйлап куйган идем. Озак уйланылган әсәрләр, күңелдә тәгәрәп йөри-йөри, тиешле рәвешләрен ала һәм, бер тотынгач, тизрәк языла да. Димәк, син ул повестьны 1990 ел планына теркәп куй. Повесть бу юлы беркадәр зуррак, 10-12 табаклар чамасы булыр дип беләм. Мин озак еллар уртак әсәрләр авторы булып килдем дә, хәзер миңа бер-бер артлы үз әйберләремне халыкка җиткерергә кирәк. Бик кирәк! «Яра» басылды, рәхмәт, әсәр синең җылы кул аша үтте. Рашат дус та аңа

Тәүфыйкъ Әйди (уртада) «Казан утлары» редакциясендәге хезмәттәшләре белән

бик игътибарлы булды. Шәт, иншәАллаһ, бу юлы да мәгънәле әсәр туа кебек, өслүбе дә, рәвеше дә, фикере дә үзенчәлекле һәм шәп кенә булачак. «Яра»ны ничек кабул иттеләр икән, дип, Минскида ай буе дер калтырап көтеп тордым, шөкер, беренче хәбәрләр күңелле, Компрессор заводының директоры (хәләле белән бергәләп!), өйне эзләп табып, Нәкыя аша миңа хат җибәргән. «Татар телен генә түгел, татар җанын да аңлый алырлык адәмнәр бар икән әле, йа Ходам!» – дип, елый-елый укыдым. Аңлаганнар, әсәрнең милли булуын да, андагы кешеләрнең бары тик татар гына була ала икәнен дә бик шәп аңлаганнар! Милли повесть тудырырга омтылган идем мин һәм хат язучылар шуңа куанган да! Шәкерт җиләненнән борча чүпләүчеләр тагын табылырмы – белмим, мәгәр, «Яра» повесте ул – минем йөз аклыгым. Гайбәтчеләргә, алардан бигрәк, көнче күбәләкләргә җавабым. Халкым аны шулай кабул итә алса иде дип ялварам... «Балта кем кулында?» сталинщинага багышланган, шул хакта ук булмаса да, әсәрдә ул калдырган мирас турында сүз бара, 60-70 нче еллар чынбарлыгын ача торган кырыс вакыйгалар, халыкны изү ысуллары, җинаятьләрдән тәм һәм файда табучылар янында шул җинаятьләрне башкаручылар... Алар, төп җинаятьчеләр, балта сабын тотып та карамый, балта әнә шул кечкенә кешеләр кулында! Бу ике катлау, Тендряковча әйтсәк, «коммунизмда яшәде». (Әгәр җан һәм мал талап яшәүне коммунизм дип атасак!) Беләм, синең өстәлдә, Монблан тавы булып, кульязмалар ятадыр, аңлыйм, әмма минем повестьны киләсе елда укучыга җиткерергә иде!

*Хатларны басмага **Рөстәм Галиуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Офык читендәге йолдыз

Лирон Хәмидуллин

Оренбургның беренче гильдия сәүдәгәрләре бертуган Хөсәеновлар 1889 елда салдырган «Хөсәения» мәдрәсәсендә Заһид Гайфулла улы Шәркый-Йосыпов (1901-1960) 1908-1918 нче елларда укыган.

Офык киң. Анда, хыялга бирелеп, күзәтеп торырдай йолдызлар да бихисап күп. Баш түбәсендә үк якты нур сибеп торганнары да бар алар арасында. Күк читеннәнрәк кенә балкып куйгалаганнары да күренгәләп китә...

1917 елгы үзгәрешләрдән соң, элек изелгән, икенче дәрәҗәле халык дип йөртелгән милләтләр арасыннан да, баш өстендә калыккан әлеге йолдызлар кебек, күпчелекнең күңелен җәлеп итәрдәй гамәлләр кылган зур шәхесләр калкып чыга. Шушындый зур үзгәреш чорында яңа тормыш төзү хыялын тормышка ашырырга керешкән максатчан шәхесләр арасында татар халкы вәкилләре дә ишле генә була. Татар милли автономиясен төзүгә үз өлешләрен керткән яңа чор дәүләт эшлеклеләре, яшь комиссарлар Мулланур Вахитов, аның урынбасары Галимҗан Ибраһимов, тәүге хөкүмәт башлыкларыннан Борһан Мансуров, Сәхибгәрәй Сәидгалиев, Мирсәет Солтангалиев – 1917 елгы түнтәрелеш чорында калкып чыккан беренче милли йолдызларыбыз. Патша хакимияте чоры дәвам итсә, татар милләтенең узаман шәхесләренә җиң сызганып эшләрдәй андый мәйдан бирелмәс иде. Яңа чорга аяк атларга беренче юл күрсәтүчеләр булган шул милләттәшләребезгә һәм аларның көрәштәшләренә бүген дә рәхмәт әйтеп яшәргә тиешбез. Элекке заманда яшәүне дәвам итсәк, яу-сугышлар кырында хәрби осталыклары ачылган Ильяс Алкин, Хөсәен Мәүлүтев, Йосыф Ибраһимов, Якуб Чанышев, Муса Мортазин һәм башка бик күп хәрби җитәкчеләребез барлыгын да белми

калыр идек. Чөнки элекке вакытта аларны бригада, дивизия кебек зур-зур хәрби берәмлекләр белән җитәкчелек итәргә куймаслар иде. Шул үзгәреш елларының ялкынлы комиссарларыннан Шамил Усманов, Бәкер Белоусов һәм Кәрим Хәкимовлар хакында да шундый ук сүзләрне әйтергә була.

Әлеге беренче дулкында күтәрелгән шәхесләребез үрнәгендә, аларга сыенып вә таянып, әдәбият-мәдәният күгендә калыккан йолдызларыбыз исә безнең милләт вәкилләре арасында икеләтә-өчләтә күбрәктер, мөгаен. Шундый шәхесләр исемлегенә мин күпмедер дәрәҗәдә якташым дип таныган Заһид Гайфулла улы Шәркый-Йосыповны да (1901-1961) кертер идем. Ата-анасы Җаек суы буендагы Зобачи авылының татар атлы казаклары нәселеннән булган, үзе Оренбург каласында үскән бу егет яшьли җәмәгать эшләрендә актив катнаша. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганда ук, ундүрт-унбиш яшеннән, бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсендә төрле вазыйфалар үти. Баштарак, мәдрәсәдә укуыннан аерылмыйча, Муса Җәлилнең абыйсы Ибраһим Җәлилов белән бергә шул ук басмаханәдә хәреф җыючы һөнәрен үзләштерә. 1916-1917 нче елларда Заһид, уналты-унҗиде яшендә, шунда ук мөхәррир-корректор ярдәмчесе булып эшли башлый. Күренекле әдип, мөхәррир-корректор Шәриф Камал аның остазы була. Киләчәктә, 1917 елгы үзгәрешләрдән соң да алар, остаз белән шәкерт, бергә-бергә берничә газетаны бергәләп нәшер итәчәкләр. Әйтик, 1919 елның гыйнварыннан Оренбургта чыга башлаган «Эшчеләр дөньясы»ның баш мөхәррире Шәриф Камал, аның урынбасары Заһид Шәркый-Йосыпов була, дип хәбәр ителә шул төбәккә бәйле язмаларда.

Мәдрәсәдә Заһид белән бер үк елларда булачак күренекле шәхесләрдән Кәрим Хәкимов, Шамил Усманов, Төхфәт Ченәкәй, яшьрәк буын вәкилләреннән Муса Җәлил, Сәгыйть Агиш укыганнар. Заһидның түбәнрәк сыйныфта укучы Муса белән үзара аралаша башлавына курсташы Ибраһим Җәлилов сәбәпче, әлбәттә. Ә соңрак Заһид белән Мусаның дустанә мөнәсәбәтләре ага-брат мөнәсәбәтләре рәвешен алачак.

«

Мәдрәсәдә Заһид белән бер үк елларда булачак күренекле шәхесләрдән Кәрим Хәкимов, Шамил Усманов, Төхфәт Ченәкәй, яшьрәк буын вәкилләреннән Муса Җәлил, Сәгыйть Агиш укыганнар. Заһидның түбәнрәк сыйныфта укучы Муса белән үзара аралаша башлавына курсташы Ибраһим Җәлилов сәбәпче, әлбәттә. Ә соңрак Заһид белән Мусаның дустанә мөнәсәбәтләре ага-брат мөнәсәбәтләре рәвешен алачак.

Оренбургта Совет хакимияте беренче мәртәбә 1918 елның гыйнвар урталарында урнашкач та, Заһид Йосыпов коммунист чордашлары тарафыннан «Мөхбир» газетасының мөхәррире итеп билгеләнәчәк. Әмма бу газета бик кыска гомерле була. Шул ук елның җәендә кызыллар казакъ илендәге Актүбә шәһәренә таба чигенергә мәҗбүр ителәләр. Бу вакыйга «Хөсәения» мәдрәсәсендә бер чорда укыган Шамил Усмановның «Легион юлы» әсәрендә бик җентекләп тасвирланган. Әлеге легион гаскәриләре шәһәрне калдырып китәр алдыннан гына «Заһидның, үз

газетасын тотып», аларга килеп кушылуы да тасвирланган ул әсәрдә. 1919 елның 22 гыйнварында кызыл гаскәр Оренбургны кабат яулап ала. Шул ук «Легион юлы» әсәрендә хәбәр ителүенчә, Заһид дутовчылар белән сугыш барышында яралана, «контузия ала». Әмма яңа тормыш кору өчен барган җитди көрәш вакытында лазаретта озак ята алмый ул. Заһид Йосыпов шул айларда ук «Юксыллар хакыйкате» (берникадәр вакыттан соң «Юксыллар сүзе») газетасын башлап нәшер итүдә актив катнаша. Берара ул газетаның баш мөхәррире булып та торачак. «Хөсәения» мәдрәсәсендә Муса Җәлил белән бер чордарак укыган Башкортстан язучысы Сагит Агиш бер истәлек язмасында: *«Шул газетада Мусаның да бер шигыре басылып чыккан иде»,* – дип билгеләп үткән. Ләкин әле Муса Җәлил иҗатын барлаучылар ул газета бәйләмнәрен таба алмады, ахрысы. 1920 елдан, баш мөхәррир Афзал Таһиров чорында, шул ук газетаның җаваплы сәркатибе вазыйфасын Һади Такташның үтәгәнлеге дә мәгълүм. Ләкин әле аның да бер ел дәвамында шул газетада нинәрсәләр бастырганлыгы әдәбиятчыларыбызга билгеле түгел. Чөнки Оренбург архивларында бу газетаның берничә саны гына сакланган. 1970 елда шул архивка, татар матбугатын тәртипкә китерү өчен, Казан университетын тәмамлаган белгеч тә җибәрелә. 1971 елда әдип Мәҗит Рафиков белән шунда булганда, без ул Мая ханымның бик тырышып эшли башлаганын күргән идек. «Менә бер бүлмәгә, өсте-өстенә өеп куелган газета өемнәрен актарып, тәртипкә сала башладык», – дип әйткән иде ул. Шунда ук аңа ярдәмләшеп йөрүче элекке журналистлар Фатих Кыргызбаев һәм Сабит Якупов агалар белән дә таныштык.

Заһид Шәркый-Йосыповның даими рәвештә нәшер ителмәгән кайбер газеталарны чыгарышуда катнашуын да билгеләп үтик. 1918 елның гыйнвар ахырында Оренбург Совет хакимияте вәкилләре кулына күчә. Кәрим Хәкимов тиздән губернаның азчылык милләтләр белән эшләү бүлеге җитәкчеләренең берсе итеп билгеләнә. Заһид та алар төркеменә тартыла. Аның төп бурычы – яңа матбугатны, мәдәният учакларын оештыруда катнашу була. 1917 елның көзендә Борһан Шәрәф мөхәррирлегендә чыга башлаган «Оренбург мөхбире» газетасын да, юнәлешен һәм исемен бераз үзгәртеп редакцияләүне аңа йөклиләр.

1919 елның мартында Башкорт Совет автономиясе идарәсе дә Оренбургта оештырыла. (Бу вакытта Зәки Вәлиди оештырган, Мәскәү түрәләре кабул итмәгән автономия хөкүмәте хәзерге Баймак шәһәре тирәләрендә урнаша.) Яңа автономия идарәсенең башлыгы яшь коммунист, «Хөсәения» мәдрәсәсенең элекке хәлфәсе Габдулла Дәүләтшин була. Ул ярым мөстәкыйль автономияне оештыру эшенә мәдрәсә шәкертләрен дә җәлеп итә. Автономия җитәкчелеге ярым башкорт һәм ярым татар телендә чыгучы «Башкортстан хәбәрләре» газетасын нәшер итәргә ниятләгәч, әлеге эшне башкару да Заһид Гайфулла улына йөкләнә. Һәм бу газетаны ул автономия идарәсе шул елның көзендә яңа башкалага – Эстәрлетамак шәһәренә күчеп киткәнче баш мөхәррир буларак нәшер итәчәк...

***

1920 елның апрелендә исә Оренбург шәһәре Казакъстан Республикасының беренче башкаласы буларак билгеләнә. Патшалар чорында да монда казакъ иленең көнбатыш тарафлары белән идарә итү бүлекчәсе булган. Ә 1913 елдан шушы ук шәһәрдә демократик фикерле яшьләр тарафыннан оештырылган «Казакъ» газетасы да чыгып килгән. Аны нәшер итүче Әхмәт Байторсынов, Мәгъҗан Җомабаевлар белән Галимҗан Ибраһимовның аеруча дустанә мөнәсәбәттә торуын да әйтеп

үтү урынлы булыр. Әдипнең «Казакъ кызы» романы да Мәгъҗанның бер куплет шигъри эпиграммасы белән башланып китә. Заһид та бу газетага аны ташбасмада чыгару чорында ук катнашкан була. Әлеге газета да, бераз соңрак шул телдә нәшер ителәчәк яңа чор газета һәм журналлар да Рәмиевләрнең яңарак кына Совет хакимиятенә тапшырылган «Вакыт» типографиясендә басылалар. Заһид бу эшкә, типографиядә хәреф җыючы рәвешендә, «Казакъ» газетасын нәшер итү чорында ук катнаша. Аның һәм Муса Җәлилнең беркадәр казакъ телен чамалаулары шул «Казакъ» газетасының Оренбурда нәшер ителүенә дә бәйледер, мөгаен. Якташлары Заһидның яңа республика башкаласы монда оешкач та казакъ телендә нәшер ителүче газета-журналлар эшендә бик актив катнашканлыгын искә алалар.

1932-1934 нче елларда баш мөхәррир урынбасары Заһид Шәркый-Йосыпов якташы, әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Муса Җәлил белән бергә «Коммунист» газетасы редакциясендә эшли.

Казакъстан Республикасының беренче көннәрдән үк диярлек нәшер ителә башлаган газетасы «Енбекше казакъ» (хезмәтчән, эшчән казакъ) була. Ул газетаны чыгаруда Заһид-Шәркый Йосыповның ни рәвешле катнашуы әле минем тарафтан ачыкланмаган. Соңрак Заһид татар һәм казакъ милләтләренә багланышлы, ике телдә дә аңлаешлы «Юл» («Жол») белән «Сабан» газеталарының баш мөхәррире була. 1970 нче еллардагы бер очрашу вакытында сеңлесе Маһишәкәр апа сөйләгән истәлек тә хәтердә саклана. 1924 елгы җәйге каникул вакытында шул редакцияләрнең берсендә Муса Җәлил дә эшләп киткән. «Абыйның истәлек язмасында ул хәбәр булырга тиеш», – дигән иде сеңлесе. Ул байтак еллар Оренбург партия оешмаларында төрле вазыйфалар башкарган апа иде. Бик җаваплы эшләр башкарганлыктанмы, абыйсының язма истәлекләренең бер ишен генә саклый алганлыгын белдергән иде. Абыйсының Муса Җәлилгә кагылышлы истәлек язмасының да Уфа матбугатында кайчан нәшер ителгәнен искә төшерә алмадык.

1925 елның урталарыннан Оренбург РСФСРга кергән бер өлкә башкаласы булып кына кала. Казакъстан хөкүмәте Кызыл Урда шәһәренә күчерелә. Әлеге хөкүмәтне алып киткән поездга тагылган бер вагонда 1906-1925 нче елларда Оренбургта татарча, башкортча һәм казакъча нәшер ителгән дистәләп исемдәге газета-журналлар да озатыла. Шул сәбәпле, Оренбургта ул гасырның беренче чирегендә нәшер ителгән татар матбугатының тулы исемлеге дә сакланмаган.

Заһид Шәркый-Йосыпов Оренбургта яшәгән егерменче елларда дүрт пьеса да иҗат итә. Һәм аларның дүртесе дә Оренбург татар театры тарафыннан сәхнәләштерелә. Аеруча аның 1926 елның декабрендә куела башлаган «Алмаз кылыч» пьесасы уңышлы бара. Шул ук елларда әлеге театрда Хәбибулла Ибраһимовның (әлеге чордагы Ибрай Хәйбүшнең) «Мөкатдәс сарай», «Зөбәрҗәт», «Башмагым» кебек әсәрләре дә куела. Алар Заһид Гайфуллла улы әсәрләренә кара-

ганда отышлырак булгандырмы – 1950-1960 нчы елларда шәһәр музеена куелган афишалары ишлерәк иде кебек хәтердә калган.

Бу елларда Заһид Йосыпов «История революционного движения Оренбурга» (1927) дип исемләнгән гыйльми хезмәт тә туплап чыгара. Һәм шул ук елдан монда аның мөхәррирлегендә өлкә партия комитеты карамагындагы «Очкын» газетасы да чыга башлаячак. Кайчандыр әлеге газетаны кулларында тоткан, соңрак монда нәшер ителүче татарча «Коммунист» газетасында эшләгән Фатих Кыргызбаев (шагыйрь Төхфәт Ченәкәйнең авылдашы) һәм Сабит Якупов агалар белән дә 1971 елда очрашкан идек, дидем. Алар Заһид агаларының журналист һәм кеше буларак бик тә инсафлы җан иясе икәнлеген искә алдылар. Дәрдемәнд, Фатих Кәрими, Шәриф Камал һәм алар даирәсенә кергән шәхесләр йогынтысында тәрбияләнгәнлеге сизелә иде, диделәр.

Оренбург өлкәсе ул чорда Урта Идел буе округына кергән була. 1928 ел ахырында округ күләмендә танылган журналист Заһид Шәркый-Йосыповны Самарага чакырып алалар. Һәм ул монда 1929-1930 нчы елларда округның рәсми милли газетасы саналган «Урта Идел»нең баш мөхәррире була. Шуннан соң аны Мәскәүгә, ВКП(б) Үзәк Комитеты карамагындагы Марксизм-ленинизм университетына укырга җибәрәчәкләр.

Маһишәкәр апа абыйсының Мәскәүдә Муса Җәлил белән кабат аралашуын искә ала иде. Ләкин тәүге елларда ул аралашуның ни рәвешлерәк булганлыгын әйтә алмады. «Абый укыган елларда мин Мәскәүдә була алмадым», – диде. Ике еллык курсларда укуын тәмамлагач та, Заһид Йосыповны Донбасска, татар телендә чыгучы «Пролетар» газетасына баш мөхәррир итеп җибәрәләр. «Ул чорда Донбасс шахтерларының дүрттән бер өлеше чамасы безнең татар кешесе булгандыр», – дип сөйләгән иде бервакыт Нәби ага Дәүли. Хәсән Сарьян «Азат хатын» журналында эшләгән чакта аның бүлмәсендә Нәби аганың Донбасста үткәргән елларын бик кызыксынып тыңлаган идек. Ул анда корыч кою заводының көн-төн дөрләп янып торган мичләренә вагонетка белән ташкүмер ташучы да, ут чәчеп януын дәвам иткән күмер шлакларын шул вагонеткаларга төяп цехтан чыгарып торучы да булган икән. «Күрәмсез минем биттәге вак-вак кара тапларны? Шул дөрләп янган шлактан очкан күмер бөртекләре таплары инде алар… Детдомнан соң килеп эләктем мин ул эшкә. Үз теләгем белән түгел…» – дигән иде Нәби ага.

Дөрес, ул кичтә безнең әңгәмә Һади Такташтан, аның Донбасска, шахтерлар белән очрашырга дип махсус килгәнлегеннән башланып киткән иде. «Минем бик мавыгып шигырь иҗат итә башлавым да шул вакыйгага бәйле, – дип сүз башлаган иде Нәби ага. – Нәкъ шул чакта безнең телдә «Пролетар» дигән газета да чыкты. Мин ул газетага мәкаләләр дә, шигырьләр дә җибәреп тора идем. Бераздан мине редактор үзенә эшкә алды. Заһид атлы, катлаулырак фамилияле бер кеше иде.

– Заһид Шәркый-Йосыпов түгел идеме? Шундый фамилияле бер якташым да ул газетада эшләгән, – дип сорадым.

– Әйе-әйе, шул иде, – дип раслады Нәби ага. – Мин аңа мең мәртәбә рәхмәтлемен. Шул Заһид иптәш мине дөрес юлга кертеп җибәрде, кеше итте. Ә гомер буе шул заводта эшләсәм, нәрсә булып бетәр идеме? Тамак тук, өс бөтен булса да, чын шагыйрь булып китә алыр идемме? Мәңге рәхмәтлемен мин синең якташыңа. Ул мине газетага эшкә алды. Шунда мин беренче тәҗрибәмне тупладым. Детдомнан соң үземне кеше итеп тою чоры шул газетта эшли башлагач булгандыр…»

Заһид Гайфулла улы Йосыповның чордашларыннан аерылып яшәве озакка бармый. 1932 елның ахырында аны якын дус-ишләре Мәскәүгә чакырып кайтаралар.

һәм ул СССР Үзәк Башкарма Комитетының Милләтләр Советы карары белән татар телендә чыга башлаган «Коммунист» газетасының баш мөхәррир урынбасары итеп билгеләнә. Ул елларда Заһид Йосыповның ни-нәрсәләр язганлыгы, «Коммунист» газетасы сәхифәләрендә ни-нәрсәләре чыкканлыгы барланмаган. Сеңлесе Маһишәкәр әйтүенчә, аның Оренбургтан киткәннән соң дөньяга чыгарылган хезмәтләре Мәскәү өлкәсенең Домодедово шәһәрендә яшәүче кызында сакланырга мөмкин. Миңа ул абыйсы кызының адресын да биргән иде. Домодедовода яшәүче әлеге ханым исә бераз үпкә хисен сиздергәнрәк җавап кайтарды. «Муса Җәлилне «Коммунист» газетасына эшкә алучы әти булган. Нигә аны бер дә искә алмыйлар?» – дигәнрәк сүзләр дә бар иде ул русча язылган җавап хатында.

Әйе, 1932 елның декабрендә Муса Җәлил җитәкчелегендә нәшер ителгән «Октябрь баласы» журналы чыгудан туктый. (Бу журналда Нәби ага Дәүлинең дә берничә шигыре басылып чыккан.) Һәм киләсе ел башында Муса Җәлилне әлеге «Коммунист» газетасына эшкә алалар – әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире итеп куялар. Бу якташлар әлеге газета ябылганчы – 1934 елның ахырынача бергә эшләячәкләр. Заһид Шәркый-Йосыповның якын якташына багышланган истәлек язмалары бездә басылмаганлыктан, аларның үзара аралашу мизгелләре дә бүгенге укучыга мәгълүм түгел.

Газета редакцияләрендә эшләү белән бер үк вакытта, 1934-1937 нче елларда Заһид Гайфулла улы Кызыл профессорлар институты дип аталган уку йортында белем үзләштерүен дә дәвам иткән. Ә «Коммунист» газетасы ябылгач, аны СССР Язучылар берлеге тарафыннан нәшер ителгән «Литературная газета»га эшкә билгелиләр. 1935 ел башыннан алып 1941 елның сентябрь ахырынача (газета берара ябылып торганчы) ул Милләтара бәйләнешләр бүлегендә эшли. Берара шул бүлекнең мөдире вазыйфасын да башкара. Заһид Йосыпов союздаш һәм автоном республика оешмалары белән эшли, элемтә тота, шул төбәкләрдә оештырылган чараларда катнаша.

Мәскәүгә командировкаларга йөрелгән чакларда мин бер мәртәбә әлеге газета редакциясенә кереп, сугыш алды елларында чыккан берәр бәйләм газетагызны карап чыгарга рөхсәт итмәссезме, дип тә сораган идем. «Капылт кына белдерелгән үтенечегезне үтәп булмас, алдан заказ бирәсе булыр», – диделәр. Әлбәттә инде, кабат анда барылмады.

Заһид Шәркый-Йосыповның соңгы ике газетада әдәби-мәдәни темаларга атап язылган күләмле мәкалә һәм очерклары әле беркем тарафыннан да тупланмаган һәм тикшерелмәгән. Домодедово шәһәрендә яшәүче кызы да: «Аннары сугыш башланды бит. Урыннан-урынга да күченгәләдек. Газета язмалары түгел, Оренбург театрында куелган пьесалары да сакланмаган», – дип язган иде.

«Литературная газета» сугыш башлангач чыгудан туктый. Партиянең Үзәк Комитеты Заһид Шәркый-Йосыповны Башкортстан Республикасының Кыйгы районы партия райкомына эшкә билгели. Кыйгы бик бай да, зур да район түгел инде. 1944 ел урталарынача ул анда райкомның пропаганда бүлеге башлыгы вазыйфасын башкарачак. Сугышка бәйле авырлыклар бераз кими төшкәч һәм якынаеп килүче картлык авырулары көчәйгәч, шул ук елда аңа Уфага күчәргә рөхсәт бирелә. Һәм 1944-1956 нчы елларда, йөрәк авыруы тәмам аяктан екканчы, Заһид Шәркый-Йосыпов Башкортстанның Тарих, тел һәм әдәбият институтында фәнни хезмәткәр вазыйфасын башкарачак. 1955 елда Уфада нәшер ителгән «Башкорт әдәбияты тарихы» җыентыгында аның фәнни-тарихи хезмәтләре дә саллы гына була. Һәм шул ук 1955 елда безнең олуг якташыбыз филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә дә ирешәчәк. Шундый дәрәҗәгә ирешү дипломы аңа шул вакытта тапшырыла.

Майшәкәр апаның (сөйләм телендә ул шулай йөртелә иде) хәбәр итүенчә, Заһид ага Уфага килгән чорда анда Оренбургтан күчеп тупланган танышлары да ишле генә була әле. Алар бигрәк тә драматург һәм композитор Хәбибулла Ибраһимов белән якын мөнәсәбәттә торалар.

Элегрәк елларда минем архивта Заһид Шәркый-Йосыпов белән Муса Җәлил Оренбургта күмәк төркемдә бергә төшкән берничә фото да бар иде. Аларның берсен мин 1990 нчы елларда нәшер ителгән «Татарстан хәбәрләре» газетасында бастырып та чыгардым. Хәзер алар үземдә сакланмаган икән.

Заһид Шәркый-Йосыпов 1960 елда, алтмыш яше туларга берничә ай калгач, арабыздан мәңгелеккә китеп барды. Ул Уфа шәһәре зиратында җирләнде.

Җаек-Урал суын эчеп үскән, татар мәдәният дөньясында сизелерлек эз калдырган шәхесләрдән Кәбир Бәкер (Кәбир Кәрим улы Бакиров), аның авылдашы Заһид Гайфулла улы Шәркый-Йосыпов, патшалар чорында үк Петербург университетын тәмамлаган Шакир Зариф улы Мөхәммәдъяров, шигърият өлкәсендә Мусаның остазы дип танылган Төхфәт Ченәкәй-Самави мираслары әле һаман татар дөньясыннан читтә кала сыман. Берничә ел элек мин фәнни институтыбыз архивына Шакир Мөхәммәдъяровның ГУЛаг лагереннан чыккач язган унбиш хатын тапшырган идем. Шул хатларның берсендә Хәсән Туфанның ул елларда язган шигыренә карата хат авторының фикере дә теркәлгән иде.

Милләтебезнең ирекле яңа тормыш коруга кергән чорында шактый зур эшләр башкарган, туган телебездә яңадан-яңа газета-журналлар чыгуны оештырган, милли телдә укытучы югары уку йортларын булдыруга үз өлешләрен керткән бөек шәхесләребезне онытмасак иде. Әлеге хезмәтләре белән алар туган телебезне саклауга һәм таратуга да зур өлеш кerткәннәр. Шулар өчен генә булса да, без аларны искә алырга тиешбез.

Редакциядән: *Мөхтәрәм авторыбыз, язучы һәм әдәбият галиме, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллинның октябрь аенда гомер бәйрәме – 90 яшь тула.*
Ә инде җәмәгате Дания ханым белән гаилә коруларына – 55 ел. Аларны ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, тигезлек белән хәерле озын гомер теләп калабыз! ■

ХӘТЕР САНДЫГЫ

Хаҗ сәфәре

Ләбиб Лерон

Ният иттем изге юлга чыкмакка...

«Без йортны (Кәгъбәне), кешеләр бергә җыелсын дип,
иминлек урыны иттек».
(«Бәкарә» сүрәсе, 125 нче аять.)

Кәгъбәтулла

Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим.

«Киләчәктә булачак һәрнәрсә якын». (Хәдис.)

Соңгы вакытларда бүгенгә хәл-халәтемне сурәтләгән, якын киләчәгемне фаразлаган шигъри юллар күңелемдә үзләреннән-үзләре (Аллаһының хикмәте белән!) бөреләнә, аерым шигырьләргә әверелә башлады.

Әле кайчан гына (2018 елның 7 гыйнварында) «Тукайча яшим, дип...» шигырен язган идем:

Татарча һәр иртәм –
Хөр итәм үземчә:
Бисмилла, оныклар,
Күрәгә, йөзем, чәй.

Дөньяны пакьлим, дип,
Үземчә тырышам.
Аллага шөкер, дим,
Канәгать тормыштан...

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы (2022) санында.

Узган елның ахырында (2021 елның 6-12 декабрендә) Яшел Үзән шәһәрендә урнашкан «Волга» шифаханәсендә дәваланырга туры килде. Мондый «ял» тәтегәнгә, җай-форсат чыгуга сөенеп, мин фәкыйрегез бер атна эчендә бер көлтә шигырь язарга өметләнгән иде, юк, гөнаһ шомлыгына күрәдерме, нибары өчне, аларын да өйгә кайтыр алдыннан гына яза алды. Шул өчнең берсе – 11 декабрьдә язылганы – «Илаһи көн» дип атала:

Әйтерсең лә, төнлә нидер булып,
Бөтен нәрсә кинәт үзгәргән:
Кояш кебек балкый һәрбер кеше –
Нур сибелә һәммә күзләрдән!

Шатлык белән тулган бөтен дөнья –
Кайгы-хәсрәт, гүя, юк сыман.
Шәфәкъ дөрли күңел офыгында –
Йөрәгемдә янган ут сыман!

Сөттәй ап-ак болыт ага ургып –
Әйтерсең лә, томан ертылган...
Төш вакыты. Серле, илаһи моң –
Кайтып барам иман йортыннан.

Йөзеп барам галәм диңгезендә –
Маяк булып яна ярымай...
...Күз тимәсен берүк – ай күк балкып,
Каршы алган сөйгән ярыма...

2022 елның 27 мартында көндәлегемә болай дип язып куйганмын:

«Төш күрдем. Төшемдә бер савыттан ап-ак каймак ашый башладым. Кемдер (хатын-кыз булды шикелле) туктатты: «Миңа да (безгә дә) калдыр!» – диде бугай. Яртысыннан азрагы калган иде, шуны, икенче кечкенә савытка бушатып, матурлап куйдым (ашагыз, янәсе)...

Күптән ниятләп йөри идем, ниһаять, бүген кич Рабит абый Батулла (кичә аның туган көне иде – котладым) тәрҗемәсендәге һәм шәрехләвендәге «Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре һәм аңлатмалары»н укый башладым. «Фатиха» сүрәсен кычкырып укыйм, чөнки хатыным Фидания тыңлый...

«Нәүәйтүән акраәл курәнә вә әтәшшәррафә бишәрафәтил курәни лирдааиррахмәни вә тәрдишшәйтани. Аллаһүммә йәссирһүли вә тәкаббәлһү минни». (Мәгънәсе: «Ният кылдым Коръән укымакка, аны укып хөрмәтләнмәккә. Ниятем Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү һәм шайтаннан ерак булмак өчен. Йә Раббым, бу эшне миңа Син җиңел кыл һәм Коръән укуымны кабул ит».)

Безнең өйдә Коръән тәфсире бернечә. Батулланыкыннан соң аларны да укып чыгарга ниятләп торам, Аллаһы теләсә...»

Көндәлектән:

«13 апрель, 2022 ел.

«Безнең мирас» журналы редакциясе «Татмедиа» ашханәсендә ифтар уздырды. Безнең басмаханәнең өченче ифтар уздыруы бу. Туксанлап кешене чакырдык: дин

әһелләре (Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Нияз хәзрәт Сабиров), матбугат ветераннары, галимнәр, өлкән әдипләр һәм яшь каләм әһелләре...

Ифтар мәҗлесе әйбәт узды кебек. Сөйли алмый калучыларның үпкәләве ихтимал, дип, беркемгә дә сүз бирмәдек. Җәлил хәзрәт вәгазь укыды. Соңгы ун-унбиш ел эчендә вафат булган алтмышлап күренекле шәхесебез рухына дога кылдык...»

«17 апрель, 2022 ел.

Төнге унбердә «Йосыф» сүрәсен укыдым... Эчтәлегеннән алдан (Кол Галиның «Кыйссаи Йосыф» китабыннан укып) хәбәрдар булгангадырмы, башкаларына караганда ошбу сүрә җиңел аңлашылды...»

«18 апрель, 2022 ел.

Ал мәчеттә. Ифтарда. Ильяс хәзрәт чакыруы буенча килдем. Иренмичә санадым: ифтарга килүчеләр утыз сигез кеше иде. Дөрес, араларында мәдрәсә шәкертләре дә, укытучылар да бар иде. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстанның элекке баш агрономы Харис хаҗи Камалиев, Спас районының элекке башлыгы, ТР депутаты Камил Нугаев, «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, Әмәт бистәсе мәчетенең имам-хатыйбы Равил хәзрәт Бикбаев, Ульяновск шәһәренең 1 нче мәхалләсе рәисе Рафаэль хәзрәт Нәҗметдинов, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит хаҗи Мифтахов, драматург Данил Салихов, мәдрәсә мөгаллиме, Тәтеш районының Дәвеш авылы тумасы Зөлфәт хәзрәт Мингалиев, җырчы-мөнаҗәтче Ильяс Халиков, Ильяс хәзрәт Җиһаншин үзе...

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин

Мин яшел күлмәктән, сары галстуктан идем. Ильяс хәзрәт таныштырган вакытта: «Сары галстуклы Ләбиб абый», – дигән иде, мөфти хәзрәтләре: «Алтын галстуклы», – дип төзәтте. Көлештек...

Ифтар вакытында «Татмедиа» АҖ җитәкчесе Шамил Садыйков, әле мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга, әле миңа карап:

– Башкалабыз Казанда төзеләчәк яңа җамигъ мәчетен Ләбиб Лерон «Хан мәчете» дип атарга тәкъдим итә, – диде.

Мөфти:

– Олуг Мөхәммәд хан исемен мәчеткә бирсәк әйбәт инде, Казанның беренче ханы, – диде.

– Мәчеткә Олуг Мөхәммәд исеме бирелсә, ахырда халык, исемне кыскартып, барыбер «Хан мәчете» дип кенә йөртәчәк! – дидем мин, килешеп.

Ифтардан кайткач (сәгать уннарда), «Рәгыд (Күкрәү)» сүрәсен (43 нче аять) укыдым. Фидания тыңлап утырды. Соңыннан озак кына фикерләштек...»

«19 апрель, 2022 ел.

«Безнең мирас»ның май санын Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел тулуга нисбәтле итеп чыгармакчы булабыз. Әлеге уңайдан җитәкчебез Шамил Садыйковка кергән идем – мөфтиләрнең чыгышлары буенча. Шул вакытта аңа Айдар Сәлимгәрәев шылтыратты да үзенә чакырды. Мин дә иярдем. Сәлимгәрәев миңа ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаментының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгы Альберт Рифкать улы Дирзизовның телефонын биреп, аның янына барып киңәш-табыш итәргә кушты...

Кичен 14 нче сүрәне («Ибраһим») укыдым, Фидания тыңлап утырды. Аннан соң догалар укыдым...»

«20 апрель, 2022 ел.

Альберт Рифкать (Ривкать) улы Дирзизов белән күрешеп сөйләштем – сәгать бердә аның эш бүлмәсендә очраштык. Бер сәгать чамасы гәпләштек. Фикерләребез туры килә. Ул дүрт мөфтинең дә (К.Сәмигуллин, Т.Таҗетдин, Р.Гайнетдин, Ә.Крганов) чыгышын журналда бирергә кирәк, ди. Хутын да таптык кебек: башта ТРның Беренче Президенты Минтимир Шәрип улы Шәймиевнең мөрәҗәгатен, аннары бер-бер артлы мөфтиләр (Т.Таҗетдин, К.Сәмигуллин, Р.Гайнетдин, Ә.Крганов) чыгышларын куярга, шуннан соң тарихчы Ф.Хуҗинның әтрафлы язмасын һәм галим И.Миргалиевның саллы мәкаләсен урнаштырырга булдык...

Сүз иярә сүз чыгып, Альберт Рифкать улына хаҗ сәфәренә барасым килгәнен әйттем. Ниятең изге, хуплыйм, барырга насыйп булсын, диде...»

«25 апрель, 2022 ел.

Төш күрдем. «Иң дөрес төш – сәхәр вакытындагы төш». (Хәдис.)

Урындыкка утырган килеш кенә буш өстәлне артка таба шудыртканда, бер почмагын ялгыш җимереп төшердем. Кулым белән рәтләштергәндәй иттем, әмма ул почмак барыбер җимерек иде инде...

Нигә юрарга да белмәдем төшне. Башыма чыгышлары журналга керәсе дүрт мөфти исеме килде. Шуларның берсе белән проблема килеп чыгарга тора дип фаразладым (ахырдан ул шулай булып чыкты да: кайбер сәбәпләр аркасында, ни кызганыч, мөфти Ә.Крганов чыгышы журналга керми калды)...»

Рөхсәт итәрләрме, әллә әүвәлге ике елдагы кебек (2020 һәм 2021 нче елларда пандемия белән бәйле рәвештә Согуд Гарәбстаны Корольлеге хаҗ визалары бирмәгән иде), Рәсәй мөселманнары хаҗга барудан мәхрүм калырмы, минем гозеремә колак салучы булырмы, дип шөбһәләнеп йөргән көннәрнең берсендә – Балаларны халыкара яклау көнендә, ягъни 1 июньдә, ниһаять, сөенечле хәбәр килеп иреште – быел Россиядән (димәк, Татарстаннан да!) хаҗ кылырга бару мөмкин булачак икән!

Соңыннан белүемчә, бу Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның 2021 елда «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең күчмә утырышы кысаларында куйган тырышлыкларының нәтиҗәсе икән: мәйданчыкларның берсендә – Согуд Гарәбстанының хаҗ һәм гомрә эшләре буенча министр урынбасары Габделфәттах бән Сөләйман Машат белән очрашу вакытында – ТР Президенты Россия мөселманнары өчен быел гомрә һәм хаҗ кылу мөмкинлекләрен ачуны сорап мөрәҗәгать иткән булган һәм мәсьәлә уңай хәл ителгән. Шулай итеп, быел Россия мөселманнары өчен 11 318 кешелек квота (шулардан 810ы – Татарстаннан) бүлеп бирелгән. Димәк, хаҗ сәфәренә шулкадәр кеше бара алачак.

Күңелемдә өмет уты кабынды. Ул да булмады, берничә көннән шылтыратып, хаҗ сәфәре өчен кирәкле документларны әзерләргә куштылар…

Күпмедер вакыт үткәч, мин бахырыгыз хастаханәдә дәваланып яткан чакта, ягъни 15 июньдә Питрәч районы мөхтәсибәтенең җитәкчесе, имам-хатыйп Габбас хәзрәт Кадыйров ватсап аша элемтәгә керде. Ул безнең төркемнең җитәкчесе итеп тәгаенләнгән булып чыкты. Без, безнең төркем, 1 июль көнне Казан аэропортыннан Истанбулга очарга, 18ендә Казанга әйләнеп кайтырга тиешбез икән.

Питрәч районы мөхтәсибәтенең җитәкчесе, Татарстан Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты рәисе, имам-хатыйп Габбас хәзрәт Кадыйров

Сүз уңаеннан, Габбас хәзрәт хакында бер-ике кәлимә: Габбас хәзрәткә 33 яшь, ул чыгышы белән Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авылыннан. 2014 елда «Әл-Әзһәр» университетын (ислам хокукы белгечлеге), 2019 елда исә Россия транспорт университетын («Халыкара мөнәсәбәтләр» белгечлеге буенча бакалавриат) тәмамлаган. Татарстандагы дини эшчәнлеген Казанның «Тынычлык» мәчетендә (1998-1999 нчы елларда архитектор Г.А.Бакулин проекты буенча төзелгән) имам булып башлаган. 2018 елдан Татарстанның Питрәч мөхтәсибәтен җитәкли. Татар һәм урыс телләреннән тыш, гарәп, алман, инглиз телләрен дә белә. Ошбу елның 21 апреленнән Татарстан Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты рәисе итеп билгеләнде.

Габбас хәзрәт минем белән хәбәр алышкан көнне үк ватсапта «Хаҗ-2022» дигән төркем ачты: барлык яңалыклар белән шуннан таныша бардык.

Быелгы хаҗ сәфәренең үзенчәлекләрен Согуд Гарәбстаны Хаҗ һәм гомрә эшләре буенча министрлыгы билгеләгән – аның тарафыннан аерым таләпләр куелган: хаҗиларның яше 65 яшьтән югары булырга тиеш түгел; 10 еллык биометрик чит ил паспорты, аның 6 айга кадәр вакыты чыкмаска тиеш булу; коронавируска каршы «Спутник V» вакцинасы ясатылган булу, сәфәргә чыгу алдыннан ПЦР-тест тапшыру.

23 июль көнне Габбас хәзрәт ватсап аша бер китапның тышлык сурәтен җибәргән: «Татар телендә, бик яхшы китап!» – дигән һәм ул әсбап-җыентыкны Париж Коммунасы урамындагы «Хозур» кибетеннән сатып алырга мөмкин булуын әйткән. «Әттәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл Кудури (Кудури китабының җиңеләйтелгән фикһи мәсьәләләре)» дигән әлеге китапның авторы – Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрни.

«23 июнь, 2022 ел.

Төш вакытында Ильяс хәзрәт Җиһаншин янында булдык – «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин белән. Ильяс хәзрәт хаҗга баруга нисбәтле киңәшләрен бирде.

Бирде, дигәннән... Хәзрәт, хаҗда сиңа кирәк булачак, дип, билгә каеш кебек эләктереп куя торган ак билбау-сумка (акча һәм документлар йөртү өчен) белән ап-ак күлмәк-чалбар бирде, рәхмәт төшкере...»

«28 июнь, 2022 ел.

Париж Коммунасы урамына бардым. Алтынчы йорттагы «Хозур» кибетеннән Ризаэддин Фәхреддиннең «Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре» дигән китабын (Казан, 2018, хәзерге әдәби телгә күчерүче – А.И.Кадыйров), аннары Әхмәдһади Максудиның «Гыйбадәте исламия» (Казан, 2021) җыентыгын һәм, мәчеттә намаз вакытында киярга, дип, бик затлы кара чүәк сатып алдым.



Хаҗ сәфәренә барыр алдыннан Ләбиб Лерон сатып алган дини китаплар

Шул ук урамның икенче башындагы «Ихлас» кибетеннән 1000 сумлык гигиеник әсбаплар (юыну кирәк-яраклары), янә Габдерахман Галәветдиннең «Гарәфә догасы» (хаҗга баручыларга ярдәмлек, 2018, Яр Чаллы), Җәмалетдин Бикташиның «Фазаилеш-шөһүр яки саваплы гамәлләр» (Казан, 2021) һәм Әбү Ясин Руслан Мәликовның «Синең намазың» китапларын, аннары Галимә Харисованың «Кара тмин, зәйтүн, сенна, хельба, ладан, имбир, хна, мисвак, зәм-зәм суы, тәлбинә белән дәвалану» (Казан, 2018) һәм «Тәкъдиргә ышану һәм сәламәтлек» (Казан, 2013) җыентыкларын сатып алдым...»

«29 июнь, 2022 ел.

Эшкә барышлый, Чистай урамындагы 15 нче йортка (анда – медицина үзәге) кереп чыктым. Иртәгә иртәнге җидегә килергә куштылар – ПЦР-тест тапшырмакчы идем, хаҗга бару өчен кирәк».

«30 июнь, 2022 ел.

Җиде тулганда медицина үзәгендә идем инде. ПЦР-тест тапшырдым – бер татар кызы борыннан һәм авыздан мазок алды. Дүрттән соң әзер булыр, диде. 1150 сум түләдем...

Алдан сөйләшеп-килешеп, унбер тулганда Ал мәчеткә (мәдрәсәгә) киттем. Ильяс хәзрәтнең киңәшләрен тыңлап, аның фатихасын алдым.

Ильяс хәзрәт мәдрәсәсеннән дә бер иптәш (Азат исемле, күрешкәләп торабыз) хаҗга барачак икән. Аның белән сәфәрдәшләр булабыз икән, Аллаһы бирсә.

Кичә «Хозур» кибетеннән Ризаэддин Фәхреддиннең «Мәрҗаниның хаҗ сәфәре» турындагы китабын (Әхмәдһади Максуди китабын да) сатып алуымны әйткән идем, Ильяс хәзрәт миңа да шундыйрак рухта сәяхәтнамә язарга киңәш итте. Үзем дә шулайрак уйлап тора идем, дидем.

Безгә Равил хәзрәт Бикбаев (Әмәт бистәсе мәчетенең имам-хатыйбы) килеп кушылды. Ул унҗиде ел Мәккәдә яшәгән икән. Равил кардәшебез дә иртәгә минем белән бергә Истанбулга очачак икән.

Ильяс хәзрәт Равил хәзрәткә: «Мәккәдә син күзеңне йомып та йөри аласың, Ләбиб абыйны үзеңнән калдырма, үзең белән бергә алып йөр», – диде.

Шушындый китапны таба алмадым, дип, Ильяс хәзрәткә телефоннан Габбас хәзрәт ватсап аша җибәргән җыентыкны (Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрни, «Әт-тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури», Казан, 2019) күрсәткән идем, үзенең эш кабинетыннан шуны табып, миңа бүләк итте. Чынлап та, шәп китапка охшаган – тиз генә күз йөртеп чыктым да, хаҗга алып барасы булыр дип уйлап куйдым.

Кайтышлый медицина үзәгенә кереп, анализны алдым, үзебезнең яндагы даруханәдән хаҗ вакытында кирәге чыгуы ихтимал булган төрледән-төрле дарулар, бер кибеттән сарымсак, шешәле чиста су, кара ипи, өч лимон сатып алдым – болар барысы да юл букчасында урын алачак, Аллаһ бирсә.

Сумкаларны әзерләп куйдым. Ике махсус сумка (плюс янә бер кара рюкзак) алып барырмын дип уйлыйм. Берсен – багаж итеп.

Вакыт 22:06. Көндәлек язудан туктыйм. Аллаһ насыйп әйләсә, сәфәрдә чакта дәвам итәрмен дип торам.

Фидания мин кайтканчы минем исемнән теләкләр язып куйган иде. Аларны карап, төзәткәләп, кайбер нәрсәләр өстәп, компьютердан ике данә чыгардым – алтышар бит булды.

Документларны рәтләп куйдым. Хаҗ сәфәренең вакытына эштә чираттагы ялны алырга булдым.

Минем хаҗ сәфәренә җыенуым турында эш буенча хуҗаларым – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының житәкчесе Айдар Сәетгәрәй улы Сәлимгәрәев белән «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Мөхәммәт улы Садыйков та хәбәрдар иде. Алар миңа теләктәш һәм хәерхаһ булды, рәхмәт аларга!

Аллаһка шөкер, атна-ун көн чамасы элек Габбас хәзрәт янында булып, «Хаҗ догалары» дигән китап һәм ихрам киемнәре салынган махсус биштәр белән букчалар алып кайттык.

Иртәгә сәфәргә кузгалабыз. Хәерле сәфәр булсын берүк. Амин!» ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Әсгат Галимҗанов булып карагыз

Габделбәр Ризванов

Апас районының Болын-Балыкчы авылы –
хәйрияче Әсгат Галимҗановның туган төбәге

Әсгат Галимҗанов хатыны Роза белән. 1961 ел

Очрашкан-күрешкән саен Әсгат абый: «Байлык аяк астында ауный, җыештырып ала белергә генә кирәк», – дип әйтергә ярата иде. Дөресе дә шулай бит. Колхоз базары янәшәсендә яшәгән Әсгат Галимҗанов, базардагы ашамлык калдыкларын җыеп, дуңгыз симертүгә керешә. Дуңгызларын ишегалдындагы шактый иркен утын сараенда асрый. Тирә-күршедәгеләр тавыш, ис дип ризасызлык белдерә башлагач, шул ук сарайда тирән итеп чокыр казый да дуңгызларын шунда төшерә. Тиресен, сыекчасын, трамвай-троллейбуслар туктагач, халык инде тәмам йокыга талгач, шәһәр читендәге басуга илтеп аудара.

Азыгы бушка, дуңгызлары тиз симерә, аларны ит комбинатына тапшырып, акчасын караватастындагы ләгәнгә алып кайтып сала. Айдан-айга өсти торгач, савыт тиз тула. Хатыны Роза белән киңәшәләр дә акчаны Казандагы 1 нче балалар йорты хисабына (счетына) күчерәләр. Әлеге вакытта әле Әсгат абый үзләреннән ерак түгел генә бер кибеттә ат җигеп йөк ташучы булып эшли һәм төннәрен базарда каравыл да тора. Ул да түгел, базардагы ташландык, әмма әле кулланышка бик тә яраклы такта тартмаларны каккалый-суккалый да заводка илтеп тапшыра, шул рәвешле дә азмы-күпме акча эшли. Хәләл көч белән эшләп тапкан акчасын әлеге дә баягы ба-

лалар йортына күчерә бара. Әсгат Галимҗановның игелекле эшләре хакында «Ватаным Татарстан» газетасында (элеккеге «Социалистик Татарстан») беренче тапкыр 1982 елның 29 апрель санында язган идем. Аның редакция белән дуслыгы да менә шул елдан башланды. Ул, редакциягә килгәләп, күргән-белгәннәрен, ишеткәннәрен сөйләп тора, журналистлар аның хәлләреннән даими хәбәрдар иде. Әсгат абый бернәрсәгә дә битараф түгел, фаҗигаләрне күңеле аша үткәрә, хәленнән килгәнчә ярдәм кулын суза тора. «Хәленнән килгәнчә» диюебез хәзер инде бик зур суммаларга җыела. Казандагы, Башкортстандагы балалар йортларына, хастаханәләргә төрле зурлыктагы алтмышлап автобус кына бүләк итте ул. Әрмәнстандагы җир тетрәү, Грузиядәге су басу, Чернобыльдәге афәт тә аны битараф калдырмады. «Курск» су асты көймәсендә бәлагә юлыгып һәлак булган 118 мең диңгезченең гаиләләренә дә 10 ар мең сум хәләл акчасын күчерде, заманында Советлар Союзында сәяси сыену урыны тапкан Луис Корваланга да акчалата ярдәм итте. Әсгат абый туган төбәгендә – Апас районының Болын-Балыкчы авылында исә, иң беренче эше итеп, артезиан коесы казытты, үзенә дип кирпечтән салынган менә дигән йортында да инде балалар бакчасы, мәктәп балалары исә укырга ул бүләк иткән автобуста йөри иде.

Әсгат Галимҗановның әнисе Шәмсеруй апа

Милләтебезнең горурлыгы, мактанычы бу олуг шәхес. Шәймиевләр гаиләсенең Казанда, Кремль янындагы мәйданда Татарстанның «баш хәйриячесе»нә үз акчаларына һәйкәл куйдыруы да – шул горурлыкның бер чагылышы. Әмма, ни аяныч, һәйкәл торгызган көннәрдә Әсгат абыйның күңеле әллә ни тыныч булмады. Милләт,

Хәйриячегә һәйкәл

Хәйриячегә һәйкәл
ачу тантанасыннан бер мизгел

дип җан аткан кайберәүләр, дуңгыз симертеп тупланган акча хәрәм ул, изге урында – Кол Шәриф мәчете янында үзеңә һәйкәл куйдырудан баш тарт, юкса, пикет оештырабыз, ул урында сиңа түгел, ә Казанны яклап шәһит киткәннәргә һәйкәл торырга тиеш, дип теңкәсенә тиделәр.

Кайбер матбугат чараларында Әсгат Галимҗановны акылына килергә чакырган мәкаләләр дә басылды, үлгәч, аның кем икәнлеге ачыкланыр әле, дигән «кыю фикер»ләр дә әйтелде. Ул исә сәяси уеннардан элеккечә үк ерак торды (сәясәткә тартып-өстерәп кертергә, аның абруен үз мәнфәгатьләрендә файдаланырга теләүчеләр булса да), бары тик игелек кылуын гына белде.

Әсгат Галимҗанов

Болары да нәкъ үзе

Әсгат абый «Идел-Пресс»та журналистларның көтеп алган кунагы иде. Аны танымаган-белмәгән кеше юк. Кочаклап алалар, сорашалар, белешәләр, үзе дә сүзгә кеше кесәсенә керә торганнардан түгел, көлдерә, сокландыра.

«УАЗ»игын гел бер урынга куярга тырыша иде ул. Әмма... килгән саен бер сорауга ачыклык кертмичә булмый.

– Әсгат абый, машинагызны бикләдегезме соң? – дип сорыйм.

– Син нәстә? – дип гаҗәпләнә бу. – Ул бит минем машина, аңа беркем дә кагылырга тиеш түгел.

Машина бикләнмәгән, ачкычы да шунда ук була.

Менә шулай: читләрнең кеше әйберенә сораусыз кагылырга хакы юк. Бу аның яшәү рәвеше иде, шул хакыйкатькә гомере буе тугры калды.

***

Болын-Балыкчыда Әсгат абый күлне чистарттырган мәлләрдә Казан белән авыл арасын шактый урадык. Мин – рульдә. Әсгат абыйны Межлаук урамындагы барагына килеп алам. Беренче килүемдә җил-җил атлап чыкты да шундук машинага утырды. Кулында берни юк, туганнарына кайтабыз бит, күчтәнәчсез ярамас инде ул дип уйладым.

– Әсгат абый, күчтәнәч-фәлән алмадың, ахры?..

Әлеге дә баягы шул ук гаҗәпләнү:

– Син нәстә? – ди бу. – Аларның бөтен нәстәләре дә бар. Менә күрерсең, бирептә җибәрәчәкләр әле.

Апасны чыгып, Болын-Балыкчыга борылгач, кибет яныннан узганда бераз хәйләгә керешергә булдым:

– Әсгат абый, тәмәкем беткән икән, кибеткә кереп чыгыйм инде...

Үземнең тәмәкегә гомердә дә якын килгәнем юк, әмма барыбер кибет ишеген ачтым, кечкенә генә бер төргәк йөзем җимеше алдым да машинага утырдым.

Кайтуга ук чәй өстәле янына чакырдылар. Мин җимешне өстәлгә куйдым, Әсгат абый рәхәтләнеп елмайды, җимешле чәй күңелебезгә хуш килде. Кичкә таба юлга

кузгалыр алдыннан нәкъ Әсгат абый фаразлаганча булды, безгә, кучтәнәч итеп, берәр банка сөт өсте бирделәр.

«Аларның бөтен нәстәләре дә бар, дип әйтемме мин сиңа?!» – диде юлдашым.

Килештем, шулай да икенче тапкыр кайтуыбызда кибет яныннан узганда Әсгат абый: «Тәмәкең бетмәдеме?» – дип сорап куймасынмы?! Кибеткә икәүләп кердек һәм Әсгат абый кучтәнәч алды: «Аларның бөтен нәстәләре дә бардыр дип уйлаган идем, җимешләре юк икән бит».

Ул үзе ятимнәргә, дөресрәге, ятим балаларга булышлык күрсәтте: кучтәнәчен дә, машинасын да кызганмады. Әледән-әле: «Таза-сау кеше үзе эшләп табарга тиеш, акча аяк астында ул», – дип кабатлый иде.

***

Әсгат абыйны Мәскәүгә Бөтенроссия балалар фонды киңәшмәсенә мактаулы кунак итеп чакыралар. Ул вакытта Татарстанда балалар фондын шагыйрь Роберт Миңнуллин җитәкли, алар бергәләп башкалага юл тоталар. Әсгат абыйның иганәчелек-хәйриячелек өлкәсендә шактый ук танылган чагы бу. Бөтенроссия балалар фондының җитәкчесе Альберт Лиханов Татарстан кунагын бик җылы кабул итә, киңәшмәне дә элек Әсгат Галимҗанов белән таныштырудан башлый һәм шул араларда «Огонек» журналында басылган мәкаләдән өзекләр укый. Анда хәйриячененң эшчәнлеге сурәтләнгән була. Җыелган халык «аһ» итә, килеп кулын кысалар, мактау сүзләре әйтәләр. Альберт Лиханов тәкъдиме белән, Әсгат абый Бөтенроссия балалар фондына әгъза итеп алына.

Әсгат Галимҗанов Роберт Миңнуллин белән

Икенче килүләрендә Әсгат абый белән Робертны бер ханым: «Идите сюда, мои татары!» – дип, бөтен залга ишетелерлек итеп аваз салып, үз янына – түргә чакырып ала һәм урын тәкъдим итә.

Тәнәфестә Әсгат абый Роберттан: «Кем булды бу?» – дип кызыксына. «Раиса Максимовна ул, Горбачев хатыны. Минем якташ. Раиса Максимовна, дип тел сындырып әйтеп азапланма, Рәйсә Мәгъсүмовна, дисәң дә аңлар». Әсгат абыйга шул җитә кала: «Исәнмесез, Рәйсә ханым», – ди ул. «Да-а, это я», – дип җавап кайтара Раиса Максимовна.

Әсгат абыйның барагында М.С.Горбачевның зур портреты иң түрдә иде. Раиса Максимовна белән танышканнан соң Мәскәүдән алып кайткан портрет булып чыкты ул. Роберт бу хәлне җае чыккан саен хәтерендә яңартырга тырыша иде. Икесенең дә урыннары оҗмах түрендә булсын.

Редакциядән: *Хәйрияче Әсгат Галимҗановның тормышына, эшчәнлегенә, игелекле гамәлләренә мөнәсәбәтле «Изге җан»-«Лучший из нас» дип исемләнгән саллы хезмәт дөнья күрде. Мәкалә басмага әзерләнгәндә апаслылар шул китапны халыкка тәкъдим итү һәм Әсгат Галимҗанов музеен булдыру мәшәкатьләре белән мәшгуль иде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

«Исемең матур, кемнәр куйган?..»

Әхтәм Зарипов

Татарстанның халык артисты, Татарстанның Лаеш районы Яушыйк авылы тумасы Фирдәвес Әхтәмова (1939-2012)

Шушы исем белән (Фирдәвес Әхтәмовага 70 яшь тулганда) телевизион очерк эшләп күрсәтеп, рәхмәт көтеп йөргәндә, телефоннан шалтыратты да иң элек җиңелчә генә үпкәсен белдерде: «Тапшыруыңа исемне дөрес сайламагансың, исемем генә матур булганны мин үзем дә беләм...» – диде. Күпме генә аклансам да, тынычландыра алмадым, Фирдәвес үз фикерендә калды. Холкы шундый иде. Аның өчен рәхмәтне тамашачылар һәм артистканың хезмәттәшләре әйтте. «Дөрес бәяләдең», – диделәр. Бәяләүгә килгәндә, Фирдәвес кемнеңдер бәяләвенә мохтаҗ түгел, ул үзенең кем булуын, нинди сәләтләргә ия икәнен, нәрсә җитмәвен дә бик яхшы белеп, булганына канәгать булды, ә булмаганына зарланып, елап яшәмәде. Аның күңеле һәрчак көр, киләчәге өметкә төрелгән иде.

Елап, зарланып кына яшәрлек хәлдә булса да, Фирдәвеснең башкаларда яшәү рәхәтен тойдыру сәләте көчле иде.

...Әти-әнисе назыннан мәхрүм калгач, туганнары тәрбиясендә үскән ятимә кызда ихласлык та, вәгъдәдә торучанлык та, туганлыкның һәм дуслыкның кадерен белү дә башкаларга үрнәк булырлык мул иде...

...Минем 1925 елгы абыем 18 яшендә Ватан сугышында һәлак булгач, әткәй белән әнкәй өчен мин бик тә кадерле бала булып үстем, укыдым, яшәдем. Артистлыкка укыганда «повышенная стипендия», өстәвенә, әткәй-әнкәйдән ай саен стипендия суммасы кадәр акча килә иде (әткәйнең киез итек басу кәсебе табышыннан). Ләкин акча барыбер җитмәде. Ара-тирә Фирдәвестән әҗәткә алып тора идем. Ә бит Фирдәвес бер стипендия акчасына гына яшәде! (Туганнарыннан акчалата ярдәм көтү мөмкинлеге юк...) Мине акча тота белмәүдә гаепләп тиргәгәне хәтердә: «Син үзеңне-үзең дә карый алмыйсың, гаиләң булгач нишләрсең?!»

Фирдәвес хаклы булып чыкты: гомер буе акча җитмәүдән интегеп яшәдем. Бик кыен хәлләрдә калганда гел Фирдәвескә бара идем. (Фатиры бездән ерак түгел генә урнашкан иде.)

«Өч җирдән хак алып яшәгән Әхтәмнең пенсиядәге Әхтәмовага әҗәткә керүе көлке!» – дип булса да, үтенечемне кире какмады. Бу аның акчага туенып яшәвеннән түгел, ә кешелеклелегеннән, ярдәмчеллегеннән иде. (Монысы да холыктан!)

Узган гасырның 70 нче еллары башында булса кирәк, кибеткә алтын чылбыр кайткач, Фирдәвес шул чылбырны алырга театрдагы хезмәттәшләреннән әҗәткә акча җыйды. Кем күпме булдыра ала, – шуның кадәр бирүләре хәтердә. Китте Фирдәвес кибеткә һәм, күпмедер вакыт узуга, кайтты да: «Беткән... Миңа булса, гел шулай инде: йә җитми, йә кайтмый», – диде. Кемнән алса, шуларга акчаларын кире кайтарды.

Ф.Әхтәмова һәм Ш.Биктимеров «Ак чәчәкләр» (Г.Әпсәләмов әсәре буенча) спектаклендә. 1970 ел

Шулай дисә дә, Фирдәвес башкалардан ким яшәмәде: зәвык белән киенә дә, булганына канәгатьләнеп, сөенә дә белде. Аның өчен иҗатташының уңышы, нәрсәгәдер ирешүе дә зур сөенеч булды. Ул көнчел түгел иде. Яшерен-батырын түгел – артистлар арасында роль уйнап дәрәҗәләр алу – зур вакыйга. Кайчакта дәрәҗәләрнең лаексызга бирелү очраклары да булгалый. Сүз китә, гайбәт тарала. Ә Фирдәвес сүзгә, гайбәтләргә игътибарсыз: ул кеше шатлыклары өчен сөенә генә белә... Без аның үзе өчен дә сөенгән чакларын, сирәк булса да, күрдек. Намаз әһеле, иманлы шәхес иде ул.

...Аның өчен һәр премьера шәхси бәйрәм булды. Һәр уйнаган роле табыш-ачыш иде. Ул бер ролендә дә элек уйнаган ролен кабатламады. Тәвәккәл иде Фирдәвес. Чагыштыру җиңеллеге өчен генә аның ике фильмдагы Биби ролен мисалга китерү дә җитә. Г.Камалның «Беренче театр»ындагы Биби һәм «Бибинур»дагы Биби – икесе ике төрле холык, икесе ике дөнья. Аларны бер генә нәрсә берләштерә: артисткадагы ихласлык. Үзе ышану белән башкаларны да ышандырып, үзенә әсир итә ул. Фирдәвес һәр тапшырылган эшкә чын күңелдән бирелеп, ихласлык белән башкарды. Аның кылану, ясалмалык кебек «авыру»ларга иммунитеты табигатеннән үк килә иде.

Сценарийларын язып, үзем үк төшергән телефильмнардагы рольләрен санап тормыйм, Фирдәвес һәр ролен җиренә җиткереп, кирәкле сыйфатта башкаруы белән хәтердә саклана.

«Щепкинчылар» дип йөртелгән артистлар төркеменең, укып кайтып, театрда эшли башлауларына 50 ел тулуны бәйрәм итү кичәсендәге чыгышында Фирдәвес үзен: «Мин – узган гасыр кешесе», – дип атады. Кичәдән соң мин аңа: «Юк, Фирдәвес, син узган гасыр кешесе түгел, син – киләчәк гасырлар артисты», – дидем. Бу вакытта инде ул каты авырганлыктан, аның күңелен күтәрмәкче булып әйткән идем. Кабул итмәде. «Мин узган гасыр кешесе булуым белән горурланып әйттем», – дип, узган гасырдагы кешеләрнең хәзерге кешеләр белән чагыштырмаслык яхшы якларын, иманлы, вәгъдәле булуларын санап китте. Кушылудан башка чарам калмады, әлбәттә.

Ф.Әхтәмова ире Марат һәм кызы Айгөл белән

Шулай да, ятып калганчы атып кал, дигәннән чыгып, аның Бибинур образы Аяз Гыйләҗев язган образга якын түгел, дигән сүз ычкындырдым. Аяз агай совет чорында иҗат иткән, «совет шулпасы»н мул эчкән әдип бит. Сәясәтнең, идеологиянең кулы Совет чорында әдәбиятта да, сәнгать төрләрендә дә бик ачык сизелә иде. Шул сәясәт күп язучыларның кулыннан каләмен алып, аларга көрәк-кәйлә тоттырды.

Аяз Гыйләҗевнең кулы, кәйләдән соң ныгып, каләмен ычкындырмас көчкә ия булды. Аның иҗатында туган җир, туган йорт, әти-әни, ир-ат, яшәү һәм үлем, зират образлары (символик мәгънәдә!) мөһим төшенчәләр булдылар. Әдип күп әсәрләрендә игътибарын татар милләтенең яшәвенә, халыкның киләчәге өчен «даруга рецептлар» тәкъдим итүгә юнәлтә. Аның, әдип буларак, рухи халәтен татар милләтенең язмышыннан аерып карап булмый. Иҗатының төп мотивы да шулдыр.

«Җомга көн кич белән» повестендагы Аксыргак авылының колхоз рәисе Җиһангир Сәфәргалин (44 яшендә генә булуына карамастан) авыл зиратын чистартуга, аны төзекләндерүгә ихлас күңелдән тотына. Символ бит бу! Аның бу гамәлләрен күреп яшәгән тол карчык Бибинур шул яшь рәискә чын күңелдән гашыйк була.

...Кызганыч ки, Җиһангир Сәфәргалинның гомере кыска булып чыга. Аны туган авылы Тегәрҗеп зиратына бабалары янына кайтарып җирлиләр. Бибинур Тегәрҗеп зиратына кадәр барып, «Әлхәм» һәм «Кулһуаллаһу...»сын укып, Җиһангирны мәңгелеккә озата.

Аяз Гыйләҗевнең һәр әсәре татарның йөрәк җылысы белән сугарылган. Ә «Җомга көн кич белән»дәге Бибинурның йөрәк җылысы ул – мәхәббәт белән типкән татар йөрәгенең җылысы. Тереклек өчен җылылык төп шарт. Аяз Гыйләҗевнең әсәрләрен укыган күп кеше аның дөньяга сибелеп яшәгән татар милләтенең рухын, җанын саклау юнәлешендә иң саллы өлеш керткән әдип булуына шикләнмичә, әсәрләре буенча куелган фильм-спектакльләргә дә иманнарын яңартырга баргандай барачаклар, караячаклар, ышаначаклар. Бу фикерләрне мин әдипнең «Җомга көн кич

белән» әсәре буенча күпсерияле фильм-спектакль төшереп күрсәткәч килгән хатларга таянып яздым. Без төшергән фильмда Бибинурны Фирдәвес Хәйруллина уйнады. Ике Фирдәвес – ике Бибинур, ике фильм. (Кызганыч ки, хәзер икесе дә мәрхүмә.) «Бибинур» фильмында Аяз Гыйләҗев рухы калмаган иде. Төсле пыяла аша карaганда дөнья шул пыяла төсендә күренә. Ә «Бибинур» фильмы төрле төстәге пыялаларны катлы-катлы итеп карар өчен төшерелгәндәй иде. (Образлар танылмый, вакыйга читят милләтчә.) Уйлаганын яшерми турысын әйтә торган кеше булуын таныганлыктан, мин фильмны кабул итмәвемне, ошатмавымны белдердем. Ә Фирдәвес фильмның конкурсларда җиңүе, берничә приз яулавы турында сөйләп, минем фикерем белән килешмәүдән: «Син көнләшәсең», – диде. Бәлки, ул хаклыдыр. Бездә шулай бит: «Үзебезнекеләргә – умач, килгәннәргә – күмәч».

Бүген тулы канлы образларны, үзенчәлекле типларны фильм өчен кирәкле муляжлар белән алыштыру сәнгать дип атала, хәтта мактала, бүләкләнә дә. (Замана чире генә булса ярый.) Киләчәктә Галиябану Исмәгыйльгә кияүгә чыкса, Анна Каренина исән калса, Нехлюдов Катеринаны озатып Себергә бармаса – болар барысы да заман режиссерының әсәрне үзенчә чишәргә хокуклы булу «теория»се белән якланылачак.

Фирдәвес Әхтәмованың актерлык карьерасына инде бик тирәнгә кермичә, артык җәелмичә генә килгәндә, андый актриса бар иде, бердәнбер иде, кешелекле иде, ясалмалылыктан мәхрүм – ихлас иде, артыгы белән тугры сүзле иде, дип искә алырга тиешбез.

(Кайсыдыр бер мәҗлестә, сүз иярә сүз чыгып, кемдер минем хатыным Җәмиләне: «Ничек бу артистка кияүгә чыгарга җөрьәт иттең? Аларның күзе гел читләрдә бит...» – дип «чеметеп» алырга теләгәннәргә Фирдәвес: «Әхтәмнең күзе читләрдә булса, аның үзенә карaучы булдымы соң? Юк бит. Безнең кызлар аны яратмады, шуны яраткан Җәмиләсенә рәхмәт инде – ул аннан кеше ясады», – диде.) Үзе күргәнен, уйлаганын өздереп әйтсә дә, аңа рәнҗеп үпкә саклаучыны белмим. Аның кисәтүләре һәрчак вакытлы һәм урынлы була иде.

Бүген театрыбызда Тукай исемендәге бүләк алмаган артистларыбыз бетеп, сәхнәдә ихласлык тансыкка әверелеп барган кабалану-ашыгу заманында, театрыбыз тезгенен кулларыннан ычкындырмас өчен тырышлыкларын кызганмаучыларга, сәхнәдә Фирдәвес рухы яшәсен өчен, ихласлык премиясе булдыруны тәкъдим итәр идем. (Уйнап түгел – уйлап!)

Әгәр шундый премия булдырылып, сәхнәдә ихласлык өстенлек итә башласа, тамашачылар Фирдәвес Әхтәмованы гына түгел, Гөлсем Камскаяны да, Галимә Ибраһимованы да хәтерләп, алар рухына дога кылырлар иде. Алар сәхнәдә уйнап кына яшәмәделәр, ә ихластан яшәп уйнадылар. Аерма бик зур. Әйе, татар театрында ихлас күңелле артистлар, күп булмаса да, бар иде. Алардагы ихласлык рухы яшәргә тиеш. Шунсыз татар милләтенең, үзенең төп милли сыйфатыннан мәхрүм калып, инкыйразга ризалашуы бәхәссездер.

Ихласлык – безнең милләтне башка милләтләрдән аерып танытучы төп сыйфатлардан берсе ул.

Сүземне түгәрәкләп, яшәсен «Ихласлык премиясе», ә сәхнәдә Фирдәвес Әхтәмовалар ихласлыгы дип, каләмемне актрисаның теләктәш дусларына бирәсем килә.

Бер сабакташым, кульязмамны укып чыкты да: «Өстәнрәк язгансың, соңлап кияүгә чыгуын, бердәнбер кызы белән каршылыкларын да язарга иде», – диде. Мин: «Алары турында сүз сезгә бирелә. 2024 елда Фирдәвескә 85 яшь булыр иде», – дидем. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Истә, һаман да истә!

Язучы Азат Әхмәдуллинның туууына 90 ел

Әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы (1994), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1982), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2002), 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин 1932 елның 13 октябрендә Татарстанның Саба районындагы Байлар Сабасы авылында туган. Азат Гыйльмулла улы шунда урта белем ала, аннан соң Казан дәүләт университетында укый, аны тәмамлагач, ике ел Тубыл пединститутында укыта.

1958-1961 нче елларда ул Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасында укый, Татарстан радиокомитетында эшли.

Азат Әхмәдуллин 1981-1999 нчы елларда Казан дәүләт университетында эшли, 1999-2004 нче елларда КДПУда татар әдәбияты кафедрасын җитәкли.

Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин 1964 елда – кандидатлык, ә 1987 елда докторлык диссертациясен яклый. Әдәбиятка ул тәнкыйтьче буларак килә, соңрак әдәбият тарихы, бигрәк тә драматургия белгече буларак танылa.

Азат Әхмәдуллин 2021 елның 8 декабрендә вафат булды.

Галимә Резеда Ганиеваның тууына 90 ел

Әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1992), профессор (1993), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1994) Резеда Кадыйр кызы Ганиева Татарстанның Яшел Үзән районындагы Кече Шырдан авылында 1932 елның 25 октябрендә туган.

1958 елда ул Казан дәүләт университетын тәмамлый.

Резеда Ганиева 1962 елдан Казан дәүләт университетында гарәп, фарсы һәм төрки-татар әдәбиятлары тарихын укыта. «Татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатында сатира» темасына – кандидатлык, Кол Гали иҗатына багышланган докторлык диссертацияләрен яза.

Резеда Ганиева – ике дистәгә якын фән кандидаты һәм докторант тәрбияләгән мөгаллимә.

Галимә 2020 елның 21 мартында Казанда вафат булды.

Гали Хуҗиның туууына 110 ел

Шагыйрь Гали Хуҗи (Гали Хуҗи улы Хуҗиев) 1912 елның 17 октябрендә хәзерге Татарстанның Апас районындагы Карамасар авылында туган.

1932-1934 нче елларда ул «Кызылармеец» газетасы редакциясендә – әдәби хезмәткәр, 1934 елдан – «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы сәркатибе, соңрак редактор урынбасары һәм редакторы була. Гали Хуҗи 1937-1941 нче елларда исә, эштән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогика институтының кичке бүлегендә укый. Ул үзе теләп сугышка китә һәм «Фронт» газетасында җаваплы сәркатип булып хезмәт итә, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Гали Хуҗи 1946-1949 нчы елларда «Кызыл Татарстан» газетасының Буа, Тархан һәм Апас районнарындагы үз хәбәрчесе булып эшли. 1954-1962 нче елларда исә Татарстан Язучылар берлеге каршындагы Яшь язучылар белән эшләү бюросына җитәкчелек итә.

Гали Хуҗи әдәбиятка утызынчы елларда килә. Аның «Шатлык» исемле беренче шигъри җыентыгы 1936 елда басылып чыга. Шуннан соң дистәләрчә китаплары («Яшьлек тавышы», «Комсомолка», «Сабан тургайлары», «Зоя», «Туган җир», «Чын күңелдән», «Мин сөям сезне, дуслар!», «Кояшлы иртә», «Идел хикәясе» һ.б.) дөнья күрә.

Шагыйрь 1966 елның 13 октябрендә вафат булды.

Артист Әнвәр Гобәйдуллинның туууына 100 ел



Татар артисты, Камал театры актеры, ТАССРның халык артисты (1983) Әнвәр Габдерахман улы Гобәйдуллин 1922 елда Казан шәһәрендә туган.

1948 елда ул Камал театры каршындагы студияне тәмамлый һәм Татар академия театрына кабул ителә. 1991-2002 нче елларда «Инсаният» труппасында уйный.

50 елдан артык дәвам иткән иҗади гомер эчендә сәләтле актер тарафыннан 120дән артык кабатланмас образ тудырылды. Шулар арасында Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» спектаклендә – Исаак, Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә – Шәйхел, Хәй Вахитның «Рәхим итегез!»ендә – Илгизәр, Шәриф Камалның «Акчарлаклар»ында – Шәрәфи, Кәрим Тинчуринның «Американ»ында –Сәлим һәм башка образлар аның иҗат биографиясендә генә түгел, татар театр сәнгате тарихы битләрендә дә күренекле урын алган гүзәл образлар иде.

Әнвәр Гобәйдуллин 2012 елның 9 июлендә Казанда вафат булды.

*Сахифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

15 октябрь — 1552 елда Явыз Иван гаскәре явыннан Казанны саклаганда һәлак булган каһарман бабаларыбызны искә алу көне

Мөдәррис Әгъләм (1946-2006)

Хәтер көне

Йомыркадан чыккан чебеш кебек,
Таш капчыктан чыгып кил әбәндә…
Айкалган да халык,
Чайкалган да, –
Чайкалган да халык, түгелгән дә…
Дүрт йөз елдан артык яшәсәң дә
Бабаларың дөнья исәбенә –
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәп булмый
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә…

Күпереп торган илне изү, басу,
Камыр азык ясау дәвам итте…
…һәм, ниһаять,
Өркетелгән милләт,
Кимсетелгән милләт… тәпи китте.
Айны тәре белән алмаштырып,
Җигелсәң дә Мәскәү мичәвенә, –
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәп булмый
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә…

Инде, шөкер, ата-бабаларның
Рухын искә алыр мөмкинлек бар;
Иман эстәү
Эзсез калмас, дигән,
Болай бармас, дигән бер өмет бар.
Казан урамнары чүплек базын
Хәтерләтә иде кичә генә…
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәп булмый
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә…

Күмелгәне һәм күмелмәгәне,
Күз яшьләре булып түгелгәне –
Нәүмиз булып күзгә карап тора
Бер гөнаһсыз кеше гомерләре –
Кисә генә, иблис, кисә генә
Безнең балаларның исәбенә…
Хәтерсезлек хәтәр!
Яшәмәгез
Хәтерләмичә генә, хәтерләмичә генә…

1998 ■

Аны көткән агач улаклар

Рәссам Резеда Яманова үзенең остаханәсендә

«Менә алар, минем балаларым», – дип, Резеда ханым картиналарын күрсәтә башлады. Резеда Яманова иҗаты белән якыннан таныш булмасаң да, алар күңелеңә үтеп керә, чөнки шәхсән син белгән урыннарны хәтерләтә. Су буендагы агач-куак яфракларының шыгырдаган тавышы, чишмәләрнең салмак кына челтерәве, урам буенча үз уйларына чумып барган авыл кешесе, кичен тыныч кына җырланган халык көйләре... Татарстан һәм Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Резеда Яманова иҗаты белән танышу нәкъ менә шуннан башланып китте.

– Резеда ханым, иҗатыгызда шәһәр күренешләрен чагылдырган пейзажлар бармак белән генә санарлык. Сез авыл тормышын сурәтлисез, аның табигате белән илһамланасыз. Сәбәбе нәрсәдә?

– Балачак, җәйге каникуллар, яраткан әбиләрем, әлбәттә, тамырларым – барысы да авылда. Апас районының Сатмыш авылында күңелемә якын булган искитмәле бер урын – өч улаклы чишмә бар иде. Балачакта анда төшеп, суының челтерәп аккан тавышын тыңлаганнарым, улакларда үсеп утырган мүкне сыйпаганым әле дә күз алдымда. Кечкенәдән бирле, аларның гүзәллегенә сокланып, әбигә: «Чишмәләргә ничә яшь? Кем ачкан аларны?» –дигән сораулар бирә идем. Бактың исә, аларны минем бабаемның әтисе шулай матур итеп эшләгән икән! Ул Сатмыш авылының атаклы агач остасы саналган, кайчан карама, янында агач йомычкасы өелеп яткан. Авылның шактый урыннарындагы имән улакларны да ул үзе ясап куйган. Шуңа да ул яклар, аның чишмәләре минем күңелемә икеләтә якын.

– Картиналарда чишмәләрне сурәтләүгә Сезне нәрсә этәрде? Күпләр өчен гади су алу урыны гына булып тоелган чишмәләр Сезне кай ягы белән җәлеп итте?

– Сатмыш авылында бер улак бар иде. Мин аны кечкенәдән бирле күзаллап йөрдем, ничек тә булса аны хәтердә саклап калу ягын уйладым һәм, ниһаять, рәссам булып формалашкач, киндергә төшердем. Шул арада аны Швециядән бер хәлле кеше сатып алды һәм миңа: «Үкенмәячәксезме?» – дигән сорау бирде. Ул сүзләрне күп тапкырлар исемә төшерермен дип уйламаган да идем, әмма авылга кайткач һәм шул улакларны янәдән ясарга дип киткәч, якын танышым әлеге чишмәне бетерүләре турында әйтте. Эсселе-суыклы булып китте. Кәефем бик нык төште. Нәкъ шул көннән соң, Татарстан буенча сәяхәтем башланып китте. Мин шул чишмәне, шул улакларны эзләдем, тик, кызганыч, таба алмадым… Иң аянычлысы – аларны бабаемның әтисе ясап калдырган булган.

Аны авылда «Рәхмәтулла кисмәкче» дип йөрткәннәр. Ул Сатмышта иң беренче рус капкасын эшләгән, кисмәкләр, агачтан савыт-сабалар ясаган. Бабамның җиһазларында – тарих, миңа калдырган мирас. Шуңа бала вакыттан ук минем аларны хис-кичерешләремне салып чагылдырасым килде. Тик без барысы да мәңгелек дип уйлыйбыз шул. Әлбәттә, кайбер улакларын мин ясап өлгердем. Әмма элеккеге картина юк иде инде.

– Яңартылган яки борынгыдан элеккечә сакланган чишмәләр – кайсылары Сезнең илһам чаткыларын кабызып җибәрә?

– Чишмәләрне хәзер буйыйлар, калай белән тышлыйлар, заманча кыяфәткә китерәләр. Иске агачта, табигый материалларда бит вакыт, гасыр сизелә, буяу исә аны юкка чыгара. Гомумән, рәссамнар искелекне ярата. Ник дигәндә, нәкъ борынгы әйбер, җиһаз яки бина картинага җиңел ята, аның белән эшләве рәхәт, ул синдә фантазия тудыра, уйланырга этәрә. Кирпечтә, ташта, калайда, гомумән, тимердә поэзия һәм эстетика юк. Бу факторлар иҗат кешесенә бик зур тәэсир ясый.

– Чишмәләрдән тыш, рәссам буларак, Сезне тагын нинди образлар үзенә тарта?

– Васильево бистәсендә йортым бар, ул якларда коелар шактый икән. Мин аларның һәрберсен унышар тапкыр, төрле ракурстан диярлек ясап чыктым инде. Иртән-кичен, җәен-кышын, уңнан-сулдан, кечкенәсен-зурысын картон кәгазендә, киндердә. Иң әһәмиятлесе – объект белән кызыксынуым бер дә кимеми. Шулай Кырлайда бер түкне (печән чүмәләсе. – *А.С.*) мин өч ел рәттән ясадым. Ул килгән саен кечерәя барды, үлән белән капланды, әмма аны беркем дә җыярга уйламады. Акрынлап ул миңа җанлы образ булып тоела башлады. Соңыннан мин Башкортстан, Чуашстан якларында таныш образларны күрү, аларны тоемлау, тарихларын өйрәнү эшен башлап җибәрдем. Гомумән, һәр якның табигате үзенчә булып чыкты. Кырлайда агачлар арасында ниндидер сер, «шүрәле» сагалап йөрсә, Апас якларында таллар сокландыра, уйга сала. Барысы да уникаль.

– Авыл тормышы төрле төсләргә бай: күңелле Сабан туйлары, җыеннар, көндәлек тыныч тормыш, салмак кына аккан елгалар... Резеда ханым, Сезгә нәрсә якын?

– Шау-шуны, тавышларны җенем сөйми, шуңа шәһәрне ясарга бик яратып бетермим дә. Авылда, табигать кочагында исә мин тынычлык, романтика сизәм, җаныма рәхәтлек алам. Авылның көндәлек тормышы йөрәгемә икеләтә якын, чөнки ул җылы хисләр тудыра, матур хатирә булып, балачак кайтавазыдай яңгырый.

– Картиналарыгызны карап чыккач, аларда төп рольне өлкән буын вәкилләре – әби-бабайлар башкара икәнен тойдым.

– Бу, беренче чиратта, ике әбием белән бәйле. Маһинур әби сугыш вакытында авылда бригадир булып эшләгән, колхозны торгызган. Ире сугыштан кайтмаган, шуңа ул өч баланы, авыр хәлдәге сеңлесен ялгызы карарга, авыр тормыш йөген төпкә җигелеп тартырга мәҗбүр булган. Әбинең сеңлесен – Рабига апайны мин балачактан ук бик яраттым һәм менә шул ике әби образы иҗатымда һәрчак чагылып бара. Алар – иҗатымның үзәге, һәрвакыт янәшәдәге илһамым. Сугыштан кайтмаган Сәлим бабаем турында да искә алмый мөмкин түгел. Ул Гродно шәһәрендә әсирлеккә эләккән һәм фашист концлагерендә 29 яшендә дүрт айдан соң вафат булган. Авылда иң төз, чибәр, сәламәт егетләрнең берсе шундый кыска вакыт эчендә дөньядан китә... Рәсем сәнгатенә тартылуым да нәкъ шул бабаемнан килгәнлеге билгеле булды.

– Картиналарыгызда тормышка хас булмаган артык ачык төсләр кулланып эш итәсез. Бу нинди максаттан чыгып эшләнелә?

– Күбрәк караган саен, ачыграк, матуррак күрәсең. Элеккеге картиналарга күз салсагыз, аларда төсләр тоныграк. Кайчак алардагы тоник «элпә»не салдырасым килеп китә.

«Беренче кар»

«Көзге кое». Васильево бистәсе. 2009 ел

Әби портреты. 1983 ел

«Әбиләр чуагы»

«Зәйтүнә апа иртәсе». 2005 ел

– Шулай ук детальләргә дә зур игътибар бирәсез.

– Әйе, миңа картинада объект янына килеп, аны өйрәнеп, барлык почмагыннан карап аңлау мөмкинлеге булу мөһим. Ул тулаем ясалып бетәргә тиеш, таплар белән эшләү ысулы бөтенләй минем жанрга туры килми.

– Жанрларга килгәндә, кайсыларына күбрәк мөрәҗәгать итәсез?

– Рәсем сәнгате дәресләренең барлык этапларын да уздым, шуңа натюрморт та, портрет та, пейзаж да, сюжетлы картиналар да ясый беләм. Кайсысы күбрәк ошый, дигәндә, ул билгеле бер чорга бәйле. Мәсәлән, мин ун ел бары натюрморт кына ясадым, хәзер 12 еллык тәнәфес алдым, аларга яңадан әйләнеп кайтырга теләгем юк. Ләкин авыл пейзажларына, андагы сюжетларга мәхәббәтем беркайчан да сүрелмәячәген бик яхшы беләм. Һәрвакыт натурадан ясарга кирәк, чөнки ул – иң яхшы укытучыларның берсе. Шуңа минем күзләр һаман эзләнүдә, яңа образ табуда. Кыскасы, аларның һәркайсы үз тормышы белән яши.

– Резеда ханым, картиналарыгызда иң мөһиме нәрсә? «Әйе, бу Резеда Яманова эше», – дип әйтерлек нинди сыйфатлары бар?

– Күрәсезме, менә бу картинада әнинең туган авылы сурәтләнгән. Ә монысы – мин бик яратып кунакка килә торган Кырлай. Мин туган җиремнең төрле урыннарына гашыйк һәм алар да миңа шундый хисләр белән җавап кайтара. Бары тик минем картиналарга гына хас сыйфатлар юк дияр идем, чөнки эшемне тагы да яхшырак, тагы да үтемлерәк итәргә омтылам.

– Бер урынга янәдән килеп, башка төрле картина ясап буламы?

– 2014 елда миңа Сатмыш авылында картиналар күргәзмәсен оештырырга тәкъдим иттеләр. Агач авыл клубы, яңа гына юылган агач идән, мин балачакта күргән, әмма инде күптән олыгайган танышлар һәм авыл тормышын сурәтләгән иҗатым. Бу бәйләм бик җылы тәэсир ясады миңа. Шуңа озак та үтмәде, көзен Сатмыштагы чишмәгә, улаклар янына кире кайттым. Чишмә янына бер атна буе барып, аның шифалы суын эчеп, картина өстендә 7 сәгать дәвамында эшләдем. Кинәт беренче кар төште. Озак уйлап тормадым, икенче картинаны ясый башладым. Аны мин «Беренче кар» дип атадым. Күпләр аннан салкын җилләр искәндәй тоела, диләр, ә Сез ничек уйлыйсыз?

– Әйе, чыннан да, салкын, куркыныч тәэсир калдыра...

– «Беренче кар» зәмһәрир суык көндә ясалды, тәмам өшеп беттем. Әмма чишмәләрдән бик илһамланып кайттым. Кызганыч, берничә айдан соң ул улакларны да сүтеп бетерәчәкләр...

– Замана рәссамы нинди ул?

– Рәссам ул – барлык мәшәкатьләрне, планнарны, гаиләне, эшне, туганнарны икенче урында калдырып, картина ясарга дип җирнең теләсә кайсы урынына юл тоткан кешедер. Мин дә шундыйлардан. Урамда салкын, яңгыр – монысы мөһим түгел, чөнки, пленэрга килгән рәссамнар белән бергәләп, син иҗат итәргә барасың. Кемдер пленэрга хатыны, ире, әти-әнисе белән кычкырышып килә. Рәссам һәрвакыт эзләнүдә.

Эзләнүләргә килгәндә, мин бит Сезгә бер тарихны сөйләп бетермәдем. Танышымның Сатмыш авылындагы бабаемның әтисе ясаган улакларның юкка чыгуы турындагы хәбәрен хәтерлисезме? Өч ел элек әни белән шул урыннарны урап кайтырга булдык. Ни күрим! Улаклар бит үз урынында! Мин егерме ел буе Татарстан авыллары буенча шул улакларны эзләп йөрдем, әмма таба алмадым. Ул исә янәшәдә, йөрәгем түрендәге авылда сакланып торган икән! Әлбәттә, тизрәк пумала артыннан йөгердем. Картина әзер булгач, ул улакларны җимерделәр. Шулай итеп, иҗат сәяхәтем бер ноктага килеп җитте, әмма әле дә тәмамланырга уйламый.

***

Резеда Яманова картиналары белән таныштыруын дәвам итте. Һәрберсенең тарихын, ясалу урынын, исемен белә ул һәм аларны, үз баласыдай, җылы караш белән назлый. Менә Чуаштандагы үзенчәлекле очлы түкләр, ә менә монысы очраклы табылган, авылда берүзе генә калган салам түбәле йорт... Һәрберсендә туган җиребезнең Резеда Яманова карашы аша узган гүзәллеге, җылылыгы, самимилеге чагыла. «Әлеге әңгәмәдән соң син дә бу дөньяга бөтенләй башкача карый башлаячаксың», – диде ул миңа. Чыннан да, редакция янында үскән чикләвек агачы бүген тагын да матуррак иде...

Әңгәмәдәш – ***Айзилә Сабирова*** ■

Апастагы тиңсез хәзинә

Апастагы Туган якны өйрәнү музеенда халкыбыз тарихына нисбәтле гаять бай экспонат саклана. Аларның кайберләре турында безгә музейның җитәкчесе Рамис Ногманов сөйләде.

Садри Җәләл мирасы

«Садри Җәләлнең Айсылу исемле кызының улы Валерий Николаевич музеебызга язучының шкафын бүләк итте. Искиткеч зур хәзинә! Аның эчендәге 1800 нче елларда Кузнецов фабрикасында чыгарылган фарфор савыт-саба комплекты, теш табибы булып эшләгән Айсылу ханымның фотоальбомы, Мактау кәгазьләре, тегү машинасы, шәхси әйберләре, Садри Җәләлнең китаплары – барысы да музеебызга алынды».

Садри Җәләл шкафы

Хикмәтле таяк

Хикмәтле таяк

«Әлеге серле экспонатны Тутай авылыннан Вәкил Мотыйгуллин бүләк итте. Бу – календарь. Таякның хикмәте – сырларында. Анда 365 сыр бар. Сырлар буенча ай, атна һәм көннәрне билгеләгәннәр икән. Әмма таякның серенә тулысынча әлегә кадәр төшенә алганыбыз юк. Гаҗәп бит!»

Мулла мөһере

Мулла мөһере

«Мулла мөһерен Аюкөйдергән авылыннан алдык. Аңа Сәлах мулланың исеме, ташны чокып, ике имля белән дә язылган. Мөгаен, ул метрика кәгазьләренә шушы мөһерне суккандыр».

«Бабакай»

«Күперләрнең субайларын сугар өчен эшләнгән җайланма бу. Тоткычлары элек агачтан ясалган булган. 6-7 кеше күтәреп, субайга сугып, балчык эченә батырганнар. Аннары күперне салганнар. Ритмны саклар өчен:

«Ай-хай-хай,
Бер, ике, өч,
Ба-ба-кай...» –

дип кабатлаганнар.

Бу экспонат Барыш авылыннан кайтты. Андагы Үләмә елгасы һәр елны язгы ташу вакытында күперне агыза торган булган. Ә сипләр өчен ел саен диярлек субай сугарга кирәк». ■

«Бабакай»

Музейда төшерелгән видеолар белән журналыбызның социаль челтәрләреннән танышырга мөмкин.

Җуелмас хәзинә

«Рәйхан» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Рәйхан

(Татар халык җыры)

Аклы ситсы күлмәгеңнең
Якаларын кем уйган?
Әй Рәйхан, исемең кемнәр куйган,
Сине күреп кем туйган?

Аклы ситсы күлмәгеңнең
Таба алмадым ишләрен;
Әй, гомерем буйларына, Рәйхан,
Оныта алмасам нишләрмен?!.

Аргы яктан бирге якка
Басма салдым киң итеп;
Әй, гомерлек яр булсын дип,
Сине сөйдем тиң итеп.

«Рәйхан» җырының Казанда язып алынган бер нөсхәсендә мондый дүртьюллык та бар:

«Суга барсаң, бар иртәрәк,
Соңга калсаң, болгана.
Әй, кызарып кояш чыкканда
Без түгел, кош моңлана».

Галим һәм шагыйрь Әнвәр Шәриповның «Рәйхан» җырына нисбәтле истәлеге мондый: *«Ул чакта миңа җиде-сигез яшьләр булгандыр. Туган авылым Кәрәкәшледә җәйге көн сүнеп барган вакыт. Мин урамда уйнап йөрим. Көтүләр кайткан, сыерлар савылган. Авыл ашыкмый гына төнне каршы алырга әзерләнә. Баеп барган кояшның соңгы нурлары, сәер бер ямансу халәт тудырып, бөтен тирә-якны иркәли. Бөтен җиһанны җәйге кичләрдә генә була торган тынлык-тынычлык биләп алган. Рәхә-әт!*

Мәшһүр җырчы, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты (1950, 1957), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1959), «Рәйхан», «Сибелә чәчәк», «Сакмар», «Су буйлап» кебек искитмәле татар халык җырларын оста башкаручыларның берсе, Апас районының Шәмбалыкчы авылы тумасы Фәхри Хөсәен улы Насретдинов (1911-1986)

Шулчакта көтмәгәндә безнең бакчалар артында кемдер җыр сузып җибәрде. Бөтен авылга кемнеңдер күңел түреннән чыккан сихри моңы таралды. Хатын-кыз тавышы иде ул. Көтүдән кайтмый калган сыерын эзләп йөри идеме ул, әллә күңелен биләп алган сөю-мәхәббәт хисләренә ирек биреп, күңелен бушатуы идеме – кем белсен.

«Гомрем буйларына, Рәйхан,
Оныта алмасам нишләрмен?!.»

Мин, уенны онытып, җырның тылсымына бирелеп, туктап калдым. Беренче тапкыр ишетә идем мин аны. Никадәр сөю, никадәр сагыну-сагыш бар иде җырда! Сүзләр белән әйтеп бетерә алмаслык сәер халәт, рухлану кичердем ул чакта. Менә нинди икән ул халык җыры! Бөтен барлыгыңны актарып ташлап, сине сихерләп, күңелеңә кереп урнаша икән. Шунда мин төшендем: мондый җырны бары бөек халык кына, сөю-мәхәббәтнең тирән сагышын аңлаган, аны үзе кичергән халык кына чыгара ала!»

Әлеге җыр Ф.Насретдинов, Ф.Кудашева, Ш.Әхмәтҗанов, Р.Ильясов, М.Сөнгатуллин, С.Фәтхетдинов, С.Хәкимова репертуарында бар.

Тәртип радиосы

*Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – **Гөлфия Мөхәммәтгәрәева**) материалларына нигезләнеп, **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Тирәк

Тирәгең булса, терәгең булыр.
Татар халык мәкале

Тирәк (тупыл) – таллар семьялыгына керә торган, тиз үсә, биек, төз кәүсәле, куе яшел яфраклы агач.

Татарның традицион мәдәниятендә тирәк киң ябалдашлы агач булганга да «шәҗәрә агачы» буларак күзаллана. Дөрес, фольклор жанрында аның башка номинациясе – байтирәк тә очрый. Күчмә төрки-татарларда байтирәк ыруның үзәк туплану ориентиры булган. Кагыйдә буларак, кабилә үзенең җитди проблемалары хакындагы сөйләшүләрен нәкъ менә шушы агач төбендә алып барган. Хакимнең өйләнергә җыенучы улларына көтүлек җирләрен билгеләүне дә шунда хәл иткәннәр, башка ыруның кияүләрен дә шунда кабул иткәннәр, яшүсмерләргә хас инициация йолалары, төрле бәйрәмнәр байтирәк янында үткән.

Бүген дә тирәкнең әлеге семантик кыры югалмаган. Күп кенә татар авылларында гаиләнең ыру агачы булып, аларны, үз фразаларынча, әрвахлар галәме белән тоташтыручы карт тирәкләр әле дә үсеп утыра. Агач никадәр картрак булган саен, аның хәтере дә шулкадәр тирәнрәк, ул ыруның һәр кешесен, һәр гамәлен белә, шуңа да нәселне берләштерүче мөһим үзәк дип уйлый алар.

Тирәк бик биек, киң булып үсә торган агач булганга, аны, гадәттә, бакча артларына, тыкрыкларга, өй араларына, яр кырыйларына утыртканнар. Тирәк өй белән янәшә үссә, аны, чит кеше утырткан булса да, кисмәгәннәр.

Авыл урамындагы тупыл-тирәк

Ике өй арасына утыртылган тирәк аларны янгын афәтеннән дә саклаган. Аннары тирәкнең бер үзенчәлеге бар: ул, сеңдергеч кебек, әйләнә-тирәнең начар һавасын, энергиясен үзенә ала. Шуңа күрә тирәк, экологияне яхшырту максатыннан, санитар агач буларак, элек шәһәр урамнарына күпләп утыртылган.

Татар авылларында хәзер яшь тирәкләрне бик сирәк очратасың. Ә булганнарының кайчан, кем тарафыннан утыртылганнарын да инде хәтерләүче юк.

*Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Фәнзилә Җәүһәрова**) белән берлектә әзерләнде.* ■

Тирәк (тупыл) турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Тупыл дәвалый

Тупыл бөресеннән ясалган төнәтмә цинганы дәвалый

Файдаланыр алдыннан тупыл согын җиңелчә генә җылытып алалар

Тупыл бөреләреннән ясалган экстракт халык медицинасында киң кулланыла. Мәсәлән, ревматизм, туберкулез һәм подагра булганда, шулай ук ишиас һәм цингадан файдасын күрәләр. Аны яраларны, пешкән урыннарны дәвалауда да кулланалар. Фурункулдан ярдәм итә.

Кара тупыл яфракларыннан ясалган төнәтмә бавырны һәм эчәкләрне дәвалаганда бик файдалы, салкын тигән вакытта температураны төшерә, кычынудан да файдасы бар. Күңел төшенкелеге вакытында да аның ярдәме тия.

Тупыл кайрысының төнәтмәсе малярия һәм бизгәк вакытында булыша. Ревматизмны һәм подаграны дәвалый.

Тупыл яфракларын сыгып ясалган сыеклык теш сызлаганда файдалы. Шундый ук сыеклыкны баш шаулаганда колак тишекләренә өчәр тамчы тамызалар.

Пешкән урыннарны, яраларны дәвалау өчен өй шартларында яфрактан май (мазь) ясау ысулы: яңа өзелгән яшел яфракларны боткага әйләнгәнче төяләр, аннары, атланмай яисә вазелин кушып, яшел масса хасил булганчы болгаталар.

Гинекологик авырулар һәм геморрой булганда тупыл бөреләреннән мондый май ясала: пыяла банкага 50 грамм бөре салына, аның өстенә 500 грамм (ярты литр) теләсә нинди сыек май (әйтик, зәйтүн яки йөзем мае) агызалар һәм бер ай җылы урында тоталар, соңыннан әзер сыеклыкны әйбәтләп сөзәләр.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2022

Кабак бәлеше – тәм-том бәйрәме!

Туган ягыбызның теләсә-кайсы төбәгендә, һәр өй бакчасында, һәр басуда тир түгеп үстергән уңышны җыю процессы бара. Көзге муллыкны җыю, уңыш белән мактану һәм Аллаһыга рәхмәтле булу безгә борынгы бабаларыбыздан килгән. Шул уңыштан тәмле сыйлар әзерләп, мул табын оештыру гадәте исә хәзерге заманга кадәр дә сакланган.

XIX гасырда күбесенчә ит һәм сөт ризыкларына бай булган татар кухнясы яшелчәләр белән дә тулыландырыла башлаган. Беренче чиратта, кишер һәм суганны токмачлы ашка тәмләткеч буларак кулланганнар. Шалкан, кабак ашаганнар. Яшелчәләр татарлар өчен күп вакытлар дәвамында бары тик төп ризыкка – иткә кушып ашала торган сый буларак кабул ителгән.

Татар халкы яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең файдасын беркайчан да кире какмаган. Төрле файдалы үләннәр һәм тамырлар халык медицинасында киң кулланылган.

Ә җиләк-җимешләргә татарның карашы бөтенләй икенче булган. Күп төбәкләрдә җиләк-җимешләрне сату мөселман сәүдәгәрләре тарафыннан башкарылгач, татарлар ул тәм-томнар белән тукланганнар, аларны милләтебезгә хас булган камыр ризыкларына да кушып җибәргәннәр, табынга куйганнар, һәм күчтәнәч итеп тә биргәннәр.

Татар халкы аш-суда төрле яңалыклар яраткан, шуңа хатын-кызлар аш-су бүлмәләрендә нинди генә «тәҗрибә»ләр үткәрмәгән. Рационда яшелчә, камыр, ярмалар, сөт ризыклары, җиләк-җимешләр булу да аларны яңа камыр ризыгы – бәлеш уйлап чыгаруга этәргән. Сүз барыбызга да таныш кабак бәлеше турында. Ул – көзнең иң матур, бәйрәмнең иң күркәм вакытында табынга куелган. Шуңа без бу юлы, билгеләп үткәнебезчә, кабак бәлешенә тукталырбыз.

Кабак бәлеше әзерләү турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Кирәкле ингредиентлар:

Камыр өчен:

- 20 г чүпрә;
- 1 аш кашыгы шикәр комы;
- 1 бал кашыгы тоз;
- 100 г сыек май;
- 300 г сөт;
- 2 йомырка;
- 500 г он.

Эчлек өчен:

- уртача зурлыктагы кабак;
- 200 г дөге (тары ярмасы да ярый);
- 80 г шикәр комы;
- 200-250 г сары май;
- 100 г корт;
- 150 г йөзем җимеше.

Эш барышы:

1. Кабак бәлешен, гадәттә, әче камырдан пешерәләр, тик кайчагында, зур бәлеш кебек, төче камырдан да ясыйлар. Без исә әче камырдан әзерләргә булдык. Савытка чүпрә, сөт, тоз, шикәр комы салабыз һәм яхшылап болгатабыз. Йомырка сытып, сыек май кушабыз һәм янәдән туглыйбыз. Шуннан соң он салабыз һәм камыр изәбез. Тизрәк кабарсын өчен, камырның өстен каплап, җылы урында калдырабыз.
2. Эчлек ясыйбыз. Өлгергән, каты, баллы кабакны урталай ярабыз да эчен чистартып, кабыгын әрчибез һәм вак итеп турыйбыз. Тоз сибеп бераз тотабыз яисә яхшылап аралаштырабыз һәм, иләккә салып, суын саркытабыз.
3. Аннары кабакка бүрттереп суыткан дөге, йөзем җимеше, шикәр комы кушабыз, эрегән сары май, тоз салып, барысын бергә болгатабыз.
4. Бәлеш төбенә, бигрәк тә аны зур бәлеш кебек ясаганда, корт салырга да мөмкин. Без дә бәлеш төбенә корт салдык.
5. Аннары табага кабак, дөге, кайнар суда йомшартылган йөзем салабыз. Өстенә сары май куеп чыгабыз. Шуннан соң камыр белән бәлешнең өстен каплап, 180 градуслы мичтә пешерәбез.

Инде кабак бәлеше әзер! Татар халкының рационында зур урын алып торган төп продуктлар – камыр, сөт ризыклары, җиләк-җимешләр, яшелчәләр, ярма – барысы да, беләзек булып, бер-бер артлы тезелде һәм безгә искитмәле тәм-том бәйрәме оештырды.

Көзге салкын кичләрдә якыннарыгызны татар халкының бу татлы һәм файдалы камыр ашы белән сыйларга онытмагыз, дуслар! Ашларыгыз тәмле һәм сыйфатлы булсын!

*Сәхифәне **Айзилә Сабирова** әзерләде.* ■

Көлке куа килә...

Яшь язучылар өчен зур сөенеч

(Язма янына Ибраһим Нуруллинга охшаган берәүнең газетадан кисеп алынган рәсеме ябыштырылган)

Язучылык осталыгына өйрәнү өчен яшьләргә тиздән зур мөмкинлек туачак: Татарстанның Язучылар союзы һәм Китап нәшрияты шундый бер китап чыгара. Анда Владимир Маяковский, Зәки Нури, Виссарион Белинский, Ибраһим Нуруллин һәм башкаларның үз иҗат тәҗрибәләре турындагы мәкаләләре урнаштырылган.

Нури һәм Нуруллиннарның иҗат тәҗрибәләре ни дәрәҗәдә кыйммәтле – бу һәркайсыбызга билгеле. Ләкин алар белән бергә В.Маяковский һәм башкаларны бу китапка кертү иртәрәк түгел микән?! Укучылар моңа да әһәмият бирерләр дип ышанабыз.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, авторы билгесез, 1987 ел)

Фәнис Яруллин (1938-2011)

Ватан сугышына торырлык

Урындык һәм кеше аерылгысыз,
Урындыксыз кеше – юк кеше.
Урындыксыз булсаң – син нишләмә –
Тик чүп кенә була һәр эшең.

Даһилар да даһи була алмый,
Аларга да кирәк урындык.
Урындыклар күп ясала бездә,
Тик куярга гына урын юк.

Зур-зур биналар да калкып тора,
Кабинетлар арта исәпсез.
Ләкин һаман күпләр кала бирә
Урындыксыз һәм дә өстәлсез.

Ипи түгел, итләр, майлар түгел,
Кирәк безгә бары урындык.
Көрәш бара урындыклар өчен
Ватан сугышына торырлык.

Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

Тәүбә

(Каләмдәш дусларыма ачык хат)

Хөрмәтле иптәшләр, кадерле каләмдәш туганнарым! Беләм, сезнең каршыгызда бик тә гаеплемен. Бары бернәрсә генә әйтә алам: мин бит аны зур акылым белән түгел, ә чын күңелемнән эшләгән идем.

Ничектер, шулай туган якларга кайтып төштем. Яңа аерткан каймак эчкәннән соң, бер повесть язып ташладым. Укып чыкканнан соң, үзем дә шүрләп куйдым, коточкыч шәп чыккан бит бу! Журналда да башта икеләнеп калдылар, шулай да бастырып чыгардылар.

Менә шуннан соң башланды инде хәлләр! Укучылар яза, тәнкыйтьчеләр мактый, күршеләрем горурлана, ә язучылар... миннән бөтенләй йөз чөермәсенме! Мин башта үпкәләп тә куйдым, соңыннан гына барып җитте – мин хаклы түгел! Уйлап кына кара, әле генә каләм очлаган кеше, нахалланып, исемле зур язучыларның иҗади биленнән түбән бәрсен әле!

(«Тынгысыз каләм», 1981 ел)

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Хикмәтле икеюллыклар

Тәрәккыйпәрвәр булдылар Мәстүрәләр –
Иваннарга Ычтапаннар үстерәләр.

***

Никадәр язучылар!
Ә ничә язучы бар?

***

Курортларда син дә мулла, мин дә мулла!
Шунсы читен: остабикә уртак була.

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Марс Шабаев
(1933-2008)

Зәңгәр песи

Бик ярата зәңгәр төсне
Зәңгәр песи,
Зәңгәр песи.
Зәп-зәңгәрдән
Киенгәндер-бизәнгәндер:
Үзе зәңгәр,
Күзе зәңгәр.
Зәңгәр песи,
Зәңгәр песи
Тотып кайткан зәңгәр күсе.
Тоткан булса песи әгәр
Тычкан-мазар,
Анысы да булыр иде
Зәңгәр-зәңгәр.
Зәңгәр песи
Эчә зәңгәр тәлинкәдән
Зәңгәр сөтне,
Зәңгәр сөтне.
– Нигә, – диеп, – барсы зәңгәр?! –
Сорасагыз миннән әгәр –
Соң, шуны да белмисезме,
Соң, шуны да күрмисезме:
Буяу карандашым зәңгәр!

Әхсән Баян
(1927-2013)

Дәү әтинең көче

Сәрвиназ кемнең көче нихәтле булуы турында сөйләп торды да аннары дәү әтисен телгә алды.

– Иң көчлесе – минем дәү әти. Аның көче менә монда хәтле җитә, – дип, кулы белән муенын сыйпап күрсәтте.

Табигатьтә кунакта

Куян

Арыслан, куян, ишәк, жираф, бегемот, селәүсен, аю, дөя, төлке, бүре…

Әйе, боларны һәм тагын бик күп җәнлек-җанварларны зоопаркта күрергә мөмкин. Алар турында сез ниләр беләсез? Мәсәлән, куян турында.

Куян (аны үр куяны да диләр), гадәттә, көрән-соры төстә була. Аның авырлыгы алты килограммга җитә. Ул басуда, кечкенә урманда, далада яши.

Төлке, бүре, селәүсен, бөркет, мәче башлы ябалак – куянның дошманнары.

Үр куяны елына ике, ә кайчакта дүрт тапкыр да балалый. Һәр юлы өч-алты бала китерә.

Куян көз көне йонын алыштыра: соры йон урынына кар кебек ап-ак йон үсеп чыга.

Такмак

Безнең песи бигрәк уңган:
Комганга су тутыра.
Бозавыбыз мич башында
Оек бәйләп утыра.

Әйдәгез, уйныйбыз!

Кәҗә

Балалар стенага яки коймага карап басалар. Бер бала стенага туп ыргыта. Стенадан кире бәрелгән тупны балалар үзләренә тидермәскә тырыша. Әгәр туп кемгә дә булса тисә, ул балага «кәҗә» сүзенең «к» хәрефе «ябыштырыла». Кем тупны үзенә тидереп «кәҗә»нең бөтен хәрефләрен дә иң беренче тутыра, ул «кәҗә» була. Аңа җәза бирелә.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

СЕНТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Сентябрь аенда атаклы Үтәмешевләр династиясе вәкиле, күренекле педагог, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче Маһруй Үтәмешевага (1862-1904) кагылышлы яңа китап дөнья күрде. Авторлары мәшһүрләребез Галимҗан Баруди һәм Шәһретдин Шәрәф булган әлеге китап (бастыру өчен җаваплы – тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров, басмага әзерләүче – филология фәннәре кандидаты Айдар Гайнетдинов) ТР Мөселманнары Диния нәзарәтенең Кукмара районы мөхтәсибәте ярдәмендә «Иман» нәшриятында нәшер ителде.

● 1 сентябрьдә Татарстан Мөселманнары Диния нәзарәтенең Әлмәт шәһәрендәге «Нур» татар-мөселман мәктәбенә 70 бала укырга килде. Аларның ундүрте – беренче сыйныф укучысы. Бүгенге көндә мәктәптә 5 башлангыч сыйныф, 1 инглиз теле укытучысы һәм өстәмә белем бирүче 3 белгеч укыта.

● 5 сентябрьдә Казанның Толстой урамындагы Роберт Миңнуллин яшәгән йортта шагыйрьгә мемориаль такта ачылды. Анда Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Дәүләт Советы Рәисенең урынбасары Марат Әхмәтов, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, ТР Язучылар берлеге

рәисе Ркаил Зәйдулла, депутатлар, әдипләр, журналистлар һәм шагыйрьнең иҗатын яратучылар җыелган иде.



● 5 сентябрьдә «Татмедиа»ның конференц-залында күренекле дин галиме Нургали Хәсәновка (1852-1919) нисбәтле яңа китапны тәкъдим итү чарасы булып узды. Чарада китап авторы Рәшит Амишов, күренекле галимнәр һәм журналистлар катнашты.

● 10 сентябрьдә Буа шәһәрендә күренекле дин белгече Нургали Хәсәновның тууына 170 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Чарада ТР Мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Буа муниципаль район хакимия-

те башлыгы Ранис Камартдинов, галимнәр – Төркиядән Омар Хакан, Искәндәр Гыйләҗев, Рәмил Исламов, Флера Сәйфуллина, Гамирҗан Дәүләтшин, Рәшит Амишов, Буа дәүләт драма театрының җитәкчесе Раил Садриев, Ульяновскидагы Идел аръягы районы татар автономиясе һәм «1 нче мәхәллә» рәисе Рафаэль Нәҗметдинов, ТР мәдәният министрының киңәшчесе Нияз Игъламов, «Безнең мирас» журналы һәм «Сиражи сүзе» газетасының баш мөхәррирләре һәм хезмәткәрләре – Ләбиб Лерон, Искәндәр Сиражи, Ленар Гобәйдуллин, Рәфидә Галимҗанова һәм башкалар катнашты.

● 10 сентябрьдә дин белгече Нургали Хәсәновка нисбәтле халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашучылар, Толымбай авылында (Буа) булып, мәгърифәтче, дәвачы, ишан Әхмәр Юныс улы Толымбай (1763-1819) каберен зиярәт кылды.

● 10 сентябрьдә бер төркем дин һәм каләм әһелләре, галимнәр, дин белгече Нургали Хәсәновның Буа зиратындагы каберен зиярәт кылып, мәшһүр шәхес рухына дога ирештерделәр.

● 10 сентябрьдә Буа районының Туган якны өйрәнү музеенда Буа дәүләт драма театры дин белгече Нургали Хәсәновка нисбәтле

«Дәрвиш» спектаклен (режиссеры – Тимур Кулов) конференция кунакларына тәкъдим итте.

● 17 сентябрьдә Казанда «Әхмәт ибн Фадланның Итил елгасына сәяхәте» китабы буенча бәйгенең сайлап алу туры узды. 50гә якын кеше китап турында тест рәвешендәге 50 сорауга җавап бирде. Бәйге август ахырында ТР Мөселманнары Диния нәзарәте һәм «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан игълан ителгән иде. Иң күп балл җыючылар 22 октябрьдә Казанда узачак финалда катнашачак. Бәйгенең төп призы – тауда йөрүче велосипед. Икенче урын яулаучы робот-пылесос алачак, өченче урын өчен электр самокаты тәгаенләнгән.

● 26 сентябрьдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, татар әдипләре һәм сәнгать әһелләре катнашында, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Разил Вәлиевнең иҗат кичәсе булып узды.

● Сентябрь аенда Апаста иганәче Әсгат Галимҗановка (1936-2016) нисбәтле яңа китапны тәкъдим итү чарасы узды. ■

МИРАСВОРД

«Калфаклы сандугач»

Апас районындагы авыл

Тар авызлы күн капчык, турсык (иск.)

Бурада бүрәнәләрдән салынган бер рәт

Актер ... Нуруллин / Такан

Хәләф, Низами

Габдерахман ... (театр белгече, тәнкыйтьче)

Ашарга яраклы үлән

Коры елга

Габдулла Тукай шигыре

Күренекле татар балалар шагыйре

Литваның борынгы башкаласы

Аккургаш белән каракургаш эретмәсе

Алла тарафыннан пәйгамбәр күңеленә салынган фикер

Татар халык җыры

Көлке көлә килә, артыңнан ... килә

Зур, хуш исле чәчәкле бакча гөле

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Садак эчендә / Разил, Диас, Асаф

Аваз, тавыш (иск.)

12 ай / Оят, намус (иск.)

Монархның асылташлар белән бизәлгән баш киеме

Язучы, «Ну, погоди!» мультфильмының сценарий авторы

Гарәп артикле

Җырчы ... Насретдинов

Конфуций Ватаны

Россия вертолеты

... Герц (немец физигы)

Борынгы Идел

... Роговцева / Диктор ... Абдулла

Суз, сөйләм (иск.)

Актриса ... Бернар

Җәвахарлал ...

Шагыйрь Зыя ... / Һинд кызлары киеме

Филипп ... (француз актеры)

Иран мифологиясендә явызлык алласы

... дөнья

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: җоба, аучы, ел, Аюка, Бәян, Күзкәй, ушат, игәр, тора, турнир, чуман, ашау, лари, Али, «Ил», Сая, би, Ниязи, Янка, Хәсни, иләм, Франс, Урал, Әминә.
Өстән аска: бәет, «Ася», углан, лар, яу, ияк, Җиһаншина, Акмал, Агиш, баек, тәравих, аулак, Инсаф, Гыйззәтуллин, Рим, Ома, Ания, Әсрар, нан, «Аникин».

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / октябрь

Драматург Мирхәйдәр Фәйзи

645 ел элек (1377)

Төрле яктан җыелган урыс гаскәрләренең талавыннан туеп, мукшы кенәзләре Мамай мирза тарафдары Гарәпшаһ угланга илче юллыйлар. Идарәче углан, вазгыятьне бик тиз аңлап, шундук гаскәре белән хәрби сәфәргә кузгала. Ул гаскәрен биш өлешкә бүлә дә дошманга һич көтмәгәндә төрле яктан һөҗүм итә, аннары Түбән Новгородта гайрәт күрсәткәннән соң, кайтыр юлда Рязань кенәзлегенә дә сугыла. Гарәпшаһ углан дошманга татарларның әле көчле булуын шик калмаслык итеп төшендерә. Шулай итеп, Гарәпшаһ углан, Мамай морза әмере буенча Иделнең уң ягында урнашкан җирләрне урап чыгып, анда кабат татар хакимиятен ныгытып йөри.

625 ел элек (1397)

Кырым аксөякләре Тимер Котлык ханнан тарханлык ярлыклары ала. Гәрчә, тәхеттә Тимер Котлык утырса да, асылда Алтын Урда дәүләте белән гаскәр башы Идегәй морза идарә итә башлый.

105 ел элек (1917)

Татар мөхәррирләре Рәхимҗан Марсиков һәм Хәлил Габбасов Семипалат шәһәрендә казакъ телендә милли-демократик юнәлештәге атналык «Сары Арка» газетасын чыгара башлый.

100 ел элек (1922)

11 октябрьдә Уфа шәһәрендә Мирхәйдәр Фәйзи Мәҗит Гафури һәм Давыт Юлтый белән очраша.

75 ел элек (1947)

Шәркый Төркестанның Чүгүчәк каласында (хәзер Кытай Халык Республикасының Шеңҗаң-Уйгыр автоном районына карый) татар-үзбәк урта мәктәбе ачыла.

50 ел элек (1972)

Азәрбайҗан ССРның башкаласы Баку шәһәрендә Совет Көнчыгышы әдәбиятларына багышланган фәнни-гамәли җыен уза. Анда Татарстаннан Хатип Госман, Ибраһим Нуруллин, Йолдыз Нигъмәтуллина һәм Азат Әхмәдуллин катнаша һәм чыгыш ясый.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Октябрь 2022

И останется в мире слово моё...: Шаукат Галиев.

Историческое наследие: «Портрет Чингизхана». Н.Хусаенов, И.Хусаенов; «Ахмед бай». Г.Баруди; «Находки Болгаяр в Финляндии». Х.Бадрутдинов; «Апастовцы на строительстве Казанской линии обороны». Б.Мифтахов; «Татарский мир 100 лет назад».

Татарский мир: «Айрат Зиганшин: «Надеюсь, что мы оставим богатое наследие будущему поколению»; «Мелодии Деушево-Тулумбаево».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Ислам. Религиозный словарь»; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «Стихи Гали Хузия»; «Письма Тауфику Айди». А.Гилязов; «Звезда на горизонте». Л.Хамидуллин.

В глубинах памяти: «Поломничество». Л.Лерон; «Попробуйте быть как Асгат Галимзянов». Г.Ризванов; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Алхәбәр:

Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис хатыны – язучы Ләбибә Ихсанова белән
(«Үлемсезлек җырчысы». Н.Хисамов)

«Безнең мирас» галереясы

«Аллаһ йорты». 1996 ел. *Киндер, майлы буяу. Артист һәм режиссер Раил Садриев эше*

«Чуаш авылы – Абамза». *Резеда Яманова.* 2021 ел

«Ютазы районындагы Салкын Чишмә авылы». *Резеда Яманова.* 2020 ел

«Апрель азагы». *Резеда Яманова.* 2019 ел

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.